Безнең МИРАС

09

сентябрь 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

1 сентябрьдә башкалабыз Казанның Яңа Савин районында Татарстан Республикасындагы иң зур мәктәпне ачу тантанасы булды. Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче әлеге 179 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең директоры – Эльвира Наумова. Бирелә 1375 укучы белем алачак.

Президент вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов укучыларны, ата-аналарны һәм мөгаллимнәрне Белем бәйрәме белән котлады.

Белем илем – мәктәбем!

М.Фролов, Л.Гобәйдуллин фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең мирас

12 +

09(44)

сентябрь 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.

38

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 Без бар! *Әдхәт Синугыл*

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Җамигъ мәчете.

6 Каһарман Батырша: тәрҗемәи хәленә һәм восстаниегә яңа караш. *Фәйзелхак Ислаев*

15 Төрек вә татар тарихы. *Әхмәтзәки Вәлиди*

21 Милли вә мөһим мәсьәлә. *Габделкаюм Баһмани*

ТАТАР ГАМЕ

26 Биләр һәм лашманнар ядкяре. *Рәфыйк Шәрәфиев*

30 Сабаларга илтә юлларым...

ПЕДАГОГИК МИРАС

33 Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

ДИНИ МИРАС

34 Дин һәм шәхес. *Рәдиф Сәгъди*

38 Өйләргә нур биргән дога. *Айзирәк Гәрәева*

ӘДӘБИ МИРАС

46 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Йосыф Баласагуни*

51 Кыйссаи Таһир илә Зөһрә.

54 Кайгысыз падишаһ һәм кайгылы вәзир турында хикәят.

63 Тукай энциклопедиясе. *Рифә Харрасова*

64 Утыз Имәни оныгы — «Кечек Болгари». *Әнвәр Шәрипов*

71 Тормыш юлым. *Гобәйдулла Салихов*

80 Солдат йөрәге. *Зариф Мөэминов*

КАЙТАВАЗ

99 Безнең мирас — затлы бүләк! *Наилә Вилданова*

26 **БИЛӘР ҺӘМ ЛАШМАННАР ЯДКЯРЕ.**
Рәфыйк Шәрәфиев

102 ФАРФОР ЭШЛӘНМӘЛӘР.
Гүзәлия Җәләлова

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском языке)

ХӘТЕР САГЫНДА

102 **Фарфор эшләнмәләр.** *Гүзәлия Җәләлова*

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

104 **Илһам — күңел канаты.** *Дания Гайнетдинова*

ТАТАР ҖЫРЫ

108 **Каян килә татарга моң?!** *Марс Макаров*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

110 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның сентябрь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

114 **Көлке куа килә...**

СПОРТ

116 **Казан янә үзен күрсәтте.** *Атлас Гафиятов*

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Сентябрь*

Заказ №О-2433. Тираж — 1500 данә. Формат 70 Х 108 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 03.09.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Риф Якупов, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр, Равил Айдаровның «Казанский деревянный дом XIX-начала XX века в акварели и графике» китабындагы рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Ш.Мәрҗани урамындагы йорт». Кәгазь, акварель.
Р.Айдаров рәсеме.



Әдхәт Синугыл
(1935-2004)

БЕЗ БАР!

Бөек Болгарның олуг иман китерү шәрифенә
Мең ел узгач, әйтте азан Болгар:
— Кыяматтән терек калган кем бар?
Утта янмас, суда батмас ирләр —
Кол Галиләр аваз салды:
— Без бар!

Мең ел кичкәч, телгә килде Болгар:
— Мең үлемнән исән калган кем бар?
Кабер-ташлар чиркәү асларыннан
Нәгъръә орып кычкыралар:
— Без бар!

Мең елдан соң аваз салды Болгар:
— Бармы минем дан тотар ир-уллар?
Кол булмыйча калган каһарманнар —
Кол Шәрифләр кычкырдылар:
— Без бар!
— Без бар!!
— Без бар!!!

БОЛГАР.
ҖАМИГЪ МӘЧЕТЕ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара

Җамигъ мәчете. 1236 елдан соң ук башланган мөселман мәчете төзелеше XIII гасыр ахырында төгәлләнгән. Мәчет Алтын Урданың тәүге чорыннан сакланып калган архитектура корылмасыннан гыйбарәт.

XIII-XIV гасыр Болгарының иҗтимагый үзәген формалаштыручы комплексның төп бинасы. Элек ул 32 метрга 34 метр үлчәмдәге турыпочмак рәвешендә булган, эчке ягы дүрт кырлы 20 баганадан торган, дүрт кыек агач түбәсе булган. Мәчетнең барлык диварлары акшарланган, тышкы яктан таш баганалар белән ныгытылган. Гыйбадәтханәнең көньягында уеп ясалган бай бизәкле михраб урын алган. Формасы һәм төзелмәсе ягыннан әлеге мәчет 1973-1974 елларда Биләр шәһәрлегендә тикшерелгән монгол чорына кадәрге мәчеткә бик охшаш һәм күпрәтле терәкле, портал ишекле, асимметрияле рәвештә ялганып төзелгән бер манаралы, заллы көнчыгыш мәчетләр тибына карый.

XIV гасыр башында мәчеткә зур реконструкция ясалган. Эчке ягы үзгәртеп корылган — гыйбадәт залы сигез кырлы алты нәфис колонналы алты өлешкә бүленгән. Ике ишек һәм берничә тәрәзә уелган, почмакларына ялгап куәтле манаралар төзелгән. Төзелеш материаллары һәм төзү алымнары буенча Җамигъ мәчете Кавказ арты, Кырым, Кече Месопатамия корылмаларын хәтерләтә. Шул ук вакытта анда, җирле табигать шартларын исәпкә алган хәлдә, Урта Азия ахитектурасының стилистик үзенчәлекләре һәм төсмерләре дә чагылыш тапкан. Шул рәвешчә, стилистика ягыннан караганда, Җамигъ мәчетенең архитектурасы, Болгар шәһәрлегенең башка истәлекләре кебек үк, көнчыгыш төзелеш сәнгатенең үзенчәлекле төньяк тармагын тәшкил итә.

2011-2012 елларда Җамигъ мәчетендә зур конструкция эшләре үткәрелде, шул исәптән XX гасырның 60нчы елларындагы реставрация вакытында куелган ясалма бетон блоклар алмаштырылды, мәчетнең туф блоклары, шулай ук михраб куышы яңадан торгызылды. Эчендә ак таштан идән түшәлде, уеп бизәлгән колонналары реставрацияләнде. Көнчыгыш почмактагы манара да торгызылды, көнчыгыш һәм көнбатыш якларга таш баскычлар корылды.

БАТЫРША ВОССТАНИЕСЕНӘ 260 ЕЛ

КАҺАРМАН БАТЫРША: ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕНӘ ҺӘМ ВОССТАНИЕГӘ ЯҢА КАРАШ

Фәйзелхак Ислаев

Русия мөселманнарының ислам динен саклап калу өчен гасырлар дәвамында барган фидаи көрәшендә актив катнашкан күп шәхесләр халык хәтерендә сакланган. Аларның һәрберсенең үз лаеклы урыны бар, тик алар арасында Батырша хәзрәт дәрәҗәсенә күтәрелгән каһарман юк. Соңгы елларда Батырша, аның җитәкчелегендә ихтилал турында китаплар, мәкаләләр нәшер ителеп тору, Татарстанда һәм Башкортстанда фәнни конференцияләр үткәрелү, диссертацияләр яклану безне бик куандыра. Бу юнәлештә нәтиҗәле эшләгән Гайса Хөсәенов, Җәмит Рәхимов, Ирек Акманов, Мәсгут Гайнетди-

нов, Эдуард Мостафин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәйзелхак Ислаев һәм башкаларның фәнни хезмәтләре, романнары, поэмалары аша Батырша һәм аның заманы, мөселманнарның көчләп христианлаштыруга каршы көрәшен төрле яктан күпкә тулырак итеп күз алдына китерә алабыз.

2015 елның 15 маенда восстание башлануга 260 ел тулды. Форсаттан файдаланып, укучыны Батырша турында тупланган яңа материаллар белән таныштырасым килә. Күренекле дин әһеле һәм акыл иясе, татар халкы милли-азатлык көрәшенең бөек шәхесе Батырша мулла җитәкчелегендә татар һәм башкорт халыклары күтәргән восстание, анда катнашучыларның үзләрен аямыйча ислам дине өчен көрәше генә Русия дәүләтенең көчләп чукындыру сәясәтен үзгәртергә мәҗбүр итә һәм ислам динен, аның гореф-гадәтләрен саклап калырга мөмкинлек бирә. Без бу шәхеснең кылган гамәлләренә дөрес һәм төгәл бәя бирергә, аның исемен хәтердә мәңге сакларга тиешбез.

Батыршаның туган вакыты турында төрле фикерләр әйтелде. Хәзерге вакытта ул 1710 елны йомышлы татарлар (мишәрләр) нигезләгән һәм яшәгән Карыш (хәзер Башкортстан Республикасы Балтач районы Югары Карыш авылы) авылында Туктаргали абыз (мулла) гаиләсендә туган, дип шикләнми әйтә алабыз. XVIII гасыр уртасында Ырынбур губернасы Уфа өязе Себер юлына караган бу татар авылында 35 хуҗалык, якынча 300 кеше яшәгән.

Моңа кадәр нәшер ителгән хезмәтләрдә Батырша 2 мәдрәсәдә 10 ел белем алган шәхес итеп күрсәтелде. Бу фикер дә дөреслеккә туры килми. Ул үз заманына хас булганча, озак еллар укып төпле дини белем алган шәхес: башта туган авылында әтисендә башлангыч дини белем үзләштерә, аннары Тайсуган авылында Габдерахман мулланың данлыклы мәдрәсәсендә (хәзер Әлмәт районы) укый, төпле дини белем һәм тәрбия ала. Ахырда, 1733-1743 елларны, Ташкичү авылының (хәзер Арча районы) мәшһүр имамы, булачак Ырынбур ахуны Габдессәлам Уразмөхәммәд улы мөгаллимлегендә дини һәм дөньяви белемен камилләштерә. Укыган вакыты җәмгысы 26 елга туры килә. Озак еллар дәвамында белем алу хәзерге заман кешесе өчен сирәк күренеш, ә ул чорда имам булып дингә һәм халыкка хезмәт итәргә әзерләнүчеләр Коръәнне, гарәп, фарсы телен озак еллар дәвамында үзләштергән.

Батыршаның Тайсуган, Ташкичү мәдрәсәләрендә белем алган еллары мөселманнарны көчләп чукындыру башланган чорга туры килә. Башта башкортларны 1735-1740 еллардагы восстание вакытында христианлаштыру, 1740 елның 11 сентябрендә патшабикә Анна Иоанновна имзалаган указ нигезендә Россия дәүләтендә яшәгән халыкларны күпләп чукындыру киң җәелә. Ул миссионерларның чукындыру ысулын, авыллардагы мәчетләрне җимерүне, халыкның моң-зарын ишетеп һәм күреп яшәгән, дөньяга карашы, көрәшче рухы формалашкан.

Ташкичү авылында мәчет җимерелгәч, Батырша Уфа өязе Уса юлындагы Гәйнә вулысы Илеш мулла авылында (хәзер Пермь крае, Барда районы Күземъяр-Байавыл авылы) ел ярым, Исәт провинциясендә Мөслим старшинаның мишәр-татар авылында (хәзер Чиләбе өлкәсе Мөслим авылы) өч ел ярым балаларга сабак укыта, мулла була. Биш ел чит җирләрдә балаларга дини белем, мулла вазифаларын үтәп тәҗрибә туплаганнан соң 1749 елда Батырша хатыны Зөлбохар һәм әле яңа гына туган улы Таҗетдин белән Карышка кайта, анда имам итеп сайла-

на, мәдрәсә ачып җибәрә. Соңыннан гаиләдә янә ике кыз туа.

Тиз арада Батырша мулла, аның мәдрәсәсе тирә-якта шактый абруй казана һәм бирегә дини белем алу өчен күрше авыллардан гына түгел, ерак Казан, Күңгер өязләреннән, Исәт провинциясеннән татарлар һәм башкортлар гыйлем үзләштерү өчен килә башлый. Шәкертләр, дин әһелләре, гади халык арасында тирән ихтирам казанган хәзрәтнең абруе артканнан арта бара һәм ул 1754 елда Уфа өязе Себер юлының ахуны итеп тәкъдим ителә, тик старшина Яныш Абдуллин каршы килгәнлектән, әлеге югары дини дәрәҗәгә ирешә алмый кала.

1917 елгы инкыйлабтан соң Төркиядә яшәп иҗат иткән күренекле татар тарихчысы Габделбари Баттал Батырша муллага төрле яктан дөрес һәм төгәл характеристика бирә: *«Акыллы бер кеше буларак, яхшы белем һәм тәрбия алган мулла русларның сыеша алмаслык дошманы була. Фетнә башлаудан күп элек ул башкорт өлкәсен аркылыга-буйга йөреп чыга, яшьләрне укытаөйрәтә, үгет-нәсыйхәт бирә, халык арасындагы сүзләргә, зарларга колак сала, үзе сөйләүдән бигрәк башкаларны тыңлый. Ул матур һәм тәэсирле итеп сөйләргә дә оста була. Батырша Казан татарлары белән дә, казакъкыргызлар белән дә бәйләнешкә керә. Аның вәкилләре Казан өлкәсендәге мөселман авылларында да, казакъ-кыргыз далаларында да йөриләр»*.

Мөселманнар, дин әһелләре — абыз-муллалар арасында Батырша үзенең ислам дине нечкәлекләрен аңлавы, фикер тирәнлеге, дингә һәм тормышка карашы белән генә түгел, сүз осталыгы, үзенең буй-сыны белән дә нык аерылып тора. Ул авылдашларына озын буе, юан булмаган матур гәүдәсе, ак йөзе, кара күзләре һәм кашлары, битенең бер ягында миңе, миңендә үскән берничә төге, мыегы, сакалы үсми торган булып халык хәтерендә сакланган. Батыршаның мондый портреты рәссамнар ясаган сүрәткә бик туры килми, гәрчә Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Мәлс Вафин иҗатын искә алмаганда.

Күп еллар эзләгәннән соң Батыршаның казакълар белән очрашу мөмкинлеген раслаучы материал табылды. Батырша мулла гаиләсе белән 1754 елда Чиләбе якларында Мөслим старшинада бер ай кунак булып китә. Ул биредә булганда төрле авылларда татарлар, сәлҗегут башкортлары белән очраша, хатынының якын туганы йөзбашесаул Мансур Тукаевларда бер атна кунак була. Мансур әнисе вафат булу уңаеннан Коръән уку мәҗлесен Мөслим авылыннан көнчыгышка таба 70 чакрым ераклыкта урнашкан, үзе нигез салган, Мансур исемен йөрткән һәм хәзерге вакытта Курган өлкәсе Сафакүл районындагы Карасу һәм Атҗитәр авыллары арасында урнашкан авылда оештыра. Авылның иске зиратында Мансур Тукаевның кабер ташын танылган археограф Марсель абый Әхмәтҗанов табып укыган һәм аның 1764 елда вафат булуын ачыкланды.

Моңа кадәр Батыршаның бу авылда булганлыгы билгесез иде. Бу безнең өчен, Мансур авылы халкы өчен генә түгел, бөтен ислам дөньясы өчен зур ачыш. Шул ук авыл белән бәйләнгән икенче ачыш — Мансур тирәсендә Урта Җүз казакъларының җәйләүләре булганлыгы. Биредә Батырша казакълар белән турыдан-туры аралашып элемтә урнаштырган булса кирәк. Әлбәттә, ул бу хакта язмаларында искә алмый. Урта Җүз казакъларының восстание бастырылганнан соң араларына күчеп килгән башкортларга уңай карашы, Батыршаның бирегә качып китү мөмкинлеге турында хәбәрләр таралуын искә алсак, мондый мөмкинлекне инкяр итеп булмый.

Гадәттә, халык чуалышлары стихияле рәвештә барлыкка килә. 1755 елгы восстание, Русия мәмләкәтендә элегрәк күзәтелгән халык фетнәләреннән аермалы буларак, Батырша һәм аның тарафдарлары тарафыннан максат-

чан хәзерләнгән күтәрелеш. Уфа өязендә яшәүче мөселманнар арасында восстаниегә хәзерлек 1752-1753 елларда ук башлана. Батырша мулла төрле төбәкләрдә яшәүче муллалар, кайбер вулыс старшиналары белән элемтә урнаштыра. Бөрҗән вулысы восстаниегә хәзерләнүнең үзәгенә әверелә, ә барлык әзерлек эшләре старшина Бикбулат Аркаев җитәкчелегендә, йөзбашларга һәм унбашларга таянып, яшерен рәвештә алып барыла, корал туплана.

Батырша 1755 елның яз айларында мөселманнарны восстаниегә чакырып өндәмә яза һәм аны шәкертләре, таныш-белешләре аша Казан, Күңгер, Гәйнә, Исәт һәм башка төбәкләрдәге мөселманнар арасында тарата, патша хакимиятенә, миссионерларга каршы ислам динен саклап калу өчен җиһадка чакыра. Восстание 1755 елның 3 июленә, корбан гаетеннән соң, билгеләнә.

Билгеләнгән көннән күпкә алда, 1755 елның 15 маенда, Бөрҗән вулысы Елан Иткул һәм Ходайбирде мулла җитәкчелегендә башкортлар старшина Бикбулат Аркаев фатихасын алып, Көньяк Урал тауларында алтын-көмеш, тимер-бакыр, кыйммәтле ташлар эзләр өчен җибәрелгән экспедиция начальнигы Брагин һәм аның командасын үтерәләр, Сапсал ям станын һәм Брагин яшәгән йортны туздыралар. Старшина Бикбулат Аркаев җитәкчелегендә Талкас күле буенда җыен үткәрелә һәм биредә восстаниене туктатырга, башка урыннарга һөҗүм оештырмаска, Брагин командасын юкка чыгаруда катнашучылар гаиләләре белән казакълар ягына күчеп китәргә тиеш, дигән карар кабул ителә. Мондый карар кабул итүнең төп сәбәбе — чакыруга карамастан, Ногай юлындагы башка вулыс старшиналары җыенга килмиләр, ә бөрҗәннәр хакимияткә үзләре генә каршы тора алмаячакларын яхшы чамалаганнар. 21 майда Брагин коман-

Старшина Бикбулат Аркаев җитәкчелегендә җыен булган Талкас күле.
Фото www.sun-expo.ru сайтыннан



Батырша чокыры. Башкортстан Республикасы, Балтач районындагы урман

дасын юкка чыгаруда катнашучылар, гаиләләре, туган-тумачалары белән бергә, 150 ир-аттан, 140 хатын-кыздан торган качаклар Җаек елгасы кичүен саклаган хәрбиләрне тар-мар итеп, казакълар ягына күчеп китәләр.

Фетнә гаскәр көче файдаланып тиз арада бастырыла, старшина Бикбулат Аркаев, элеккеге старшина Алкаш Сөендеков, 6 йөзбаш, берничә унбашлар, аларның хатыннары һәм балалары, якын туган-тумачалары кулга алынып Ырынбурга озатыла, мөлкәтләре хөкүмәт файдасына тартып алына.

Бөрҗән вулысында фетнәчеләрнең май аендагы җиңелүе Батыршаны борчыса да, восстаниегә хәзерлекне туктатмый. Изге эшне яңадан башлар алдынан Батырша иң башта июль ахырында Бөрҗән һәм башка вулыс башкортлары белән очраша, Сәет бистәсендә үзенең остазы Габдессәлам ахун белән киңәшләшә, губерна үзәге Ырынбурдагы хәлләр, андагы татарларның ниятләре белән таныша. Биредә восстаниенең яңа вакыты билгеләнә.

Ногай юлында август аенда башланган восстаниенең масштабын моңа кадәр дөрес итеп билгели алмаганбыз. Яңа материаллар бөтенләй икенче төрле итеп фикер йөртергә мөмкинлек бирә. 9 августта, Ногай юлына караган төрле вулыс халкы, бердәм дәррәү баш күтәрә, иң беренче төзелүче һәм эшләүче бакыр заводларына һөҗүм оештыра, кайберләре яндырыла һәм җимерелә. Бөрҗән башкортлары йомышлы татарлардан яңа куелган старшинаны үтерү белән генә чикләнми, Иргизле елгасында эшләүче Вознесенски бакыр заводына һөҗүм оештыра, җыелган каен тузы, утын, урман яндырыла, 34 ат урлана. Шул ук көнне 150 кешедән торган Тәңгәур башкортлары Урман-Зилаир елгасында урнашкан Преображенски бакыр заводына һөҗүм оештырып 6 русны, 12 чукынган чуашны үтерәләр, 26 атны урлап алып китәләр, 17 арбаны яндыралар. Завод бакыр кайнатуны туктата, ә Сембер өязеннән килгән руда ташучылар рөхсәтсез өйләренә кайтып китәләр.

Фетнәчеләрдән иң зур зыян Ык елгасы буенда Сәңкем-Кыпчак һәм Үсергән вулыс җирләрендә төзелүче Покров бакыр заводына китерелә. 1755 елның 15 августында, православ бәйрәме көнне, Сугын-Кыпчак вулысы старшинасы Шайла Колымбәтов, Бошман-Кыпчак вулысы старшинасы Сатлык Явкеев, Чәңкем-Кыпчак вулысы старшинасы Теләүмбәт Яугостин, Үсергән вулысы старшинасы Кыуат Кинзәгулов җитәкчелегендә берләштерелгән фетнәчеләр отряды сугыш байраклары астында заводка һөҗүм оештыралар. Алар бер-бер артлы чиркәүне, төзелүче завод биналарын, конторны, амбарны

яндыралар, плотинаны җимерәләр, завод казнасы, халыкның мал-мөлкәте талана, мал-туары куып алып кителә, дини бәйрәмгә дип чиркәүгә һәм чиркәү тирәсенә җыелган 400 кешенең күбесе сөңге кадап, ук атып, кылыч белән чабып үтерелә. Тик 50 тирәсе генә кеше үлемнән качып котыла. Менә бу инде дәүләткә каршы башланган фетнәнең ачы нәтиҗәсе.

Көчекбай җитәкчелегендәге фетнәчеләр утыз казактан һәм бер рота драгуннардан торган капитан Шкапский командасын камап ала һәм юкка чыгара. Фетнәдә Бөрҗән, Тәңгәүер, Үсергән, Тамьян, Сувун-Кыпчак, Бошман-Кыпчак, Сәңкем-Кыпчак, Карагай-Кыпчак вулыслары башкортлары иң актив катнашучылардан. Ногай юлында яшәүче башкортлар, татар вулысларыннан аермалы буларак, фетнәдә старшиналар җитәкчелегендә катнашалар, алар белән бергә казакъ далаларына күчеп китәләр.

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев бихисап гаскәр көче кулланып та 1755 елның октябрь ахырына кадәр Ногай юлында тынычлык урнаштыра алмый, ә 50 мең иң актив фетнәче гаиләләре белән казакълар ягына качып, аларга кол булып хезмәт итәргә мәҗбүр була.

Батырша Уфа өязенең төньягында урнашкан Гәйнә вулысында фетнә башлау өчен тиешле чаралар күрә. Иң ышанычлы фикердәшләреннән Максут Айсинны, Ырыскол Ислановны, Исмәгыйль Әпкинны, Әхмәр Көчековны Гәйнә вулысына восстание башлап җибәрү, аны оештыру өчен атларга атландырып җибәрә. Алар вулыска килү белән, 1755 елның 27-28 августында фетнәчеләр вулыс старшинасы Әбдүк Хуҗагуловны үтерәләр. Башап, Солтанай, Төнгүк, Аклыш авылларында халык җыеннары үткәрелә, анда Чурагол мулла Миңлебаев, Исхак мулла Мурзалиев һәм Акчура мулла Ягутеев ялкынлы чыгышлар ясыйлар. Бу җыеннарда Батыршаның «Өндәмәсе» укыла һәм ул халык тарафыннан ачыктан-ачык көрәшкә чакыру итеп кабул ителә. Кыска вакыт эчендә Тол буендагы авылларның барысы да диярлек баш күтәрүчеләргә теләктәшлек белдерә.

Ләкин күптән хәзерләнгән уй-

Батырша һәлак булган урын - Шлиссельбург крепосте

теләкләр тормышка ашырылмый, киң җәелдерелгән әзерлекләр восстаниенең башы була алмый кала. Моның төп сәбәбе — Гәйнә вулысының старшина вазифаларын үтәүче Туктамыш Ижбулатовның фетнәне тар-мар итү өчен кыю чаралар оештыруы. Чөнки шулай эшләгәндә генә ул үзенең чын старшина икәнен раслый алыр иде. Кызыл Яр (Әрҗән) авылы короллы көрәш тарафдарлары белән аларга каршы чыгучыларның көрәш мәйданына әйләнә. Туктамыш яклылар, зур каршылык очратмыйча, җыенны куып тараталар. Тол буенда әзерләнгән фетнә кабына алмыйча сүнә, оештыручылар кулга алына, Оса, Уфа төрмәләренә утыртыла. 1755 елның 25 сентябрендә Уфа өязенең Уса юлына фетнәне бастыру өчен Троицки драгун полкыннан капитан Жеребцов җитәкчелегендә гаскәриләр командасы җибәрелә. Бу җәза отрядына оешкан каршылык күрсәтелми. Старшиналардан Яныш Абдуллин, Туктамыш Ижбулатов, Шәрип Кииков, Батыршаның актив тарафдарларын кулга алып, хакимият органнарына тапшыралар.

Гәйнә вулысында фетнә тар-мар ителү хәбәрен алганнан соң, 1755 елның 1 сентябрендә, иртә таңда, Батырша хатыны, 3 баласы, 11 шәкерте белән авылдан ерак булмаган урманга кача. Бу төркем урманда бер ай качып яши, 2 октябрьдә Бөребаш авылы (хәзер Мишкә районы) янындагы урманда тар-мар ителә, Батыршаның хатыны Зөлбохар, балалары, шәкертләрдән энесе Мостафа тотыла. Батырша үзе Яхъя исемле шәкерте белән качып китә ала.

Русия дәүләте мөселманнарны тынычландыру өчен мөһим карарлар кабул итә: керәшен булмаганнар өчен өстәмә салым, рекрут итеп алу бетерелә, Казан һәм башка губерналардагы керәшеннәр белән бер авылда яшәгән татарларны икенче төбәкләргә күчереп утырту тыела, ә яңа чукынган керәшеннәрнең татарларга каршы булган шикаятьләрен губерна кәнсәләре тикшерергә тиеш була. Ислам динен эзәрлекләү, мөселманнарны һәм мәҗүси халыкны көчләп чукындыру буенча шөһрәт казанган Казан епископы Лука Канашевич һәм Тубыл митрополиты Сильвестр Гловацкий эшләреннән азат ителеп, мөселманнар яшәмәгән епархияләргә күчереләләр. Соңрак адмиралтействога кораблар төзү эшенә беркетелгән йомышлы татарларның һәм морзаларның кайбер таләпләре канәгатьләндерелә. 1756 елгы указ нигезендә Казан, Нижгар, Әстерхан, Себер губерналарында мәчетләр төзергә рөхсәт ителә.

Гәйнә вулысында һәм Карышта восстание әзерләүдә гаепләнеп барысы 15 кеше кулга алына һәм Уса, Уфа төрмәләренә ябыла. 1756 елның март аенда аларны барысын да Уфа төрмәсенә җыялар. Восстание оештыруда төп рольне уйнаган 4 кеше — Максут Гайса улы, Көчекбай Имангул улы, Чурагул Миңлебай улы һәм Нури Баскын улы сорау алганда кыйналып төрмәдә вафат була.

Хакимият органнары Батыршаны бик тырышып эзләсә дә, бер ел буе таба алмый аптырый. Батырша, Яхъя исемле шәкерте белән Бөгелмә якларында, шәкерт чакларында билгеле булган Нәдер вулысында качып яши. Авылдан авылга, өйдән өйгә кереп соранып йөргән ике мосафир үзләрен Тайсуган мәдрәсәсе шәкертләре итеп күрсәтә. Иске Нәдер авылы мәчетенең идән астында кышлыйлар. Җәй җиткәч Батырша, шәкертеннән аерылып, туган якларына юл ала.

Тик туган авылына кайтып җитә алмый, 1756 елның 8 августында Әҗәк исемле татар авылында (хәзер Башкортстан Республикасы Борай районы) старшина Сөләйман Диваев һәм аның ярдәмчеләре тарафыннан кулга алына, аяк-кулларын богаулап, махсус сак астында, Уфага озатыла. Уфадан Ырынбурга гыйсъянчы мулланы капитан җитәкчелегендәге алтмыш кешелек драгун, кырык кешелек казак отряды сак-



«Батыршаның поп белән сөйләшүе». Мэлс Вафин рәсеме

лап алып бара. 23 август кичен Батырша Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев алдына бастырыла, кыйнап сорау алына.

Императрица Елизавета Петровна, 25 августта, Батыршаны кулга алу турында хәбәр алгач та, аны кичекмәстән яшерен рәвештә Санкт-Петербург шәһәренә китерү һәм Яшерен кәнсәләргә тапшыру турында карар кабул итә. 1756 елның 16 сентябрендә Батырша көчле сак астында Ырынбур — Самара — Арзамас — Владимир — Мәскәү — Санкт-Петербург маршруты белән озын юлга озатыла. Гыйсьянчы мулла артыннан Санкт-Петербургка төрмәдә утыручы 11 кеше дә озатыла.

1 октябрь көнне, Муром шәһәренә җитмәс борын, Батырша мулла кулындагы һәм аягындагы богауларны ачып, аны саклап арбада утырып йокымсырап барган капралны һәм драгунны сугып төшерә һәм урманга таба йөгерә башлый. Тик йөгереп бик ерак китә алмый, капрал һәм драгуннар аны куып тоталар һәм кыйныйлар. Муром шәһәрендә Батыршаның кулына һәм аягына тагын богау салып куялар.

Мәскәүдә Батыршаны патшабикә исеменә язма мәгълүматлар бирергә күндерәләр. 4-21 ноябрь араларында Батырша көн саен императрица исеменә хат яза. Тарихта бу язмалар «Гарызнамә» исеме белән мәгълүм. Тел галиме һәм тарихчы Мәсгут ага Гайнетдинов фикеренчә, «Гарызнамә» — XVIII йөз әдәбиятының иң кыйммәтле энҗеләреннән берсе: *«Халык тормышын көчле хәрәкәткә китергән, чор тарихын иярләгән каһарманлыклары булмыйча, шул «Гарызнамә» авторы буларак кына танылса да, Батырша милләтебезнең якты, онытылмас шәхесләреннән була алыр иде. XVIII йөз уртасы караңгылыгында, ул әдәбиятыбызда кайнар реалистик публицистика, күренекле вакыйгалар турында тарихи-әдәби очерк, сәяси-полемик көрәш әсәре мәйданга китереп калдыра алган. Батыршаның бу әсәре татар иҗтимагый фикерен урта гасырлыктан йолкып алып, яңа, мәгърифәтчелек киңлекләренә чыгара. Җанлы тормыш хәлләрен, көнкүреш көрәшләрен һәм вакыйгаларын, дөньяви*

яшәеш кайнарлыкларын сүз сәнгатебез мәйданына, башлап, Батырша алып керә... «Гарызнамә» чал тарихыбызның хәзерге яңаруга кискен борылыш чатында иң якты маяк булып тора».

Хат язылып тәмамлангач та тикшерүне дәвам итәр өчен Батырша мулланы Мәскүдән Санкт-Петербургка озаталар. Петропавел крепостенда урнашкан төрмәдә тикшерү 2 ел дәвам итә. 1758 елның декабрендә, Батырша һәм аның 10 көрәштәше фетнә оештыруда гаепләнә. 1758 елның декабрь ахырында Батыршаның борын кабагын ертып, камчы белән кыйнаганнан соң гомеренең ахырына кадәр Шлиссельбург кальга-крепостена ябалар. Аның аяк-куллары богаулана, янында һәрдаим күзәтеп тору өчен 6 кешедән торган сакчы куела. Көрәштәшләре Рогервик каторжан төрмәсенә озатыла.

Моңа кадәр Батыршаның төрмәдә поп белән бер мәртәбә сөйләшүе билгеле иде. Яңа чыганаклар бу мәсьәләгә дә ачыклык кертте. Батырша тагын бер мәртәбә поп белән очрашып дин, чукындыру хакында сөйләшү алып барган.

Яңа чыганаклар Батыршаның төрмәдә көрәшеп вафат булу вакытын да ачыкларга мөмкинлек бирде. Моңа кадәр бу дата фәнни хезмәтләрдә 24 июль дип ялгыш күрсәтелеп килгән. Фаҗига 21е булган икән. Аермасы 3 кенә көн булса да, фәндә төгәллек мөһим. 1762 елның 21 июль төнендә Батырша мулла, сакта булган Григорий Епифановның йоклап китүеннән файдаланып, кулына балта алып, сакчыларны үтереп, төрмәдән качып китмәкче була. Төн уртасында төрмәдә булган хәлләрне аңлату өчен крепость коменданты подполковник Иван Бередников тарафыннан 3 көн нәрсә акланырга белмичә язылып сенатка җибәрелгән донесениедән өзек бирәбез: *«Голову капрала Никитина он (Батырша —* ***Ф.И.****) разрубил на-двое; у солдат — у Хомутова головы левую сторону разрубил и правый висок проломлен; у Лазерева в дву местах брюхо пропорото, у головы же по левую сторону тела схватил; у Епифанова, который был на часах, в дву местах голову разрубил же, ис которых капрал Никитин, солдат Хомутов сего же числа умре, а Лазерев и Епифанов лекарем пользуются. Оный же колодник Батырша и сам умер без всяких язв и побой»*. Әлбәттә, бу китерелгән чыганак ярдәмендә төрмәдә Батырша белән булган фаҗигане төгәл сурәтләп булмый. Сакчылар Батыршаны үзләре үтергән булырга да мөмкин, ә донесениеда акланыр өчен үзе вафат, дип язылырга мөмкин.

Татар-башкорт милли-азатлык хәрәктенең иң танылган шәхесләреннән берсенең тормышы шулай өзелә. Аның үле гәүдәсен кальга диварлары тышындагы бер чокырга күмәләр.

Фетнәдә катнашканнарның язмышы кебек үк Батырша гаиләсенең язмышы да фаҗигале була. Улы Таҗетдин, Мәскәүгә барырга чыккач, юлда 1756 елда вафат була. Зөлхбохар Хәсәнова кызлары белән чукындырыла һәм Мәскәүдә Девичий монастырьга ябыла. Төпчек кызы Салиха 1759 елны авырып үлеп китә. Зөлбохар чукындырылганнан соң Мария Александровна, ә Зөләйха Вера дип атала башлый. Алар турында башка мәгълүмат табып булмады.

Каһарман Батырша мулла исеменә бәйле вакыйгалар әнә шулай фаҗигале тәмамлана. Ислам динен сафлыкта һәм чисталыкта саклап калу, халык бәхете өчен көрәшүчеләр, гомерләрен корбан итеп, мөселманнарны тоташ чукындырудан коткара. Русиядә ислам динен юкка чыгарудан, камчы һәм кылыч ярдәмендә алып барылган христианлаштыру сәясәтен тормышка ашырудан Батырша восстаниесе генә туктата, хакимиятне ислам динен рәсми тану юлына басарга мәҗбүр итә. ■

Күренекле тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтзәки Вәлидинең (1890-1970) «Төрек вә татар тарихы» исемле китабы 1912 елда Казан шәһәренең «Милләт» матбагасында басыла (280 бит). 1915 елда шуның нигезендә «Кыскача рәсемле төрек-татар тарихы» дөнья күрә (135 бит). 1917 елда әлеге әсәрнең икенче басмасы берникадәр үзгәртелеп янә укучыларга таратыла (96 бит). Ә 1992 елда текстолог-галим Равил Әмирханов тарафыннан «Кыскача төрек-татар тарихы» халкыбызга кайтарылды. Әмма «Кыскача» тарихларда «Төрек вә татар тарихы»ның Алтын Урда һәм Казан ханлыгына нисбәтле V, VI бүлекләре шактый аз яктыртылган. Шул сәбәпле, игътибарыгызга 1912 елгы басмадан әлеге бүлекләрне тәкъдим итәбез.
Шунысын да искәртү урынлы булыр: әлеге әсәр 22 яшьлек Әхмәтзәкинең, вакытлы матбугатта басылган мәкаләләрен искә алмаганда, беренче саллы хезмәте.

Редакциядән

ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫ

Әхмәтзәки Вәлиди

Шәһәрне камау. 1314-1315 елгы фарсы манускриптыннан миниатюра

ДӘШТЕ КЫПЧАК[1] ЯКИ АЛТЫН УРДА МӘМЛӘКӘТЕ

ҖУЧИ ХАН

Җучи — Чыңгызның олуг угылыдыр. Сугышлар соңында, атасы Чыңгыз янына кайтып, кардәш ыруглары илә көрәшкәч, атасы аны үзе яулап алган кыпчак иленә җибәрде. Җучи үзенең бер микъдар гаскәре илә Урал һәм Волга тирәләрендә күчмә хәлдә тереклек итте. Җучиның мәмләкәте үзенә нисбәт илә «Җучи иле» яки «Җучи олысы» дип аталыр иде. Җучи күркәм холыклы падишаһ иде. Атасыннан алты ай алда үз олысында вафат итте (1227). Яше 30 илә 40 арасында иде. Шәйбан, Иҗен, Бәркәҗар, Бату, Бәркә, Тукайтимур исемнәрендә угыллары калды. Җучиның вафатына Чыңгыз гаять кайгырды вә Җучиның угылларын чакырып Каракорымга китерде. Җучиның угылы Бату яшькә кечерәк булса да, баһадирлык, гакыллылык җәһәтеннән кардәшләреннән өстен иде. Чыңгыз аны хан итте вә алтыннар илә зиннәтләткән кыйммәтле бер тирмә бирде.

Җучи хан сыны

БАТУ ХАН

Бату хан булгач та, үз илен киңәйтү кайгысына керешеп, сугыш яракларын карый башламыш иде. Бабасы Чыңгыз ханның вафат хәбәре килеп, эшләреннән туктап калды.

Җучи хан төрбәсе. Казакъстан, Караганда өлкәсе, Олы тау районы

Батый хан Алтын Урда тәхетендә

Ике ел соңында (1229) Үгәдәй ханның каанлыгын рәсми расларга җыелачак корылтайда булмак өчен Бату, үзенең кардәшләрен бергә алып, Каракорымга сәфәр итте. Үзе урынына энесе Тукайтимурны тәгаен итеп калдырды. Каракорымга бөтен ханнар җыелып Үгәдәйне рәсми каан иттеләр. Барысы бергә сыйхөрмәт күреп, уен-көлкеләр иттектән соңра, барысы бергә Кытайга барып кайттылар. Моннан соң Үгәдәй каан, Батуны итәчәк сугышларына ярдәм өчен, үзенең угылы Киекҗан, Толуй угылы Мәнгү хан, Чыгтай угылы Байдар ханнар командасында 30 мең гаскәр хәзерләп, һәммәсенә Батуны баш итеп, кыпчакка озатты. Болар, кыпчакка килеп кунак булдыклары соң, Болгар ханлыгына сәфәр иттеләр. Юлда бәгъзы болгар кешеләре боларның килгәнен күргәч тә Болгарга хәбәр иттеләр.

Бату шәһәрне күп зыян салып алды. Илһам хан Батуның куәте алдында баш ияргә мәҗбүр булды, Батуның итагатенә керде. Бер микъдар салым һәм дә кирәк вакытта гаскәр бирәчәк булды (1236 ел).

Моннан соң Бату рус җиренә йөрмәк булды. Болгар ханына да үзе илә бергә булуны боерды. Ошбу вакыт рус мәмләкәте бернечә вак кенәзлекләргә бүленеп бетмеш вә ошбу кенәзләр бер-берсе илә һәрвакыт сугышып тора торганнар иде. Бату кенәзләргә кан түкмичә итагать итүләрен сорап илче күндерде. Бу эшкә вак кенәзләрдән алып Владимир шәһәрендә тора торган бөек кенәз Георгий да каршы торды.

Бату иң әүвәл Рязань кенәзенә килде. Биш көн кадәр вакыт солых илә бирүләрен көтеп торды, булмады. Ахырдан Бату гаскәре шәһәрнең кальгасы өстенә баскычлар илә менделәр дә, шәһәрнең астын өскә әйләндерделәр. Кул көчләре илә шәһәрне алдылар. Бәгъзы кенәзләр меңләгән гаскәр җыеп каршы торып маташтылар исә дә, татар атларының аяклары астында тапталудан башка файда чыкмады. Моннан Москвага килеп, кенәз

[1] Дәшт — фарсыча бушлык мәгънәсендә. Дәште кыпчак — кыпчак сахрасы мәгънәсендә. Яңа мәмләкәт, Батуга бирелгән алтынлы тирмәгә карап, «Алтын Урда» аталды. Бу мәмләкәт магуллар тарафыннан Җучи вакытында «Җучи иле», аннан соң «Бәркә иле», Үзбәктән соң «Үзбәк иле» дип аталды. Төрек-магул гаскәре эчендә татарлар да күп булды һәм дәһшәтле бер гаскәрне атарга «татар» дигән исем муафикъррак булганы өчен, гареб һәм рус халыклары Чыңгыз командасындагы төрек вә магулларны «татар» дип атадылар.



Бату гаскәриләренең Владимирны алуы. XVI гасыр рәсеме

Суздальга монгол-татарларның һөҗүме. XVI гасыр рәсеме

Владимирны әсир алып Владимир шәһәренә киттеләр (1237 сәнә, 2 февраль). Татар гаскәрләре Владимирга җиттеләр. Владимир халыклары татарларның йөреш-торышларының артык дәрәҗәдә җиңел булуыннан хәйран калды. Бөек кенәз Георгий татарларның килүен ишеткәч тә качмыш иде. Бату: «Бөек кенәз мондамы?» — дип сорады. Руслар уклар илә җавап бирделәр. Бату солых илә бирүләрен сорады, янә уклар илә җавап бирделәр. Ахыр 6 нчы көн (8 нче февраль) татар гаскәре шәһәрнең һәр җәһәтендәге капкаларын ватты да үз куллары илә шәһәрне алды.

Моннан соң Бату гаскәренең бер микъдарын Кострома вә Галичә тарафына җибәрде. Үзе Ростов тарафларына китте. Февральдә 16 шәһәрне алды. Кенәз Георгий Сить елгасы тарафында торыр иде, күп гаскәр хәзерләп татарларга каршы чыкты. Гаскәре илә бергә Георгий үзе дә һәлак булды. Бату Новгород тарафына китте. Тверь, Торжок, Волок кеби берничә шәһәрне алдыкы соңра, Новгородка барып җитмичә, әйләнеп кайтып китте.

Новгород русларның иң бай шәһәре иде. Аның сәламәт калуы руслар өчен зур бәхет булды. Кайтып барган юлы Козельск шәһәренә туры килде. Ошбу шәһәр әһеле кадәр Батуга каршы торган руслар булмады. Бату бу шәһәрнең халкын һәлак итеп бетердектән соң гына ала алды.

Ошбу вакыт тәмам яз булып, бозлар тишелер вакытлар җитмеш иде. Татарлар Дон буена кайтып җиттеләр вә ошбу урында истирәхәт өчен калдылар. Әсир итеп алган рус руханиларын җибәрделәр.

1240 елда Бату хан җәнүби Русиягә юнәлде. Мәнгүне гаскәре илә Киев шәһәренә җибәрде вә Киев кенәзенә ихтияры илә бирелүен сорап илче җибәрде. Киев кенәзе Михаил илчеләрне үтертте вә Мәнгү гаскәре килеп җитү белән үзе куркып шәһәрдән

качты. Моның урынына янә Данаэль кенәз булса да, ул да качты. Өченче буларак Дмитрий кенәз булды. Киев халкы гаять мәгъруруре иде, татарга җиңелүне хәтерләренә булсын китермәсләр иде. Бату, илчеләренең үтерелүен ишеткәннән соң, үзе гаскәре илә сәфәр итте.



Бату ханга һәйкәл

Мәнгү илә Бату, Киев янында Днепр елгасы аша чыгып, Киевның кальгасы янына килмәктә иделәр. Татарларның кычкыруларыннан, атларының кешнәүләреннән, дөяләренең бакыруыннан, арбаларының шыгырдавыннан шулкадәр куркынычлы тавыш хасил булды ки, Киевта адәмнәр бер-берсе илә сөйләшкәндә сүзләрен дә көчлек илә ишетәләр иде. Киев әһле янә солых чарасын карамадылар. Татарлар Киевның тимер капкасын ваттылар да шәһәр әһеленә кылычлары илә хөкем итә башладылар. Бер көн эчендә бөтен Киев урамнары үләксәләр илә тулды, адәм каннары елга булып акты.

Руслар, кыйммәтле нәрсәләрен яннарына алып, нәсара[2] динен кабул иткән Дмитрийның кабере илә Десятинная дигән чиркәү кеби мөкатдәс урыннарына тулдылар, истимдад итәрләр[3] иде. Татарлар ошбу чиркәү илә ошбу каберне җир илә бертигез иттеләр. Кенәз Дмитрийны әсир итеп Бату янына китерделәр. Бату кенәзне гафу итте. Киев шәһәре халкының күплеге, зиннәтлеге, байлыгы илә шәркый Яуропада беренче шәһәр иде. Татарлар кулында тузан булып күккә очты, адәмнәре җир ителде, каннары елга булып акты.

Моннан соң Бату Польский корольлеге тарафына юнәлде. Юлда Галицкий, Владимир исемнәрендә кенәзлекләрне алды. Ошбуның илә русларның Новгородтан башка барлык кенәзлекләре татар кул астына кереп бетте.

Бату, бөтен Польскийны вә моннан соң Венгрия, Болгария вә Хорватия (Босния) вилаятьләрен алып, Германия мәмләкәтенә керде. Ошбу вакыт бөтен Яуропаның коты очты, барлык Яуропа үзләренең ватаннарын саклаудан өмид өзделәр. Гареби Яуропада Англия җиренә кәсепкә бара торган балыкчыларны, «Татарлар килә» дип, юлларыннан туктаттылар. Ошбу җиргә җиттеге соң Батуга Үгәдәй кааннның вафат хәбәре килде. Ошбу сәбәптән Бату кайтып китте. Татарларның ошбу хәлләре Яуропага мәгълүм түгел иде, аларча изгеләр догасы Батуга тәэсир итте.

Бату хан Идел буена кайттыкы соң, мәмләкәт эшләрен тәртип вә низамга куярга, шәһәрләр бина итеп, гаделлек илә мәмләкәтне идарә итәргә кереште. Һәм мәмләкәтне идарәгә уңай булсын өчен Әчтерханның югары ягында, Актүбә дигән урынга Сарай исеме илә шәһәр бина итә башлады (1243).

Рус кенәзләре ханга итагать белдереп, бәйгать итәргә[4] килә башладылар. Иң әүвәл кенәз Ярослав бәйгать итте.

[2] Нәсара — христиан.

[3] Истимдад итү — дошманга каршы тору өчен ярдәм сорау.

[4] Бәйгать итү — берәүнең хакимиятен тану һәм аңа буйсыну.

Каракорымда Мәнгү каанның сарай макеты

Бату гаскәре, гомумән, төрекләр-магуллар, йогышлы авырудан, ваба вә чумадан бик куркалар, ваба вә чума кеби авырулардан бик нык сакла632налар иде. Рус кенәзләренә бәйгать итәргә килгәндә карантин күрергә, ут, төтен аша чыгарга туры килә иде.

Ханга бәйгать соңында, кенәзләргә кенәзлекләрен олуг кааннан раслату кирәк иде. Кенәз Ярослав үзенең угылы Константинны Каракорымга каан хозурына җибәрде. Моннан соң барлык кенәзләр бер-бер артлы килеп бәйгать иттеләр. Бату Ярославны җөмлә кенәзләргә баш — Великий кенәз итеп Киев шәһәренә җибәрде. Ошбу көнгә кадәр Бөек кенәз Владимир шәһәрендә булыр иде. Батуның мәмләкәте ике төрле идарә кылына башланды. Берсе — идарәи мохтарияле (автономный) вилаятьләр. Безнең бабаларыбыз болгарлар илә Русь, Польша кенәзлекләре кеби. Икенчесе — Батуның үзе насыйп иткән валиләр[5] ярдәме илә идарә ителгән асыл мәмләкәттер.

Үгәдәй каанның вафаты соңында хатыны Турагина каанлык итте. 1246 сәнәдә Корылтай җыелып, Үгәдәйнең угылы Көекне каан тәгаен итеп бөек җөлүс[6] туе булды. Ошбу туйда Бату, аягы авырттыгы сәбәбеннән, була алмады. Үзенең энесе Бәркә илә якыннарын һәдияләр илә җибәрде, вә бөек кенәз Ярославны һәм җибәрде. Ошбу туйда бөек магул мәмләкәтенең һәр тарафыннан хисапсыз күп түрәләр, ханнар, ислам мәмләкәтеннән янә бик күп галимнәр хазир булдылар. Көек бер елдан артык каанлык итә алмады, вафат итте. Батуга каанлыкны тәклиф иттеләр[7], кабул итмәде. Бәлки Толуй ханның угылы Мәнгүне муафикъ күреп, ошбуны тәгаен итегез, диде. Һәм Мәнгү каан итеп тәгаен ителде (1251).

Бату кызылга тартым төстә, биек гәүдәле, күләр йөзле, гаять гакыллы, сәясәт эшләрендә маһир, бик юмарт падишаһ иде. Чыңгызның башка балалары нигездә моның фикереннән чыкмаслар, бәлки моны хөрмәт итәрләр иде.

Бату хакыйки Чыңгыз баласы иде, махсус бер дин вә мәзһәб илә мавыкмады, бер Аллага гыйбәдәт итәр вә һәр дин әһеленә бер дәрәҗәдә хөрмәт итәр иде. Дөньяның сирәк падишаһларыннан булган Бату 1255тә вафат итте. Җиренә угылы Сартак хан булмыш иде. Бер елдан вафат итте. Соңра энесе Улакчы хан булды исә дә, бу да тиздән вафат итте.

Дәвамы бар ■

[5] Вали — дәүләтнең бер өлкәсен идарә итү тапшырылган кеше.

[6] Җөлүс — тәхеткә утыру.

[7] Тәклиф итү — йөкләү.

МИЛЛИ ВӘ МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘ[1]

Габделкаюм Баһмани

Журналыбызның узган санында Габделкаюм Баһманиның Саба районы Юлбат авылында туганлыгы, Сатыш мәдрәсәсендә укытканлыгы, «Шура» һәм «Әд-дин вәл-әдәп» журналларындагы кайбер мәкаләләрнең авторы булуы турында язган идек. Күптән түгел генә редакциябез журналистлары Саба районына һәм мәгърифәтченең туган авылы Юлбатка сәфәр кылды (фоторепортаж WWW.BEZNENMIRAS.RU сайтында). Авыл мәктәбенең тарих укытучысы, музей җитәкчесе һәм төбәк белгече Илдар Фәтхулла улы Сафин безгә Габделкаюм Баһмани турында менә нинди мәгълүматлар бирде: «Габделкаюм – авыл мулласы Баһманов Мөхәммәтшакирның улы. Каюм да дини белем ала, Юлбат имам-хатыйбы була, ләкин илдә барган үзгәрешләр – Октябрь революциясе нәтиҗәсендә муллалык эшен ташларга мәҗбүр булган. Улының диннән тайпылу кайгысын күтәрә алмыйча, Мөхәммәтшакир хәзрәт акылдан яза һәм 1921 елда вафат була. Истәлекләргә караганда, Каюм сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгән, шул ук вакытта балаларга яшертен генә белем биргән. Соңрак Саба районы мәгариф бүлеге инспекторы, Мамадыш кантонының мәгариф бүлеге мөдире булып эшли. Муллалык вазифасыннан баш тартуга карамастан, Каюм кулга алына, төрмәдән кире кайтмый».
Илдар Сафинның Юлбат авылы тарихы турындагы мәкаләсен журналыбызның алдагы саныннан укый аласыз.

4.

Инде меллалык мәсьәләсе кузгалтылгач, милли мәктәпләр хакында да бер бәхәс итик. Әгәр бер гыйльми камус[2] язылса, мәктәп-мелла хакында бер кәлимә астында мәгълүмат бирергә мөмкин булыр иде. Бездә хәзер ибтидаи[3] мәктәпләр шактый күп, төрлесе төрле типта булса да, бөтенләй мәктәп булмаган җир бик сирәк. Соңгы елларда донос сәбәпле генә ябылган мәктәпләр генә ачыла алмый, андый җирләр укудан бөтенләй мәхрүм торалар. Безнең Казан губернасындагы мәктәпләрнең 7/10се хөррияттән[4] соң ачылган булып, арада вәкыфлар илә киләчәкләре тәэмин ителгәннәре дә бар. Мөгаллимсез мәктәп хәзер бик сирәк. Әмма укыту җәһәтенә килсәк, әлбәттә, күбесендә кызыгырлык түгел. Шулай да, дәвам итеп торганда, акрын булса да төзәләчәкләр. Әмма бөтенләй уку тукталган җирләр бик кызганыч, аларның киләчәкләре бик караңгы.

Инде мондый авылларда школалар[5] ачтыру мәсьәләсе бар. Боларга бердәнбер юл шушы. Русча укуның кирәклеге дә хәзер инкяр ителми. Шу-

*Ахыры. Башы алдагы санда.
[1] Мәкаләнең бу өлеше 1916 елгы «Шура» журналының 11 санында басылган.
[2] Гыйльми камус — энциклопедик сүзлек мәгънәсендә.
[3] Ибтидаи — башлангыч.
[4] Хөррияттән соң — 1905 елгы революциядән соң.

Л.Гобәйдуллин фотосы

лай да булса, школаларның ачылуы вә тәрәккъкый итүләре бик акрын, моның да сәбәпләре имамнар тәгассыбе[6] яки гавам каршылыгы гына түгел, бүтән мөһим сәбәпләр бар. Мәгълүмдер ки, Русиядә иң алдынгы һәм бөтен халыкка бертигез караучы ялгыз Уфа земствосыдыр[7]. Оренбургның да шуның эзеннән баруына шатланмаслык түгел. Мәгариф мәсьәләсендә моның әһәмияте бик зур. Шундый бер земство булмаганда, школа ачтыру бик мәшәкатьле, ачылганда да файдалы булуы бик шөбһәле.

Менә бу мәсьәләдә мин үзем белгән фактларны сөйлим. Мин үзем халык арасына рус мәгарифе, рус телен укуны таратырга байтак тырыштым. Шактый гына авыллар үзләренең тәрәккъкыйпәрвәр имамнары тәэсире

[5] Гадәттә XX йөз башында татарлар «школа» дип земство тарафыннан ачылган мәктәпләрне, ә «учитель» дип анда укыткан мөгаллимнәрне атаганнар.
[6] Тәгассыб — фанатизм.
[7] Земство — Россиядә сайлаулы җирле үзидарә органнары. Казан губернасы земстволарына сайланган мөселманнар саны Оренбург, Уфа, Самара губерналарындагы земстволарга караганда шактый аз булган. Бу исә төбәкнең иҗтимагый-мәдәни тормышына тискәре йогынты ясаган.

Юлбат авылы күренеше

илә русча укуга ихтыяҗны аңладылар. Хәзер безнең өяздә берничә авыл өч-дүрт елдан бирле школа ачу ижтиһадында йөриләр, ләкин акча юк, фәлән дигән сылтаулар илә земство һаман эшне суза. Мондый авылларда уку тукталганлыктан, болар өчен бер көн булса да алдан ачылуы бик әһәмиятле. Шундый авылларның бер-икесендә күп тырыша торгач школа ачылып, керәшен учительләр куелган иде, икешәр кыш дәвам итеп хәзердә ябылдылар. Сәбәбе шул: дин гыйлеменә 20 минуттан артык вакыт закон буенча бирелми дип, дин мөгаллименә 20 минуттан артык укытырга рөхсәт бирмәделәр. Билгеле, болай булганда халык школаларга яхшы күз берлә карый алмый. Халык илә инспектор арасында каршылык чыкты да школа ябылды. Меңнәрчә еллык тел, иске әдәбияты булган бер милләтнең мең ялвару берлә ачтырган школаларына шундый мөгамәлә булгач, андый школа аркылы мәгариф таратып булмаячагы мәгълүм.

Бездә школаларның күбәймәвенә меллалар тәгассыбе, халыкның каршылыгы гына сәбәп түгел. Тәрәккъкыйпәрвәр имамнар вә русча укудан курыкмый торган мәхәлләләр дә, шундый сәбәпләр өчен, школа ачылу эшенә җөрьәт итә алмыйлар. Шуның өчен дә милли матбугатыбызда школа кирәк дип кенә агитация ясау җитми. Мөмкин кадәр школаны халык яратырлык, халыкка мәгариф юлбашчысы булуына тырышырга кирәк. Мин сүземне бер өязгә карап кына сөйлим, әлбәттә, бар җирдә дә алай булмас. Тагын бу тугрыда халыкның үзендә дә гаеп юк түгел.

5.

Мондый мәсьәләләрдә халыкта булган гаеп шул: матбугатыбызда никадәр язылса да, халык һаман да земствоның әһәмиятен тәкъдир итә алмый. Әгәр дә земство сайлауларына әһәмият биреп, мөселман булмаганда да, үз файдабызны күзәтерлек русларны сайласак, ул вакытта үзебез дә файда күрер идек.

Земство сайлауларына староста сайлау кадәр дә әһәмият биреп көч сарыф итмәгәч, анда үзебезгә файдалы эшләр кылынмавына, мәгариф эшләребезгә әһәмият бирмәүләренә дә гаҗәпләнеп булмый. Моннан элек, земствога гласный сайлаганда, бер волостьта гына сәүдәгәр вә җирбиләүче мөселманнардан 24 кешегә повестка бар иде. Повестка таралгач та шулар арасында йөреп, земствога сайлауның әһәмиятен игътибарсыз калдырырга ярамауны сөйләдем. Шуңа карамастан, 24тән берсе дә сайлауларга катышма-

ды. Лаеш өязе мөселманнарыннан Кабан имамы Габдрахман әфәнде гласныйлыкка сайланган иде, шуның иҗтиһады аркасында, мөселман мәктәпләренә уку әсбабы бирелә башлады.

Дөрес, бу бик аз ярдәм бары гласныйлар күбрәк булып тырышканда земстводан файдалану мөмкин икәнен күрсәтүе белән әһәмиятле. Габдрахман илә бергә Габдулла, Зәйнулла, Гомәр, Госманнар да булса, билгеле, артыграк эш йөртеп булыр. Әһәмиятсез керәшен авылларына егермешәр меңгә төшереп һөнәр мәктәпләре салынганда, өч-дүрт йөз тәңкә расходлы школа ачуга мөселманнар шулкадәр ялындырылмас иде. Суд каршында гаепле кеше булмаганда, школага дин мөгаллиме буларак халык теләгән кеше куела. Башка губерналарда ошбу низам ярыйдыр. Безнең бу тарафта исә, ни сәбәптер, халыкның теләве һичбер игътибарга алынмый. Бәлки каршы барыла. Бу эш әһәмиятсездер дә, ләкин школаларның күбәюе өчен зур киртә булуында шөбһә юк. Школа ачтыру, русча укырга тырышуга халыкны кызыксындыру илә мәшгуль матбугатыбыз бу җәһәтне дә онытмасын иде. Шулай булса да, мәктәпләр ябылып, уку тыелган җирләрдә школа ачудан башка чара юк. Бары мөмкин кадәр үзебезгә файдалы рәвештә булуына гына тырышырга кирәк.

6

Мәктәп вә школалар бәхәсен кузгалткач, тагын да бер бәхәс кылу тиешле мәсьәләбез бар. Юлы чыккач ул хакта да бер-ике сүз әйтергә кирәк.

Хәзер һәр җирдә ибтидаи мәктәпләребез күбәеп бара. Көннән көн тәртипле мәктәпләребез арта бара. Хәзер иң читен мәсьәлә мөгаллим вә мөгаллимәләр табу мәсьәләседер. Яхшы гына мәгълүматлы мөгаллимнәр аз табылганның соңында да ценз-фәлән кеби рәсми чикләүләр[8] чыга. Безнең тарафта киләчәге вәкыфлар илә тәэмин ителгән мәктәпләр бар, аларга соң елда ачылу сәбәпле цензысыз мөгаллим куярга мөмкин булмый. Бу мәсьәлә тагын мең дә беренче мәртәбә милли дарелмөгаллимин[9], дарелмөгаллимат[10] мәсьәләсен хәтергә төшерә. Әгәр безнең биргән карарларыбызның йөз дә өчесе генә гамәлгә чыкса да, без байтак алга атлар идек. Бу мәсьәләне юлбашчыларыбызның исләренә төшерми узып булмый.

Бәгъзе яшьләр: «Кырык кат чәйнәлгән бәхәс берлә Америка ачарга тырышкан», — дип фикеремә каршы төшәрләр. Минем инануыма күрә, неграмотный бер керәшен әдәбиятыбызга хуҗалык кыла башласа, мөгаллим юклык сәбәпле милли мәктәпләр акрынлап ябыла барса, йөз коммерсант, мең гимназист булсын, милли тәрәкъкыйбезнең юлы әзер, дип булмый. Әдәбиятыбызны аңлаучылар фәкать бармаклар берлә генә санарлык калачагы билгеле.

Яшь байларыбызның берсе, үзенең гимназиядә укый торган баласына аерым мөгаллим тотып, милли тел укыта иде. Аз канлы бала моны күтәрә алмый, авыру булды. Мин моның сәбәбен сорап, баласының саулыгына бу кадәр авыр тәэсир итәрлек эшне эшләвенә каршы килгән идем. Ул әфәнде миңа шул җавапны бирде: «Гимназиягә кабул ителү яше елдан-ел киметелә, фәләнчә яшьтән югары булса алмыйлар. Шул сәбәпле балага милли әдәбиятны укырга форсат юк. Әгәр гимназияләр елдан-ел болай кысыла барса, безгә бары ике юл кала: йә бөтенләй милли әдәбияттан ераклашу, яки гимназиядә укытмау. Табигый, болар икесе дә бик уңайсыз. Әгәр бу юл берлә барса, илле елдан милли әдәбиятны аңлаучылар югары

[8] Ценз-фәлән кеби рәсми чикләүләр — укытучының махсус белеме, квалификациясе таләп ителү.
[9] Дарелмөгаллимин — ирләрдән укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[10] Дарелмөгаллимат — хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты.

катлау арасында бармак санында гына калыр. Менә мин дә балам милли әдәбияттан мәхрүм калмасын, дип шушындый һәлакәтле юлны ихтияр иттем», — диде.

Юбилей мөнәсбәте илә бер өлеш яшьләребезнең гимназия ачарга тырышуларының сәбәбе мәгълүм буладыр. Вакытында үзебез мөхбирлек иткән газетада гимназия фикерен куәтләгән идек. Бары дәлилебез икенче иде.

Габделкаюм Баһмани гаиләсе белән. 1912 ел

Югарыдагы бай әфәнденең сүзен ишеткәч, фикеребезнең дөрес икәненә мәмнүн булдык. Бер авыл кешесенең милли гимназия мәсьәләләренә керешеп Америка ачуы гаҗәп кеби тоелыр, ләкин белгәнне сөйләргә (икътидар шарты илә) һәркемгә ихтияр. Каләм вә фикернең шәһәрлеләр вә рус мәктәбендә укыган кешеләр кулында гына монополия булуы безгә мәгълүм түгел. Безнең һәр эштәге гадәтебез — башлап ташлау. Без ике юбилейда[11] ниләргә генә карар бирмәдек: эшкә килгәндә кешеләр әллә кая китәләр. Мөфти юбилеена җыелган кибән кадәр чалмалы карт мөдәррисләр, һич тәгассыб күрсәтми, дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимат ачарга карар бирделәр. Ә зыялыларга килгәч, бу мәсьәлә шул көе эреде.

Без бу соңгы бәхәсне һичкем белмәгән бер яңа ачыш дип түгел, бәлки мәсьәләләр арасында гына сөйләдек. Бу көндә сугыш вакыты булганлыктан, һәртөрле ватани бурычларыбыз күп. Ләкин ул эшләр үзебезнең милли мәсьәләләрдә фикер алышудан тыймаса кирәк. Аның каравы, солых соңында Русиядә булачак яңару дәверенә һәр милләт әзерләнә, безгә дә үзебезнең милли кирәкләребезне сөйләүгә бәлки иртә булмас. Безнең хәл кылырга тиешле берничә икътисади мәсьәләләребез бар. Анысын киләчәктә «Икътисади мөһим мәсьәләләр» бәхәсендә язармын. Бер руханиның үзе тәҗрибә кылган икътисади мәсьәләләрдә сүз сөйләве, әлбәттә, урынсыз булмас.

1916 ел, 20 февраль

[11] 1911 елда татар җәмәгатьчелеге Мөхәммәдьяр Солтанов мөфтилек итүенең 25 еллыгын, 1913 елда Романовлар династиясе вәкилләре тәхеткә утыруның 300 еллыгын билгеләп үтә.

БИЛӘР ҺӘМ ЛАШМАННАР ЯДКЯРЕ

Рәфыйк Шәрәфиев

Дөньяда диңгездән энҗе эзләүчеләр турында язылган маҗаралы китаплар бар. Әле тагын халкының ерак үткәненнән, үз нәселенең тирән тамырларыннан энҗе-якутларга тиң вакыйгалар һәм асыл затлар эзләп табып, шуларны язып калдыручылар да бар. Болары – гыйлем ияләре, иң зур хөрмәткә лаек җаннар.

Әмма халык тарихы шулкадәр зур һәм тирән, аны аз санлы гыйлем ияләре генә өйрәнеп бетерә алмый. Шулай булгач, нишлибез инде? Бу сорауга Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы Рөстәм Бакиров дуслары-теләктәшләре белән бергә язып чыгарган «Безнең тамырлар — Бизнәдә!..» исемле саллы китабында шактый төгәл җавап бирә кебек. Дөресрәге, китап үзе үк әлеге сорауга җавап инде. Кемдер табып биргәнне көтеп тормагыз, мөмкинлегегез булганча, үз нәсел тамырларыгызга үзегез төшәргә тырышыгыз, кеше гомерләре бик кыска, ашыгыгыз, сезнең әле зилзиләле чорларда яшәп гомер кичкән әти-бабайларыгыз югалтканны да эзләп табасыгыз һәм язып калдырасыгыз бар, дия кебек ул.

«Чын тарих, минемчә, гаилә, авыл, район, кыскасы, төбәк тарихыннан башланырга тиеш, — ди галим Фаяз Хуҗин. — *Безнең төп байлыгыбыз — хезмәт кешесе, дияргә яраталар түрәләребез. Ә тарих китапларын алып карасаң — кенәзләр дә патшалар; алар алып барган бетмәс-төкәнмәс сугышлар да асылына тиз генә төшенеп җитә алмаслык сәясәт. Хезмәт кешесенә урын калмый тарихта. Шуңа күрә дә инде үз тарихларын һәвәскәрләр яза»*.

Китапны язып, төзеп, редакцияләп чыгаруда Әнвәр Хәйри, Нәҗип Нәккаш кебек галимнәр, Мирсәй Гариф, Нәкыйп Каштанов, Флёра Тарханова, Шаһинур Мостафин кебек танылган каләм ияләре катнашкан, китапны бизәү, шәҗәрәләр төзүне бу эшнең остасы Нәҗип Нәккаш башкарган. Әйе, Фаяз әфәнде Хуҗинның кереш сүзендә «үз тарихын һәвәскәрләр яза» диелсә дә, бу китап авторларына

Татар Бизнәсе авылы Туграсы (Гербы). Авторы: рәссам-каллиграф Нәҗип Нәккаш

карата «һәвәскәр» төшенчәсе туры килеп бетмидер. Хәер, ут күршеләребез «Башкорт авыллары тарихы»н дәүләт югарылыгында әзерләп, инде күптән бастырып чыгарганда, бездә бу кирәкле эшнең быелга кадәр аерым энтузиастлар кулында кала килүен «һәвәскәрлек» дип бәяләү урынсыз да түгелдер. Бакиров һәм аның фикердәшләре академик басма чыгарырга әзерләнгәндәй, составына белгечләр дә кергән махсус редколлегия төзеп керешкәннәр бу четерекле эшкә. Өч-дүрт елга сузылган тынгысыз хезмәтләре 560 битле, искиткеч бай мәгълүматлы, йөзләгән фоторәсемле гаҗәеп китап булып гәүдәләнгән. Аны «Сүз» нәшрияты дөньяга чыгарган. «Авторлар турында белешмә»не укып хәйраннар калырлык: кемнәр генә юк анда! Элгәре

саналганнарыннан тыш, фикерле һәм каләмле затларның иң асыллары — Разил Вәлиев, Рафаэль Хәкимов, Нурмөхәммәт Хисамов, Роза Туфетулова, Резеда Вәлиева, Рашат Низами, Мәгъсум Гәрәев, Нәсим Акмал, Ркаил Зәйдулла, Шәмсия Җиһангирова, Зиннур Хөснияр...

Эшне «Бизнә» атамасының килеп чыгышын өйрәнүдән башлыйлар. «Башлау» сүзе монда урынсызрактыр, бәлки, чөнки бу атама моңа кадәр дә өйрәнелгән кебек иде инде. Урысча язылышындагы «Бездна»дан чыгып, кайберәүләр аны «төпсез» сүзеннәндер, дип гөманладылар. Бу хакта Марсель Гариповның кызыклы язмасы бар. Янәсе, авыл буласы урынга иң элек килеп урнашкан тугыз бабай урман уртасында бер күлгә юлыкканнар. Аның тирәнлеген белер өчен таяк тыгып караганнар, әмма таяклары күлнең төбенә җитмәгән. Төпсез икән бу, дигәннәр дә, имеш... авылга Бездна исеме ягылып калган. Әллә кайчангы татар бабайлары күл тирәнлеген нилектән болай «урысча» үлчәгәннәрдер, риваятьне язып алучылар бу сорауга җавап бирми. Ә менә галим Әнвәр Хәйри «төпсез»нең нигезсезлеген архив материаллары ярдәмендә ачып салган: баксаң, авыл атамасы элегрәк урысча документларда да «Безна» рәвешендә, уртада «д» хәрефеннән башка язылып килгән икән, ләбаса. Авыл атамасы «Би үзәне» сүзләреннән барлыкка килгән, дип раслый галим һәм моннан соң аны татарча Бизнә, русча Безна дип кенә язарга тиешлеген искәртә. Табиб һәм язучы Нәкыйп Каштанов исә «Бизнә»нең «бәҗәнәк» сүзеннән килеп чыгу, ягъни авылга исем биргән елганың кайчандыр «Бәҗәнәкләр елгасы» дип аталу ихтималын күрсәтә.

Әнвәр Хәйри бу авылга биләр нигез салуын, аларның берсе Үтәш атлы булуын искәртә. Мөхтәрәм галим китапның җитмешләп битен биләгән, архив документлары белән ныгытылган мәкаләсендә Бизнәнең шанлы тарихыннан гаҗәеп мәгълүматлар китерә. Пётр патша заманында Бизнәдә генә түгел, тулаем, бу авыл кергән Сембер губернасында бик күп лашманнар яшәгән, төгәлрәге, биредәге татарлар үзләрен лашманнар дип йөрткәннәр. Лашманлык искиткеч авыр, нужалы хезмәт булган, ул кадәресен безнең чор дәреслекләрендәге «Лашман бәете»н укып та белгән идек. Ләкин лашманлыкның кайбер өстенлекләре дә булган. Шул өстенлекләреннән һәм кайбер хокукларыннан мәхрүм калу куркынычы тугач... хәер, биредә өзек китерергә дә мөмкиндер: *«Казна крестьяны дәрәҗәсендәге крестьяннарны җирле кенәз хакимиятенә күчереп, удел (җир) крестьяны ясарга теләгән канунга (безнең бүгенге федераль финанслаудан җирле хакимият карамагына күчереп кую кебек) буйсынмыйча, башка крестьяннардан, хәтта урыс крестьяннарыннан да аермалы буларак, махсус өстенлекләр бирә торган лашман — урман кисүче (немец теленнән: «лаше» — киселергә тиешле агач, «ман» — шул агачны кисүче ир кеше) дәрәҗәсен, үзләренең динен-иманын, хокукларын саклап калыр өчен шул төбәктәге 40 меңнән артык кешене күтәреп, хаклык байрагы астында берләшеп, хөкүмәткә каршы чыга. Бәхеткә, кораллы бәрелешкә үк барып җитми калган бу баш күтәрүдә алар диннәрен дә, лашман дәрәҗәләрен дә, хокукларын да саклап калалар. Ә үзләрен рәнҗетергә дип килгән кенәзне һәм хөкүмәтнең башка вәкилләрен кулга алып, сак астына утыртып, бикләп куялар. Патша хөкүмәте дә, губернатор да, кенәз Бестужев та һәм хакимиятнең башка вәкилләре дә Бизнә татарлары алдында чигенергә мәҗбүр була».*

Менә нинди булган икән бүгенге Бизнәлеләрнең ерак бабалары! Инде яңарак чорга кайтыйк. Менә 1945 елның 16 апреле. Безнең сугышчылар дошманны куа-куа Нейсе елгасын кичәргә әзерләнәләр. Шулчак дошман

снаряды причалны җимерә. Күпернең йөзмә өч кисәге, кызу агымга эләгеп, түбәндәрәк пехота чыгып бара торган күпергә якынлаша. Сәйфулла Бакиров алар артыннан ташлана һәм, понтоннарны эләктереп, бар куәтенә агымга каршы сөйрәргә тотына. Ярдәмгә килгән Дедунов белән бергә (бүтән иптәшләре сафтан чыккан була), алар теге өч «бәйсез»не причалга китереп ялгыйлар, бик күп сугышчыны һәлакәттән саклап калалар. Сәйфулланың өченче дәрәҗә «Дан» ордены — Нейседа кылынган батырлык истәлеге.

Бизнә — мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗанинең дә нәсел тамыры ялганган авыл икән. Аның әнисе Бибихәбибә абыстай биредәге Иске Чокалы авылыннан булып, әнисе ягыннан бабасы Мортаза, Мортаза улы Мозаффар Бизнәдә имам-хатыйп һәм мөдәррис булып торганнар, вафат булгач, шунда җирләнгәннәр. Әнвәр Хәйри затлы ике нәселнең (Үтәшнекеләр һәм Шиһабетдин хәзрәтнең бабалары) кайсыдыр буында туганлашкан булу ихтималын яза, чөнки «затлы нәселләрнең үз аралашу мохите, үз туганлашу даирәсе булган», — ди ул. Нәкъ шундый туганлашулардан Шиһабетдин Мәрҗаниләр (Шиһабетдин Мәрҗанинең үз чоры хәзрәтләреннән аерым бер мәгърифәтлелеге, киң карашлылыгы һәм рухи хөрлеге менә нинди тамырларга килеп ялгана икән!), соңрак «арбаны йөге-ние белән күтәрә» алган, сигез балалы Атаулла, аның улы, кыю сугышчы Сәйфулла, Сәйфулланың белемле, ил-көнгә игелекле җиде улы, аларның күркәм дәвамчылары үсеп чыккан һәм, сөбханалла, үсә тора.

Китапта Бизнә күршесе Мунчәли авылы да еш телгә алына. Фронтка Сәйфулла Бакиров нәкъ шушы авылның Ләбиб дигән кешесе белән бергә киткән икән. Аннары да гел бергә булганнар, бер-берсенә «туган» дип кенә дәшкәннәр. «Киемнәреңне киптереп кияргә дә өлгермисең бит», — ди торган булган сапёр Ләбиб берөзлексез суда чупырдаучы Сәйфуллага. Мунчәли авылын без әле тагын бер пәһлеван ир исеме белән бәйләп истә тотарга тиешбездер. Губернатор-фәлән генә түгел, Мәскәү-патша теләгенә дә каршы килеп, Татарстанның мөстәкыйльлек референдумын саклап калган мәшһүр прокурорыбыз Сәйфихан әфәнде Нәфиев нәкъ шушы авылныкы лабаса! Суверенлык каһарманнарының кайсы исәпсез мал, кайсы олы дәрәҗә эләктереп тынганда, бер шәхси файдасыз мәңгелеккә китеп барган башбирмәс лашман оныгының исемен дә берәр ничек мәңгеләштерү мәслихәт булыр иде.

Зур әзерлек, һөнәри осталык белән төзелгән һәм язылган бу китапта Чүпрәле төбәгенең данлы шәхесләре, аларның гүзәл эшләре тәфсилләп сөйләнә. Дөрес, Чүпрәлегә багышланган тәүге китап түгел бу, моңа кадәр Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Рафаил Субаевның «Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар», журналист Александр Филипповның «Ерактагы якын Чүпрәледә» исемле һәм башка әйбәт-әйбәт китаплар бар иде. Әмма Бакировлар (китапта Рөстәм әфәнденең абый-энеләре язмалары да бар) һәм аның дуслары ике телдә язып чыгарган «Безнең тамырлар — Бизнәдә!» китабы тулаем төбәк тарихын да, Бизнә авылының меңъеллык үткәнен дә тирәнгәрәк төшеп, бик күп тарихи документларга нигезләнеп, төрле авторлар карашларын истә тотып өйрәнелүе белән бигрәк тә әһәмиятле һәм кыйммәтле. Китап авторлары, шанлы нәсел тамырларының олы гамәлләрен сурәтләү аша, «менә кемнәргә лаек булып яшәргә кирәк», дияргә телиләрдер. ■

Ленар Гобәйдуллин фотолары

Тенеки авылындагы мәчет

Сабаларга илтә юлларым...

13 һәм 26 август көннәрендә редакциябез мөхәррирләре Саба районында иҗади сәфәрдә булды. Фоторепортаж www.beznenmiras.ru сайтында тулырак бирелә.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Таһир Шәрәфиев һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон район китапханәчеләре белән

Сабадагы «Өлкәннәр» клубы

Саба муниципаль районы башлыгы
Рәис Миңнеханов, мәгариф бүлеге җитәкчесе Илфат Шакиров

Тенеки авылы күренеше

Сатыш мәдрәсәсе

Ләбиб Лерон

***

Юлым төшеп тора бу якларга —
Сатыш, Тенеки һәм Юлбатларга...

Юксындыра, тарта Саба җире,
Ымсындыра гүя саба җиле.

Каеннарның тузгый бөдрә чәче...
Каршы ала Сатыш мәдрәсәсе.

Күпме шәхес чыккан мәдрәсәдән...
Тарих калка сыман һәрнәрсәдән.

Бу мәдрәсә күпне белгән, күргән...
Укмасилар монда укып йөргән.

Монда «әнә белән кое казый»
Гөберчәктән — Сөнгатулла[1] абзый.

Чоры белән бергә бик тилмереп,
Белем сөрә Хәсән Биктимеров[2]...

Укый монда Мөхәммәт Галиләр[3] —
Барысы галим һәм дә галиләр.

Тенеки мәчете имамы Мөхәммәтнур Хәсәнов

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Талип Шәмсиев

Сатыш исеме телдән телгә йөргән —
Бу мәдрәсә, әйе, күпне биргән...

...Саба җиле җырлап торган көйгә,
Юлым илтә мине Тенекигә.

Мәчетенә карап торам менә
Мәгъсум ага Хуҗин урамында[4].

Кайчандыр бу мәгълүм Тенекидә
Шәехзадә Бабич[5] булган, диләр...

Саба җиле җырлап торган җирдә
Мин дә булдым — булдым Тенекидә.

Хозурланып йөрдем бу якларда —
Илһам алып кайттым Юлбатлардан...

Бу якларның күркәм кешеләре —
Уңганнан да уңган ишеләре

Күңелләрдә һәрчак сакланыр, дим,
Бу бит... бу бит... Саба яклары! — дим.

27 август, 2015 ел

Юлбат мәктәбенең туган якны өйрәнү музееннан бер күренеш

[1] Сөнгатулла Мәһдиев (1885-1938) — мәшһүр язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең (1930-1995) әтисе. Сатыш мәдрәсәсендә 10 ел укыган.
[2] Хәсән Биктимеров — атаклы артист Шәүкәт Биктимеровның әтисе.
[3] Мөхәммәт Гали (1893-1952) — язучы, Балык Бистәсендәге Олы Елга авылында мулла гаиләсендә туган.
[4] Мәгъсум Хуҗин (1930-2008) урамы — Теники авылындагы күркәм мәчетле урам шушында туып үскән күренекле әдип исемен йөртә.
[5] Шәехзадә Бабич (1895-1919) — шагыйрьнең бер кардәш кыз туганы Тенекигә килен булып төшкән, шушы авылда гомер иткән. Заманында Ш.Бабич, юлы төшеп, Тенекидә булган икән, дигән фараз бар.

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

- Динне кадерләү вә хөрмәтләү аның гыйлемен хасил кылу вә аның берлән гамәл итүдән гыйбарәт. Шушы эшләр булмаганда дин туфрак астында күмелеп торучы алтын вә чүплеккә төшкән энҗе кабилендәй яшерелеп торыр, нуры түгел, үзе дә күренмәс.
- Мәмләкәтләрнең ныгулары өммәтләр вә милләтләрнең сәгадәт берлә дәвамнары исә җирләре киң вә җан хисаплары күп булу берлә түгел, бәлки гыйлем вә һөнәрләре, сәнәгать вә мәгърифәтләре берләдер.
- Әгәр дә динебезнең хөрмәтле булуын, яшьләребезнең мәхәббәт белән шуның күләгәсе астына җыелуларын теләсәк, шул динне үзебезнең яхшы белүебез вә мөмкин кадәр аның белән гамәл итүебез тиештер.
- Мөэминнең нияте гамәленнән яхшырак.
- Үзе фәкыйрь, балалары ач була торып, кулына төшкән малны башкаларга сарыф итмәк яки балаларының маңгай тирләре белән табылган ризыкларны бер афәрин ишетер вә яки юмарт исеме алыр өчен читләргә бирмәк — ахмаклыктыр.
- Кешеләргә бурычы була торып киенеп-ясанып йөрү, хатын вә балаларны бизәндерү, йорт вә җиһаз төзү, табын-табын халык җыеп сыйлау — тәдбирсезлек[1].
- Бәндәләрнең кодрәтләре җитми торган нәрсәләр ялгыз Аллаһы Тәгаләнең үзеннән генә соралырга, чарасыз вакытларда Аллаһы Тәгаләнең үзенә генә ышыкланырга тиешле.
- Гаилә тәшкил итүдән максат нәсел калдыру вә гыйффәтне саклау булып, моның өчен ир берлә хатын арасында өлфәт[2] вә мәхәббәтне дәвам кылу шарт.
- Милләтнең киләчәге — гаиләләрнең төзек булуларына, гаиләләрнең төзек булулары исә ир белән хатыннан һәрбере үзенең тормыш юлдашына хөрмәт күрсәтүенә бәйләнгән.
- Һәрнәрсә дә уртача вә үзенең үлчәвеннән үтеп китмәү яхшы.
- Бездә мирас маллары бүлешкән вакытта варисларның дәгъвалашулары бик күп буладыр. Аз гына нәрсәдән ачу кабартып, бер-береннән үч алу касдына[3] керәләр, үз якыннары зарарына тырышу өчен адвокатлар яллыйлар, мәхкәмәләрдән мәхкәмәләргә йөреп вакыт вә байлык сарыф итәләр, сөтнең каймагын башкаларга ашатып бетергәннәреннән соң, теләр-теләмәс дәгъваларын туктатып, үз араларында килешәләр. Ләкин бу вакытта инде үзләре хуҗа булу касды берлә йөргән өлешләренең күбесе тәләф[4] булып беткән, дәгъваның файдасы читләргә киткән буладыр. ■

---

[1] Тәдбирсезлек — эшнең ахырын уйлап эшләмәү.
[2] Өлфәт — бердәмлек.
[3] Касд — ният.
[4] Тәләф — әрәм-шәрәм.

ДИН ҺӘМ ШӘХЕС

Рәдиф Сәгъди

Равил Гайнетдинов белән мине Ходай Тәгалә 1974 елны Казан дәүләт театр училищесына укырга кереп йөргәндә таныштырды. Милли театрларга сәнгатькәрләр әзерләргә Марсель Сәлимҗанов җыйган төркемгә 180 кеше гариза биргән иде, даһи режиссерыбыз унөч кенә шәкертне сайлады. Шулар арасында Равил дә, мин фәкыйрегез дә бар иде.

Ул тыйнаклыгы, курсташларына ихтирамлы булуы аркасында бездә үзенә карата тиз арада хөрмәт уятты. Гомумән, аның әйләнә-тирәдәгеләргә дорфа, тупас кыланганын, башкалар турында ямьсез сүз әйткәнен хәтерләмим. Ул һәрвакыт курсташ кызларга игътибарлы булды. Шул сәбәпле, энекәштәй күреп, аны яраталар, үз итәләр иде. Чөнки Равил Гайнетдинов укучылар арасында иң яше дә иде әле — Шәле урта мәктәбендә сигезенче сыйныфны бетерүгә үк килеп керде. Безнең бәхеткә, ул чорларда театр училищесында танылган, асыл сәнгатькәрләр остазлык итте. Шулар арасында күренекле артисткалар — Шаһсәнәм Әсфәндиярова актёрлык осталыгына, Асия Хәйруллина сәхнә теленә, республикабызның балет йолдызлары Анна Фёдоровна белән Роза Гавриловналар биюгә, этикетка өйрәтте. Тамила Геннадьевна вокалдан укытты. Барлык укытучыларыбызны бу язмада гына санап бетереп булмас, әлбәттә. Әмма Евгения Германовнаны искә алмыйча мөмкин түгел. Ул тырыша-тырыша безгә француз телен өйрәтте: *«Татар балалары болай да тырышлар, өстәвенә французларның сөйләм көе дә ничектер сезнекенә якын»*, — дип әйтә иде ул. Без инде яраткан укыту-

чыбыз биргән белемне алырга бөтен көчебезне куябыз, ә Равил Гайнетдинов исә ярты елдан бу телдә җиңелчә генә булса да остазыбыз белән аралаша да башлады. Шуңа күрә, соңыннан гарәп телен үзләштереп, зур дин әһеле булуына әллә ни гаҗәпләнмәдек тә. Табигатьтән бирелгән ыспай сыны, матур тенор тавышы да догаларын укыганда күңелләргә җылылык өсти, соклану уята.

Быел 2015 елның февралендә Мәскәүгә баргач, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон белән икәү, җамигъ мәчетенә кереп, сабакташымны күреп чыгарга булдык.

Нәкъ алдан килешенгәнчә, безне сәгать өчтә мөфти кабул итте. Яшь чагындагы калын дулкын-дулкын чәчләрен чал алган курсташым тагын да олпатланган, тавышы тагын да гөрелдәп чыга. Без әле барыбер үзебезне уңайсыз хис итәбез: чишеләсе мәсьәләләрен читкә куеп, безне кабул итә бит! Үзәк мәчеттәге киң колачлы төзелеш эшләре барганлыгын ишетеп беләбез. Чиркәү салсалар, Россия Федерациясенең казнасыннан миллион, йөз миллионлаган ярдәмнәр ыргытыла, ә 700 меңнән артык (анысы да рәсми мәгълүматлар гына) татар яшәгән калада мөселманнарга бер тиен дә ярдәм бирелмәве күңелне рәнҗетә, әлбәттә. Россиягә афәт килгәндә, дошман явы кергәндә генә милли мәсьәләләр искә төшә шул, иң фаҗигале чакта гына, баскынчыларга каршы торырга татар кирәклеге ачыклана. Бу хәл язучы буларак безне бер дә куандырмый, чөнки Россия — урыс халкының гына дәүләте түгел, дистәләгән башка халыкларның да туган җире. Баш мөфти дә бу хәлгә бик борчылуын белдерде. *«Милли мөнәсәбәтләр уңай якка хәл ителмичә торып, нинди бердәм ил төзеп булыр икән? Шуңа карамастан, башка конфессияләр белән дә мөнәсәбәтләрне сакларга тырышабыз, барлык халыкларның дуслыгына, бердәмлегенә өндибез. Кемдер изге эшләребезне күреп шатлана, кемдер кара көя. Башка өлкәләрдә дә мәчет салганда нинди генә комачаулыклар китереп чыгармыйлар. Читада да, Волгоградта да, башка төбәкләрдә дә бу эшебездә аркылы килүчеләр табылып кына тора. Әлбәттә, бу кара рухлы хикмәтләрнең нигезендә гасырлар аша сеңдерелә барган ялган тарих ятадыр. Чит илләрдә дә күңелсез хәлләр чыккалап тора. Кешеләрне, ханнарны мәсхәрә итеп сурәтләргә була, ә инде изгеләрдән изге саналган пәйгамбәребезне хурлау дөрес эшме? Бу хәлгә протест йөзеннән, Чечняга барып та мөнәсәбәтләребезне белдереп кайтырга туры килде. Сүз дә юк, әшәке галәмәтләргә каршы үч алу юлларына каршы без, үзебез дә, динебез дә андый чараларга бармаска өнди. Ләкин үтә дә пычрак хәлләргә битараф та калырга ярамый. Үз сүзебезне бердәм әйтергә тиешбез. Алланың биргәненә шөкер, башка халыкларга дошманлык күрсәткәнебез дә юк, диннәрен дә мәсхәрәләгәнебез юк! Чөнки Бөек Көч — барыбыз өчен дә бер ул! Милләтләрнең дә, халыкларның да бөтен зурлыгы башкаларны хөрмәт итә белүдә. Ходай Тәгаләнең шундый кавемнәре генә зур үсешкә, яхшы тормыш шартларына лаек! Без дә иманыбыз аша шуңа омтылырга тиеш»*, — ди мөфти.

Динебез генә татар халкын зур халык буларак саклап калган. Ә күпме фидакяр, ак муллалар милләтебезгә хезмәткә бөтен гомерләрен багышлаган, кайберләре ошбу изге юлда корбан булган. Язмамның төп өлешеннән читкәрәк китеп, мисал өчен хәзерге Пермь краеның Барда төбәгендә муллалык иткән галиҗәнап Гатаулла хәзрәтне искә алып китмичә мөмкин түгел. Ул үзе Солтанай авылында XIX гасырның икенче яртысында дөньяга килә. Уфада белем ала. Франциянең Сорбонна университетын алтын медальгә тәмамлый. Соңыннан туган җиренә кайтып мәчетмәдрәсәләр, приютлар төзетә. Милләтенә карамастан, ачлы-туклы йөргән ятим балаларны җыеп мәдрәсәләрдә укыта, фәнни белемне дә үсмерләр биредә

ала. Йөзләгән, меңләгән сабыйларны төрмәдән, төрле мәсхәрә ителүләрдән саклап кала. 1917 елгы кызыл инкыйлабтан соң аны кулга алалар, мәчетмәдрәсәләрен, шәкертләргә терәк булган кибетләрен талап, конфискациялиләр. 1918 елда танылган шәхесебезне атарга хөкем ителүен ишеткән халык аны яклап дәррәү күтәрелеп урамнарга чыга. Алар арасында татар белән башкортлар гына түгел, урыс, удмурт һәм башка милләт вәкилләре дә ишле була. Шушы бердәмлек мөхтәрәм хәзрәтебезне үлемнән саклап кала да. Калган гомерен кытлык-мохтаҗлыкта интегеп яшәп, 1928 елда якты дөньядан китеп бара. Ә күпме булган шундый шәфкатьле, изге җаннар татар дөньясында! Габдрәхим Утыз Имәни, Риза Фәхреддин, Кол Шәриф, Батырша, Габделҗаббар Кандалый… Тагын меңләгән милләтпәрвәребезне санап китәргә мөмкин булыр иде!

Без барыбыз да бу дөньяга килүебез белән Ходай Тәгаләдән кала, әниләребезгә бурычлы. Балаларның бәхете дә аналарның аяк астында, диләр бит. Равил Гайнетдин дә үзенең шушы изге юлга кереп китеп, бөтен дөньяга танылган шәхес булып үсүендә иң беренче чиратта газиз әнисе Миңниса апаның тәрбиясен саный. Һәм, әлбәттә, тормыштагы зур терәге булган хәләл җефете Зөһрә абыстайга да бик зур рәхмәт белдерә.

Равил Гайнетдин бихисап мөселман яшәгән Мәскәүдә диндәшләрен кайгыртып яши. Курыкмыйча зур-зур трибуналардан әһәмиятле, кичектерелмәс мәсьәләләрне күтәреп чыга, җиткерә белә! 2009 елның 24 сентябрендә Колонналар залында үткәрелгән «Россия һәм ислам дөньясы: тотрыклылык хакына иптәшлек» исемле халыкара конференциядә чыгыш ясап: *«Күренекле урыс тарихчысы Карамзинның фикере белән килешмичә мөмкин түгел. Ул XIX гасырда ук: «Мәскәү үзенең бүгенге олылыгы белән ханга бурычлы. Һәм бу хәл бөтен Россиягә дә кагыла. Алтын Урда ханнары арасында таркау урыс өлкәләре Мәскәү кенәзлегe тирәсенә берләштерелә»*, — дип белдерде Мәскәүнең Ислам университеты профессоры Равил Гайнетдин. Шул ук конференциянең 28 сентябрендә үткәрелгән пресс-конференциясендә: *«Россия иң баштан ук славяннар белән төрки халыклар көче белән төзелгән — бу минем чын тарихтан чыгып әйтелгән төпле фикерем»*, — дип тә әйтә ул.

Соңгы дистә елда чит республикалардан, башка илләрдән килеп эшләгән мигрантларга карата мөнәсәбәт начар якка юнәлеш алып котырып китә башлагач, 2010 елның 16 декабрендә ачылган Диннәрнең берләштерелгән киңәшмәсендә: *«Әгәр дә төп халык рәтле-башлы эшләми икән, хезмәт хакы алсалар, 15-20 көнгә югалып, станоклар тик торалар икән, андый мөнәсәбәт белән җитештереп булмый. Читтән хезмәт хакы эзләп килгән мигрантлар эчүчелек белән шөгыльләнмиләр, тәртиплеләр, хезмәт сөючәннәр, хезмәт хакы алулары була, гаиләләрен кайгыртып, алган акчаларын туган җирләренә җибәрәләр»*, — диеп мәсьәләгә ачыклык кертте. Әлбәттә, мондый туры сүзләргә дошманлык күрсәтүчеләр дә җитәрлек. Шунысы куанычлы, җирле халыклар арасында тынычлык, бердәмлек, милләтара дуслык яклы кешеләр күбрәк. Бүгенге көндә илебездә низаглар килеп чыкмаган икән, Равил Исмәгыйль улының да өлеше зур. Ил җитәкчесе алдында абруе да бик югары. Шулай булмыйча, төрле халыклар белән тулган Мәскәүдә буталышлар башланса, Россиягә коточкыч афәтләр килергә мөмкин. Чөнки дәүләтнең милләтләргә кагылган төпле программасы да юк, проблемаларны рәтле-башлы алынып чишкәннәре дә, җитди уйланылганы да юк. Әлегә ил тынычлыгы, күп миллионлы урыс халкының һәм башка халыкларның аек акыллы шәхесләре аркасында гына тотнаклы тора. Әз генә ил корабы чайкалдымы, фаҗигаләр килеп чыгуын көт тә тор. Владимир Путин да бу хәлне яхшы

аңлый бугай, дин әһелләренең фикеренә колак сала. Равил Гайнетдин дә Россия Президентына уңай мөнәсәбәттә. Һәм ул шулай булырга тиеш тә. Халык та: «Киңәшле эш таркалмас», — дигән. Мондый четерекле мәсьәләләрне хәл иткәндә Равил Исмәгыйль улының төпле кеше икәнлеген белеп алган ил агалары баш мөфтиебезгә бик еш мөрәҗәгать итә. Һәм бу — бүген генә башланган хәл түгел. Әле 1991 елның декабрендә үк ул чактагы вице-президент Александр Руцкойга иптәш булып, куркыныч сәфәргә чыгып, Гыйрак, Пакьстан, Әфганстанга кадәр барып җитә, мөҗаһитләрнең җитәкчеләре белән Россия гражданнарын әсирлектән азат итүләрен сорап, сөйләшүләр алып бара. Саный китсәң, бик күп инде мөфтинең изге гамәлләре: ислам руханилары арасында бозык дин әһелләрен эшеннән азат итү дисеңме, таркау нәзарәтләрне ныгыту, берләштерү дисеңме…

Кайбер төбәкләрдә мәчет салганда карагруһлар китереп чыгарган низагларны да шәхсән үзе барып җайлап кайта ул. Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламне Франция яһүдләре мәсхәрәләп журналда чыгаргач, Кавказ мөселманнары рәнҗеп баш күтәрде. Бу хәлләр илдә тәртипсезлекләр китереп чыгарырга да мөмкин иде. Равил Исмәгыйль улы, Рамзан Кадыйровка аркадаш булып, Чечняга барып, халык алдында баш иеп, мәсьәләнең асылына төшендереп чыгыш ясады, пычракка пычрак атып кына дөньяны мөртәтлектән арындырып булмаячагын аңлатты. Абруе, дәрәҗәсе дә, тәҗрибәсе дә зур булган илебезнең баш мулласының сүзләренә колак салды Кавказдагы рухи туганнарыбыз. Рәхмәт аларга! Бүгенге көндә гарәп илләре, Төркия белән дә араларыбыз якынаюга, дуслык җепләре ныгуга бара икән, бу изге чараларда да Равил Гайнетдиннең өлеше зур. Аның җәмәгать эшләрендә актив катнашуы, күп кенә ислам динендәге кешеләрнең ихтыяҗын кайгыртуы, шул ук вакытта башка диндәгеләр белән дә дустанә, аңлашып яшәргә тырышуы ил җитәкчеләре игътибарыннан төшеп калмады. Дәүләт алдында кылган изге гамәлләрен искә алып бик күп кенә бүләкләргә лаек булды. Шулар арасында Дуслык һәм Хөрмәт орденнары да бар. 2009 елда IV нче дәрәҗә «Дәүләт алдындагы казанышлары өчен», ә 2014 елда III дәрәҗә «Дәүләт алдындагы казанышлары өчен» орденнары белән бүләкләнде. ■

ӨЙЛӘРГӘ НУР БИРГӘН ДОГА

Айзирәк Гәрәева

Берара дим, чөнки бу хәлләр күзәтелгәнгә әле, күп дигәндә 20-30 еллардыр, шәһәр йорты чүплекләре тирәсендә шамаилләр барлыкка килде. Бүгенге көн белән генә яшәүне һәм матди кыйммәтләрне өстен күргән «внук-внучкалар», иске йортлардан яңа фатирларга күченүчеләр әбиләре, бабалары истәлекләренә шундыйрак «хөрмәт» күрсәтте. Агымдагы елның февраль аенда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан татар шамаилләренә багышланган чаралар уздыру хакында игълан ителгәч тә, аннары Кол Шәриф мәчетендә күргәзмә оештырылгач та «чүплектән алып керәсе калган икән», «чүплектә күргән идем...» дигән сүзләрне әйтүчеләр байтак булды.

Бу да безнең тарих. Аллаһы Тәгаләгә ышануыбызны белдергән, динебез, иманыбыз билгесе булган бабаларыбыз өй догасы дип кадерләгән шамаилләр белән бәйле өйрәнелмәгән тарихның, мирасның бер кызганыч сәхифәсе... Әлбәттә, Бакый Урманче, Нәҗип Нәккаш, Рөстәм Шәмсутов кебек профессиональ рәссам-каллиграфлар, аерым сәнгатькәрләр көче белән шамаил сәнгате башта совет чорында, аннары үзгәртеп кору елларында юкка чыкмады. Халыкчан төрен ясауны исә авылларда инкыйлабка кадәр яшәгән әбиләреннән, бабаларыннан гарәпчәгә өйрәнеп калган буын дәвам итте.

Бүгенге көндә безнең бурыч шамаилнең ни икәнен яшь буынга җиткерү һәм аның яңа үсеш юлларын барлаудан гыйбарәт. Шул нияттән чыгып, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте ел башында «Минем гаиләмнең шамаиле» акциясен башлап җибәрде. Әлеге акция кысаларында беренче мәртәбә татар шамаилләренә багышланган Россиякүләм сәнгать конкурсы уздырылды.

Конкурска тәкъдим ителгән гаилә ядкярләренә аерым игътибар бирелде. Нәзарәт катнашучылардан аларның фотокүчермәләрен һәм кыскача тарихларын язып җибәрүне сораган иде. Гаилә ядкярләрен җыя башлагач, без

үзебез дә көтмәгән бер хакыйкатькә тап булдык. Татар шамаилләре ул, мөселман сәнгатенең бер кабатланмас рухи мирасы гына түгел икән. Алар нык, сабыр, иманлы, зыялы татарларның гыйбрәтле, аяныч язмышы һәм шул ук вакытта үрнәк гамәлләре шаһитлары да. Аларга бәйле вакыйгалар бабаларыбызның яшәү рәвешен, ниятләрен, тоткан юлларын күз алдына китереп бастыра.

ХАҖИ МУЛЛАЛАР МИРАСЫ

Әгерҗе районы, Кичке Таң авылыннан 57 яшьлек **Гүзәлия Хөсәенова** гаиләләрендә сакланган шамаил хакында болай дип язды:

«Мин үземне белә башлаганнан бирле күңелемә бик якын булган гаиләбез ядкяре турында язам. Ул Гарәбстаннан моннан бер гасырдан артык элек кайтарылган. Төгәл елын белүче юк, XIX гасырда булырга тиеш. Үлчәмнәре шактый зур булган (80х60 см) бу шамаилне әтием ягыннан Муллахмәт бабамның әтисе Садыйк бабай хаҗдан алып кайтканы мәгълүм. Әбием Маһинур гарәпчә язылган китапларны җиңел укыса да, бу язуларны укый алмый иде. Аскы өлешендәге язуын да аңлый алмады. Еллар узу белән буяулары кырылган, пыяла астындагы кургаш кәгазе, рамындагы бизәкләре бозылган булса да, безнең өчен бу «яхшы сүз» бик кадерле (әбием аны шулай атый иде). Иң авыр елларда да гаиләбездә сакланып калуы гына ни тора! Нәселебезнең инде алтынчы буынына килеп җиткән ядкярне татар шамаиле дип әйтергә буладыр, минемчә».

Гаилә ядкяре булып 64 ел сакланган шамаил фотосын Казанда яшәүче **Хафизов Шәүкәт Хәлил улы** алып килде.

«Бу шамаилне муллалар нәселен дәвам иткән әтием Хафизов Хәлил Хафиз улы үзе язган. Әтием 1883 елда дөньяга килгән, 1973 елда вафат булды. 1913-1930 елларда Саба районының Олыяз авылында мулла вазифасын башкарган. Ике мәртәбә хаҗ сәфәрен кылган. Әлеге шамаилне әтием 1951 елда язган. Мин ул чакта армиядә хезмәт итә идем. Армиядә 7 ел булдым», — дип сөйләде 88 яшьлек Шәүкәт ага. Шәүкәт абый нәзарәткә шамаил күчермәсен җәмәгате Әнисә апа белән бергә китерде. *«Әти белән әни шулкадәр зыялы, акыллы һәм инсафлы кешеләр иде. Бик матур итеп гомер иттеләр. Шуны да әйтергә кирәктер, ирем бик тә үрнәк муллалар нәселеннән. Шулай ук танылган*

Гүзәлия Хөсәенова гаиләсендә сакланган шамаил

Хәлил мулла Хафизов язган шамаил

язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең туганнан туганы. Ирем әтисе язган шамаилне бик кадерләп саклады», – дип аңлатты Әнисә апа.

«Бездәге шамаилләрне иремнең дәү әтисе Кече Укмас авылының указлы мулласы Госсам Мөхәммәтханов үз куллары белән гарәп хәрефләрен язып, чәй кәгазенә төшереп язган. Бу шамаилләр үткән гасырның алтмышынчы елларында эшләнгән бик тә истәлекле гаиләдә ядкяре булып саклана», – дип сөйләде конкурска 3 шамаил китергән **Зөләйха Ханова**.

Госсам бабай Мөхәммәтханов 1895 елны Саба районының Бичер авылында дөньяга килә. Шушы авылдан дини белем алырга Бохарага укырга дип чыгып китә. 28 яшендә указлы мулла исеме алып кайтып төшә. Ул кайтуга туган абыйсы өйләнеп, тормыш корган була, җитмәсә әле абыйсын паралич та суккан. Әтисе Бохарадан гыйлем туплап кайткан улына: *«Улым, абыең авырый, ул инде моннан беркая китә алмаячак, сиңа китәргә туры килер, син үз юлыңны үзең сайла, кайсы авылга мулла булып китсәң дә, мин риза, бәхил»*, – дип, хәер-фатихасын бирә. Госсам Мөхәммәтханов Нырсы авылында секретарь булып урнаша. Кече Укмаста мөәзин эшен дә башкара, аннары мулла була. Коммунистик инкыйлабның ачы җилләре Кече Укмаска да килеп җитә. Мәчеткә йөрүчеләрне көн саен куркытып торалар, яныйлар. Авыл халкы Госсам мулланы хөрмәт итә, яратып, Шәкерт абый дип тә дәшәләр аңар. Беркөнне авылның иманлы бер бәндәсе Госсам муллага хәбәр җиткерә: *«Шәкерт абзый, бүген сине төнлә алырга киләләр, кач!»*

Юлга дип ашык-пошык җыелган өсбаш киемнәрен, ризыкларын капчыкка тутыра да мулла абый, төн җиткәнен көтә. Бу 1930 елның җәй ахыры була. Менә Госсам хәзрәт өенең ишеген шакыйлар. Шикләнергә урын калмый, хәбәр дөрес булып чыга. Кулына капчыгын алып, тәрәзәдән бакча ягына сикерә. Хатыны Мәрфуга ишекне ачканда Госсам мулла инде эзен югалткан була. Ул дөм-караңгы төндә җәяүләп Казанга юл тота. Авылда аның көмәнле хатыны Мәрфуга, яшь балалары Асия, Назыйф, Габделәхәт кала.

Бәладән башаяк дигәндәй, Казанда озак тоткарланмый, ул тагын юлга кузгала. Казаннан Сахалинга хәтле барып җитә. Алты ел читтә йортсыз-җирсез, гаиләсез яшәп арыган мулла кабат Укмаска кайта. Авылда кладовщик булып

Госсам мулла Мөхәммәтханов шамаиле

эшли башлый, әмма озак тоткарланырга туры килми шул, кабат эзәрлекли башлыйлар. Янә 1939 елда гаиләсен калдырып чыгып китәргә мәҗбүр була. Бу юлы Ленинград шәһәренә юл тота. Анда заводка эшкә урнаша. Сугыш башланырга ике ай кала үзенең туган ягына – Кече Укмаска кайтып егыла. Аннары инде сугыш юлларын үтәргә туры килә. Ул совет чорында да ислам диненең кодрәтен арттырып, укмаслыларны бергә җыеп җәмәгать, җомга, гает намазларын укыткан, мәрхүмнәрне соңгы юлга озатып яшәгән. Шамаилләре исә рухи мирасыбызның бер кабатланмас өлеше.

Конкурска Татарстаннан читтә яшәүче татарларга да мөнәсәбәтле шамаилләр килде. Казанда яшәүче **Ринат Вәлиуллин** юллаган шамаил фотокүчермәләре шуны раслаучы бер мисал. *«Әлеге татар шамаиле 1957 елда әтием Вәлиуллин Әнвәр һәм әнием Вәлиуллина Мөгалимәгә никахларына бүләк итеп бирелгән. Әти-әнием Казакъстанның Булаево шәһәрендә яшиләр. Шулай ук Казакъстанның Петропавловск шәһәрендә «Дин-Мөхәммәд» мәчетендә татар шамаилләре саклана. Аларны мәчеткә мәхәллә халкы бүләк итеп китергән»*, – дип хәбәр итте ул. Кызганыч, юллар ерак булу сәбәпле алар Татарстанга әлегә килеп җитмәде.

Шулай ук Түбән Новгородтан **Надия Фәхретдинова** өйләрендә сакланган шамаил фотосурәтен җибәрде. Моннан тыш Башкортстаннан, Чувашстаннан

Түбән Новгородтан Надия Фәхретдинова

Гата бабай шамаиле

һәм башка төбәкләрдән китерелгән шамаилләр Кол Шәрифтә оештырылган күргәзмәдә урын алды.

ОНЫКЛАР БАБАЛАРЫ БЕЛӘН ГОРУРЛАНА...

Шамаилләргә кагылышлы конкурс кысаларында шамаилче картлар буынын дәвам итүче яшьләр язып җибәргән хатлар рухи мирасыбыз алга таба да саклануга бер өмет бирде кебек. Әйтик, Әлки районының Татар Борнае авылыннан килгән язма авторы **Илдар Минсәгыйровка** әле бары 10 яшь.

«Бездәге шамаил ничек барлыкка килгәне турында миңа әни сөйләде. Аңа 100 елдан артык. Минем әбиемнең әнисе — Фәрдия әбинең әтисе Гата бабай бик укымышлы кеше булган. Ул пыялага шамаилләр язган. Ул вакытларда авылда бик күпләрнең өйләрендә минем бабай ясаган шамаилләр эленеп торган. Ә менә бездә саклана торганын Гата бабай кызына никахка бүләк иткән. Әбиемнең әнисе озын гомер кичерде, 96 нчы яшендә мәрхүм булды. Менә дүртенче буын инде аның кадерле әйберләрен ядкяр итеп саклыйлар. Безнең өчен шамаилләр бик кадерле. Шулай ук безнең гаиләдә борынгы Коръән һәм аның тәрҗемәсе саклана. Аларны әбием әниемә тапшырган. Әнием гарәп телен өйрәнгән һәм шуңа күрә дә ул аларны укый белә...»

Тагын бер онык — **Илдар Таҗиев** — Питрәч районы Шәле авылыннан килде. Нәзарәтнең икенче катына бабасы ясаган шамаилләрне ул бик кадерләп кенә тапшыды: *«Менә бу миңа дигәне, тегесе туганыма... Боларын күршеләрдән сорап алдым. Югала күрмәсен инде, алайса баш бетте... Кайсы елларда ясалганнарын бабай да хәтерләп бетерми. Артларына ябыштырылган газетлардагы даталарга карап чамаладым...»* Ул шулай ук шамаилләр белән бергә бабасы хатирәләре теркәп барылган хат китерде.

Бабасы – имам хаҗи Габделхак Бикмуратов 1927 елның гынварында дөньяга килгән. Әтисе Габделкаюм абзый балта остасы булган, әнисе Мәликә апа Коръәнне бик шәп укыган. Сугыш башланганда Габделхакка 14 яшь була. Ишле балалы гаилә ачлык җәфасын күргән. Сугыш беткәч, Габделхакны Кемерово өлкәсенә хезмәт колониясенә җибәрәләр. Аннан отпускыга киптереп

кайтаралар. Яңадан колониягә бармаган өчен аны 4 айга Раифа монастырендагы балалар колониясенә утырталар. 1951 елда авылына әйләнеп кайткач, ул Разия исемле кызга өйләнә.

Хәзрәт оныгына сөйләп яздырган хаттан бер өзек: *«Ишәйдек — Мансур улым туды, гаиләне туйдырырга акча кирәк иде, эш барын бар – ә акча түләмиләр. Булган акчаларыбызны җыеп, эш кораллары сатып алдык, үзем корган верстакта догалар (шамаилләр) рамы ясый башладым. Кибеттә пыяла юк, акча да юк. Колхоз фермасына менеп, ватык тәрәзәләрнең пыялаларын алып төшеп, кисәкләргә кисеп куя идем. Язар өчен буяулар да кирәк, хатыным Разия кайдандыр битум алып кайтты, аны бензинда эретеп буяуга әйләндердек, төсле майлы буяуларны Казаннан сатып алып кайта иде. Коръән аятьләре пыялага дөрес төшсен өчен башта кәгазьдән трафаретлар ясыйм. Пыялага бронза, көмеш төсле буяулар белән язам да буявы кипкәч, битум белән буяп-каплап куям, кайсы урында төсле фольга да кулланам. Кешенең күңеленә хуш килсен, Коръән аятьләре аңлаешлы булсын дип, шамаилләремдә мәчет, табигать рәсемнәре ясый идем».*

Акча булмаганда шамаилләрне сатып, шуның белән көн күрә, гаиләсен карый ул. Күбесен бушка да өләшә, бүләк итә. Шуңа күрә дә бүгенге көндә Шәледә һәм тирә-юнь авылларда ул ясаган шамаилләр өй күрке булып саклана.

Хатирәләрдән тагын бер өзек: *«Соңрак, инструментлар күбәйгәч, башка авылларга йорт салырга йөри башладым. Яңа йортның хуҗалары догалыкларны сатып алмасмы дип, үзем белән алып бара торган идем. Кайвакыт: «Шамаилләрне кая куялар соң?» — дип сорыйлар иде. Ул вакытта дин тотучылар аз, халык гарәпчә белми, өйрәнмәгән. Мин ярый әнидән өйрәнеп калдым, күбесен аңлатырга тырыша идем. Менә шулвакытта вәгазьләр сөйләп, Гает намазларын укып йөргәнгәдер инде (мәчетләр юк иде әле, кеше өендә җыелышып укыйбыз), имамыбыз картайгач, мине имамлыкка кыстый башладылар. Булдыра алмам, миннән олылар бар, дип каршы килеп карасам да, 1982 елның 6 апрелендә җомга көнне, кискен генә «син буласың» дип, картлар сайлап та куйдылар үземне. Мәет җирләү, балага исем кушу, никах уку — барлык вазифа минем өскә йөкләнде. Шамаилләрне азрак ясый башладым, соңрак бөтенләй дә ясаудан туктадым...»*

ШАМАИЛ СӘНГАТЕН АЛГА ТАБА САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?

Казандагы «Мәрҗани йорты»нда оештырылачак Ислам музеена куяр өчен, беренче булып, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Тынычлык» мәчете мәхәлләсендә саклана торган татар шамаилен бүләк итте. Башка имамнарыбыз мөфтигә кушылдылар, шулай итеп конкурс тәмамлангач та дистәләгән тарихи татар шамаилләре тупланды һәм бөтен республика күләмендә мөфтияттә җыелуын дәвам итә. Шулай ук шамаилләр белән бәйле мөфтият проектлары республика җитәкчелегендә зур кызыксыну уятты.

Яшерен-батырын түгел, кызганыч, бүгенге көндә шамаилләрне ясау түгел, аларны укый алучылар да бик сирәк. Шулай да татар халкына гына хас шушы рухи байлыкны ничек сакларга һәм киләсе буыннарга җиткерергә соң? Нәзарәт тарафыннан уздырылган «Бүгенге заман татар мәдәниятендә шамаил сәнгатен саклау проблемалары» дип аталган түгәрәк өстәлдә төрле фикерләр яңгырады. Шуны әйтергә кирәк, сөйләшү Республика Иҗтимагый палатасы һәм Россия ислам университеты белән берлектә оештырылды. Шул чарада катнашкан кайбер белгечләрнең фикерләре белән уртаклашабыз.

Рөстәм хәзрәт БАТЫР,
Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары:

● Шамилләрнең тәрбияви роле әлегә кадәр бәяләнеп бетмәгән. Шамаил балачактан аңыбызга динне, безгә генә хас үзенчәлекләрне, кыйммәтләрне сеңдерә. Менә шушы яктан чыгып караганда, ул татар халкына үз-үзен, динен, дини һәм милли рухын саклауда бик булыша. Әлбәттә, без бу хакта яхшы беләбез. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан «Минем гаиләмнең шамаиле» акциясе ел дәвамында алып барыла. Бүгенге көндә татар шамаилләренә багышланган каталог әзерләнә.

Рөстәм ШӘМСУТОВ,
Татар шамаиле галереясы директоры, танылган каллиграф:

● Каллиграфлар альбомын әзерләргә кирәк. Каллиграфлар язган Коръән сүрәләре, аятьләр булырга тиеш. Альбомда каллиграфның исемен, нинди аять язылганын һәм мәгънәсен дә күрсәтергә кирәк. Рәссамнар гарәпчә белми, алар бу язуларны шамаилләр ясаганда кулланыр иде. Каллиграфлар альбомында язу стиле татарча булуы һәм аның нәзарәт тарафыннан тикшерелүе, раслануы мөһим. Бу яңа шамаилләрне ясаганда, Коръән сүзләрен язганда хаталар җибәрүдән саклар иде. Шулай ук шамаилләрнең сыйфатын да күтәрер иде.

Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
сәнгать фәннәре докторы:

● Шамаил — традицион мөселман сәнгате. Без аны рәсем яки сынлы сәнгать, дип әйтә алмыйбыз. Сынлы сәнгать татарларда XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында җәдитчеләр тәэсирендә барлыкка килә. Ә менә декоратив ислам сәнгате мең ел дәвамында яши. Идел буе төбәгендә ул VIII гасырдан башлана. Коръән сүрәләре язылган такта паннолар шул хакта сөйли. Шамаилне декоратив сәнгать төре, дип әйтә алабыз, аның нигезендә каллиграфия ята. Сүрәләр, татар мәкальләрен, Тукай шигырьләрен язганнар. Алар янына татар бизәкләрен, архитектура корылмаларын, мәчетләрне төшергәннәр. Бары тик татар халкына гына хас шамаил төре барлыкка килгән. Бүгенге көндә дин әһелләрен әзерләүче Россия ислам университетында да һәм сәнгать уку йортларында да шамаилләрне өйрәтергә мөмкин. Тарихтан мәгълүм, шамаилләрне, шулай ук кабер ташларын муллалар ясаган. Кызлар ләүхә чиккәннәр. Татарларда Коръәннән төрле аятьләр бизәп тукымага чигелә, еш кына кысага алына һәм диварга эленә. Ләүхә – шамаилнең бер төре. Безнең бабаларыбыз, әбиләребез динне белгән. Коръәнне белмичә ничек шамаил ясыйсың?! Шамаил үзе дә синтетик, ягъни төрле юнәлешләрне берләштергән сәнгать һәм аны ясаучы да киңкырлы оста булырга тиеш. Аннан гарәп телен дә, Коръәнне дә белү һәм рәсем ясау осталыгы да сорала. Без менә шуңа омтылырга тиеш. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Җавапта Уйгырмыш әйтте: — И, кардәш,
Моңайттың син мине, агу булды аш.

Син әйткән сүзләрне тыңлап, илбиккә
Барып, тотыныйм, ди, бүгеннән эшкә.

Ничек белим аның юлын-тәртибен,
Каян өйрәним соң эшнең рәтен мин?

Керү-чыгулар һәм утырыш-торыш
Тәртибен белмәгән ир калыр коры.

Ни ди, ишет, хезмәт рәтен белгүче
(Ул әле әйтә тик сернең бер очын):

«Бийгә хезмәт итү юлына бассаң,
Телең-күңлең күзәт, сүзеңдә бул сак.

Сәрай хезмәтенең юсык-юрыгын[1]
Белеп бетсәң генә эшли алырсың».

Күп ара мин тордым кешедән ерак,
Юсык-юрык белмим, холкым кырысрак.

Ничек бийгә кылыйм мин хезмәт-табуг,
Минем өчен монда бикледер капу.

Нигә син «илбиккә хезмәт ит», дисең,
Хәлемә карамыйчарак көчлисең.

Җавапта Үгделмеш әйтте ки: — Тыңла,
Сүземне, и, туган, тискәре борма.

Синең белмәвеңне бий күптән белә:
Утырса да хуш, ди, торса да үрә.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ТӘФСИЛЛЕ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте бу сүзен:
— Алай да, шәп тугыл, и, холкы төзем.

Ярашыр микән соң син дә һәм мин дә,
Йөресәк юсыкны белмичә бер дә.

Бу ил тоту, халык оештыруны
Бәкләр башкардылар, беләсең шуны.

Ил-көн яшәтүне, бәкләрнең эшен,
Юсык вә зан илә башкара кеше.

Моны башкарырга бийләр алынды,
Оештырды киңәш, белем алуны.

Ни шәп сүз әйткән бер халык башчысы,
Белемле һәм ушлы дөнья эшчесе:

**Керү-чыгулар һәм утырыш-торыш
Тәртибен белмәгән ир калыр коры.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.

[1] Юсык-юрык — «монарх сараенда субординация, аралашу кагыйдәләре». Юсык-гомуми кагыйдә, заң-катгый закон.

**Табын көн-төн бары Аллага гына,
Ачык тот капкаңны аңарга гына.**

Бергә булса гына бий биегәя,
Үч аларак, дошман явын җиңәлә».

Без инде шәп низам-канун төзесәк,
Кагыйдәләр язып кына йөресәк…

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавабында: — Кардәш, —
диде Үгделмеш, —
Бу бик хәтәр түгел, эшләнерлек эш.

Низам-кагыйдәне мин бераз беләм,
Мин әйтеп торыйм — син шуннан өйрән.

Белмәгән низамны өйрәнсә кеше,
Теләгенә шиксез ирешер беркөн.

Ничек әйткән берәү — ачык фикерле
(Бу сүзне тотмаган — почык белемле):

Кеше туа белмәс, тора белер, ди.
Сөйли башлар берни белмәгән тел, ди[2].

Бәби берни белмәс һәм галим булыр,
Белем алгач күп эш кулыннан килер.

Җавапта Уйгырмыш әйтте: — Бу синең
Теләгең булса һич сүзем юк минем.

Мине чакырасың икән илбиккә,
Бераз аңлат, ул соң ни хезмәт икән?

Керерме күңелгә — сүзеңне тыңлыйм,
Өйрәнерлек микән, хәзерлек кылыйм.

Миңа сөйлә — низам, кагыйдә ничек?
Сана тәртип илә баплап һәм печеп.

Җавапта Үгделмеш әйтте: — Син төгәл
Туры сүз сөйләдең, ә бу — изге фал.

Ерак иде шуннан юнәлгән юлың,
Хәзер дөрес якка бугай борылдың.

[2] Шундый мәкаль бар.

**Миргән икән, укчы — җәяче була,
Күндәм, тугры икән, пичәтче була.**

Мин әйтим, син ишет, ләкин син үзең,
Каты уйлан, өйрән, яктырсын күзең.

Әгәр инде тагын уйланыр булсаң,
Юкка телдәрләнмә, тыңла да уйлан.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ВӘГАЗЬЛӘРЕ
1. БИЙЛӘРГӘ ХЕЗМӘТ

Ике төрле була хезмәткәр кеше
(Эшләсәң көннән-көн ырыйдыр эшең):

Берсе яшьлегендә үк була эштә,
Икенчесе олы яшьтә керешә.

Болардан, әлбәттә, икесе дә хуп,
Ләкин яхшырагы яшьтән юл табу.

Хәзер мин бу хакта сөйлимен икән,
Әйтим әле сүзне баштан-кечедән.

Фәһемсез ирешсә зур дәрәҗәгә
Остазының башын да ашар, мәгәр.

Сүзне уртага куй, соңы уң булыр,
Төгәл уйласаң, уй карарлы булыр.

Балама юл ачыйм, дигән кемсәләр
Яхшы булыр эшкә яшьтән бирсәләр.

Өйрәнер йоланы, канун-юрыкны,
Керә-чыга белер, булса холыклы.

Тырыш өлгер булса, иртәрәк торса,
Тыныч-түзем булса һәм телен тыйса,

Үз эшен башкарса тиз-тиз йөгереп,
Һәрнәрсәне белсә ишетеп-күреп,

Олуг-өлкәннәргә күрсәтсә хезмәт,
Телдәрләнмәсә һәм торса сүзендә,

Һәрчак шул сыйфатта башкарса эшен,
Булыр ул илбиккә кирәкле кеше.

Иң тәүдә — илбиккә кереп чыгучы,
Кешеләр гарызын ирештерүче.

Илбик ышанычын шулай аклагай,
Зуррак урын ала хезмәтче малай.

Миргән икән, укчы — җәяче була,
Күндәм, тугры икән, пичәтче була.

Кыланышы ипле һәм матур йөзле
Икән, сакый булыр, и күңле төзем.

Зирәк булса, эшләр бөтекче булып,
Хәзинәче булыр, хисапны белеп.

Кайсын сайласа да егет боларның,
Яратып эшләсә, китәр остарып.

Сораганда сөйлә, чакырганда кер...
Сәламәт яшә һәм табырсың кадер...

Ни ди озак еллар хезмәт иткән зат,
Теләк-максатына шулай җиткән зат:

«Бий катында торып хезмәт кылганда,
Бер дә юкка дәшмә һәм кыймылданма.

Үзеңне ипле тот, юрыкка буйсын,
Телең-күңлең тугры, сүзең нык булсын.

Басып торган чакта бигең каршында
Күзең җиргә тегеп, колак сал, тыңла».

Төзек торсын гәүдәң, аяклар — туры,
Уң кулың өстендә булсын сул кулың.

Ишектән кергәндә уң аяк алдан.
Бийнең сөйләгәнен яхшылап аңла.

Гарыз сөйләгәндә уйнатма кулны,
Кирәксә йөксен, чүк, тик бул ягымлы.

Үзеңне пакъ тот син барча яктан да,
Бәклек ул — арулык, шуңа ястана.

Кыя бакма үзең уңга һәм сулга,
Имәнеп тор[3], ләкин дикъкатьсез булма.

Сорасалар, сөйлә дөресен генә,
«Әйтеп бир» диелсә, җиткер төп-төгәл.

Эчемлекләр эчмә һәм йөрмә бушка,
Явыз-юньсезләрдән кач һәм сүз кушма.

Кирәксә, ишетмә кайбер сүзләрне;
Күзләрең күрсә дә, үзең күрмәдең.

Менә шулай хезмәт иткән кешенең
Эше бара, коты арта көннән-көн.

Кайсы сыбайлылар башлыгы булыр,
Кайсы илбикнең үз атчысы булыр.

Кайсы гаскәр башы һәм кайсы хаҗип,
Кайсы галим булыр, китаплар язып.

Кайсы киңәш бирү белән дан алыр,
Һәм дә илбикләрнең дусты саналыр.

---

[3] Имәнү — «курку», хәвефләнү.

Кайсы *инаныч* бәк, кайсы *чагры* бәк,
Кайсы *күртәген* бәк, кайсы *чаплы* бәк[4].

Кайсы коллар башы — *чураман* була.
Тагын әллә күпме бардыр титуллар.

Бу корларга[5] кереп китәлгән ирләр
Җитешле тормышка бер ирешерләр.

Бий корына керсә инде хезмәткәр,
Үзенең эшен бик тырышып үтәр.

Түбән булса, ләкин, күңеле-теле
Яхшук әшәкелек эшләр бий колы.

Бер гыйлем иясе бик дөрес әйткән:
«Тиешсез кешене корга кертмәскә».

Яхшы әйткән берәү (булган белемле):
«Бәгем, белексезгә бирмә кулыңны».

Фәһемсез ирешсә зур дәрәҗәгә
Остазының башын да ашар, мәгәр.

Шулай икән, бәкләр хезмәткәрләргә,
Фәһеменә күрә бирә дәрәҗә.

Сына колны, аның холык-фигылен,
Файдасына күрә күтәр кимәлен.

Бийгә тугрылыклы булсын кол, аек,
Бий мәрхәмәтенә шундый кол лаек.

Ни ди, ишет әнә низам биргүче –
Бийгә канун язып көнен күргүче:

«Дәрәҗәдә булса да кол — кол гына:
Үзен юксәлтүче бийгә буйсына.

Ни юньсез булса да ул, бийдә — бийлек,
Хезмәткәр исменнән бий аты биек.

Бийләре үзләрен күтәргән затлар!
Биек бел бийеңне, исемен сатма.

**Бәкләр сүз сораса, сиңа күз тегеп,
Сүзеңне көттермә, зирәк бул, егет.**

*Үчәшмә[6] бий белән беләмән булып
Сүзләрен сөйләмә кешегә килеп».*

Бийләр алар путлар, пут кулы озын,
Бий күзләре — утлар, көйдерә үзе.

Бийләр заманасы бу, шуны белеп
Эш итсә, ир яшәр сөенеп, көлеп.

Шәп әйткән бийләрне сынап белгән ир,
Бийләргә хезмәттә күтәрелгән ир.

(Яхшы нәрсә галим кешенең сүзе,
Галим сүзе — бәрчен ефәкнең үзе).

«Бийләр күзе сиңа караса көлеп
Сөенмә син шуңа, китмә киерелеп.

Хезмәтем күп димә, күңлең күтәрмә –
Көтмәгәндә бийләр чәпчеп китәрләр».

Олымы-кечеме, йә баһадирмы,
Хезмәтче — хезмәтче була барыбер.

Каты тор хакында бийгә хезмәттә,
Ничек тә чыкмаса тиешсең рәттән.

Сине бәкләр ничек якын тотмасын,
Түбән чыгышыңны һич онытма син.

Алар ничек кенә хөрмәт итсә дә,
Сине кимсетергә җитә бер сәбәп.

Алар бер су була һәм бер ут була,
Көлгәч елатырлык бер минут була.

Бик якын барма өч ошбу нәрсәгә:
Янган ут, ташкын су һәм дә бәкләргә.

**Тыңласалар, бәян ит белгәнеңне,
Сүзеңне киссәләр, куй сөйләвеңне.**

[4] Инаныч бәк — аеруча мөһим эшләр башкаручы бәк; чагры бәк — лачынчы бәк; күртәген бәк һәм чаплы бәкләрнең функцияләре хәзер ачык түгел.
[5] Кор — дәрәҗәләре буенча тиң утырдашлар түгәрәге.
[6] Үчәшү — «үчләшеп карышу һ.б.ш.», кәй — «начар, мәгънәсез» — болар татар сөйләшләрендә еш очрый торган сүзләр.

**Әгәр бәкләр ашка чакырса сине,
Әдәп илә аша — яхшы бел моны.**

Арысланга, күрче, бий халкы охшаш:
Көе килсә ефәк — йоннары йомшак.

Әгәр пошынсалар, башың кисәрләр,
Кантамырны өзеп каның эчәрләр.

Пошынган бәгеңә якын да барма,
Анык мескен хәлдә калырсың анда.

Сораганда сөйлә, чакырганда кер…
Сәләмәт яшә һәм табырсың кадер…

Ни ди, ишет, берәү — тотанаклы ир
(Бийгә кереп, сөйләр арадашчы бер):

«Кереп тор», дисә бий — бу бик зур хөрмәт,
«Чыгып тор», дисә — бу сүгену, димәк.

Йөзеңне, күзеңне сакла, тыныч бул,
Тотанаклы кеше хөрмәт таба ул.

Син өч хәлдән ерак тор, саклан, яме:
Бере холыксызлык, кисеп әйтәмен.

Тагын бере — ялган, бере — соклык ул,
Боларның сәбәбе — намус юклыгы.

Үзеңне пакъ тот син барча яктан да,
Бәклек ул — арулык, шуңа ястана.

Сәрайда ачык бул һәм йөре рәтләп,
Хөрмәт иткән затның үзен хөрмәтләп.

Кукыраеп, кулың селкеп тә кермә,
Шулай ук кулга-кул тотынып йөрмә.

Утырыр чагыңда урыныңны бел.
Корга чакырсалар, утырдашлык кыл.

Какыру, кикерү, каты төчкерү,
Кеше арасында юньсезлектер ул.

Янә аяк сузма һәм ятма кырын,
Көчле тавыш белән көлмә кычкырып.

Үзеңне онытма кем икәнеңне,
Онытсаң, мәҗлестән тиз китәреңне.

Үзеңнән олының сүзен сөйләмә,
Сүзеңне сайлап әйт — озак уйлама.

Йөзең булыр якты — сөйлә бик белеп,
Бары яхшы якка ачылсын телең.

Эчеп һичберкайчан кермә сәрайга,
Эчкече — чи утын, эшкә ярамас.

Түбәндәге өчтән бик сакланмасаң,
Игътибарсыз йөрсәң, язарсың баштан.

Беренчесе — бәкләр сүзен тотмасаң,
Җаның-тәнең белән хезмәт итмәсәң.

Икенчесе — булсаң әләкләшүчән
(Әләкче әләккә тиз әләгүчән).

**Ашамлыкка уң кул илә сузыл да,
Бисмилла әйтергә онытма шунда.**

Өченче — сәрайда тыйнак йөрмәсәң,
Үзеңне зур тотып, сәлам бирмәсәң.

Бу өч эшнең берсен кылган кешенең,
Ни биек булса да, башы киселер.

Нигезле булган эш, и, сабыр дустым,
Тәмаман беткәнче эшләнер тып-тын.

Түрдән узып, рәттә утырганыңда
Кеше узган чакта бас аягыңа.

Бәкләр сүз сораса, сиңа күз тегеп,
Сүзеңне көттермә, зирәк бул, егет.

Тыңласалар, бәян ит белгәнеңне,
Сүзеңне киссәләр, куй сөйләвеңне.

Әгәр бәкләр ашка чакырса сине,
Әдәп илә аша — яхшы бел моны.

Ашамлыкка уң кул илә сузыл да,
Бисмилла әйтергә онытма шунда.

Дәвамы бар ■

Хөрмәтле укучылар! XVII гасырның ошбу ядкярен сезнең хозурга берникадәр кыскартып тәкъдим итәбез. Кыскарткан урыннар квадрат җәя белән билгеләнде. Кыйссаны тулысынча **www.beznenmiras.ru** сайтында укырга мөмкин.

Редакциядән

КЫЙССАИ ТАҺИР ИЛӘ ЗӨҺРӘ

Әүвәл заманда Татар илендә Бабахан исемле бер хан үткән. Иле киң, байлыгы мул, тәхете нык, бөтен дөнья йөзендә дан-дәрәҗәсе бик тә югары булган. Гаскәрләре күп, йорты тыныч, барлык эшләрендә тик уңыш күргән, бәхетле патша булган ул. Әмма язмыш шомлыгы аны да читләтеп үтмәгән, аның да бу зур бәхете китек булган: баласы юк икән. Бу җитешсезлеккә ул бик борчыла, кайгыра, һәрчак: «Мин үлгәннән соң бу таҗ-тәхетем, бу сарайларым — байлыкларым җиде ятка каламы?» — дип бик уфтана икән. Бабаханның вәзирләре арасында Баһир исемле бик акыллы бер вәзире булган, аның да баласы юк икән. Баһир — кара халык арасыннан чыккан, үзенең акылы, сәләте белән генә бу югары дәрәҗәгә күтәрелә алган кеше икән. Икесе дә газиз бала йөзе күрмәгәнгә, хәсрәтләре уртак булганга, үзара якынлашып, Баһир ханның иң якын дусты, бердәнбер сердәше, баш вәзире булып киткән.

Беркөн Баһир, гадәтенчә, бу мәңге җуелмас хәсрәтеннән арып йокыга талганда бер төш күрә. Алар хан белән Кәгъбәтуллага хаҗга барганнар имеш тә, бу изге җирдә үзләренең шул зарларын әйтеп, теләк теләгәннәр, имеш. Аларның ул теләкләре, ниһаять, кабул булган, имеш. Баһир йокыдан бу моң-хәсрәте юкка чыгып, ниндидер бер эчке куаныч белән уяна. Ул шунда ук бу сөенечле хәбәрне сөйләргә хан сараена йөгерә. Аны тыңлап, хан күңелендә дә өмет чаткысы кабына. Ул шунда ук шатлыгыннан: «Әгәр икесе дә ир бала булсалар, балаларыбыз гомерлек аерылмас дус булырлар; кыз балалар булсалар, ахирәтләр булырлар. Әгәр берсе — ир бала, ә икенчесе кыз бала булсалар да, гомергә бергә булсыннар, бер-берсенә яр булсыннар, өйләнештерәбез», – дип вәгъдә бирә. Ант итешәләр. Антны бозучы булса, ил алдында хур булсын, дип сөйләшәләр. [...]

Балалары дөньяга килгән көнне хан белән вәзир өйдә юк, ерак кыр-япаннарга — ялга, — ауга киткән иделәр. Балалар тугач та, елгыр атларга нәүкәрләр (янсакчылар) атландырып, сөенче алырга, вәзир белән ханга хәбәрчеләр җибәрделәр. Хәбәрне ишеткәч тә хан: «Кыз атасы гына булганмын икән... Ярар, бөтенләй баласыз калуга караганда, кыз балаң гына булса да...» – дип, уйланып алса да, чын күңеленнән шатланды. Вәзир хатынының бала дөньяга китерүе дә кыска бер мизгелгә ханны сискәндергәндәй итте: «Вәзир теге сөйләшүне онытмаса?..» «Ярый, киләчәк — юл күрсәтерме», — дип, ул вәзирне дә углы белән котлады. Яннарында булган бар алтыннарын алар сөенчегә хәерчеләр, нәүкәрләр өстенә чәчтеләр дә, шунда ук атларына менеп, кайту юлына атылдылар. Узыша-узыша, атларын камчылап, җан фәрманга куалар. Әле, хан аты алга чыга, ул да түгел, вәзир аты аны куып үтә... Язмыш хан антын сынамакчы иткәндерме, бәла аяк астыннан килеп чыга: вәзир аты, һич сәбәпсез, тигез җирдә сөртенеп егыла да, ат башы аша очып төшкән вәзир, иңсәсе өзелеп, шундый көтеп алган баласына бер күз дә салалмыйча, шул мизгелдә үзе һәлак була...

Хан Бабахан зур иттереп, — бөтен илне гөрләтеп, бәби туе үткәрде. «Бу балага үзегез исем табып куясыз», — дип ул шул туйда бала исемен илдән сайлатты. Халык кызның исемен Зөһрә дип атады. Баланы карарга, тәрбияләргә дип, йөз пакизә җария (хезмәтче кол кызлар) билгеләделәр. Дуслыкларын искә алып, хан вәзир угылын — Таһирны да шул ук җарияләр тәрбиясенә бирде. Бу ике сабый бер-берсенә шулкадәр күнектеләр, бераз акны карадан аера башлагач, алар, бер-берсен күрмәсә, үрсәләнеп тәгәрәп елый торган булдылар. Берсен икенчесенә күрсәтеп кенә аларны мондый елау-көйсезләнүләрдән юату мөмкин булып калды. Шушы елаулары сәбәпле, ике яшьтән инде аларны озак вакытка аерып тору мөмкин булмый калды. Шулай алар, игезәкләр кебек, бер-берсеннән аерылмастан бергә тәрбияләнделәр, тик бергә уйнап юаныр иделәр.

Балалар биш-алты яшьләренә җиткәч, падишаһ аларны икесен бер муллага укырга бирде. Һәр көнне өч мәртәбә муллага барып укып кайтар иделәр. Алар икесе дә шундый акыллы һәм укуга сәләтле балалар иде ки, булдыклылыкларына мулла, һәр көн исе китеп гаҗәпләнер иде. Шул рәвешчә укып йөреп, алар ун яшьләренә керделәр. Алар бер-берсен бертуган ага-сеңел санап йөрерләр иде. Алар, яңа чәчәк аткан гөлләр кебек, көннән-көнгә матурая, нәфисләнә баралар, боларның ул гүзәллекләрен тәфсилләп сөйли башласаң, махсус үзенә бер зур китап язарга туры килер иде.

Араларындагы бу якынлык, әүвәл, Зөһрә күңелендә олы мәхәббәт хисе булып бөреләнде. Зөһрәнең бу гыйшкы көннән-көнгә артып, ул сабыр-тәкать кыла алмас хәлгә җитте. Бер көнне ул Таһирның йоклап ятканын күреп, озак кына аңа сокланып карап торды һәм, чыдамыйча, менә форсат килде дип, Таһирның ал асылташтай балкып торган иреннәреннән үбеп алды. Таһир, уянып, моңа

бик гаҗәпләнде һәм: «И, дуамал кыз, бу ни кылганың?! Мин синең карендәшең түгелме?» — дип Зөһрәне бик оялтты. Зөһрә бик каты үпкәләп, берничә көн хәтта муллага ялгызы гына барып укып йөрде. Әмма мәхәббәте көннән-көнгә арта барып ихтыярын кулдан җибәрер дәрәҗәгә җиткән иде. Ул очрашканда Таһирны төрлечә үчекли, тынычлык бирми, ә үзе аның йөзенә карарга чиркәнгәндәй кылана иде. Әмма беркөн тагын Таһирның йоклаган вакытына туры килеп, чыдый алмады, тагын Таһирны иреннәреннән үпте. Таһир, уянып: «И, әдәпсез кыз!» – дип, тагын Зөһрәгә ачуланган төс күрсәтте. Зөһрә бу әрнүдән ун кичә-көндез йокысыз калып, аш-су йоталмый, Хак Тәгаләгә зарыйлык кылды. [...]

Хак Тәгалә Зөһрәнең зар догасын кабул итеп, Таһирны да шундый ук гыйшык дәртенә грифтар кылды. Ул болай булды. Беркөнне, шар суккалап мәктәпкә китеп барганда, Таһирның суккан шары, көтмәгәндә, өй артында күләгәдә эрләп утырган бер карчыкның орчыгына барып тия дә, орчыкны читкә очырып җибәрә. Карчыкның бик ачуы килеп, Таһир моны үзен ирештерер өчен махсус эшләде, дип уйлап: «Минем белән шаярганчы, акылың булса, әтиең ярәшкән Зөһрәҗаның белән барып уйна», — дип сукрана. Таһир гаҗәпләнеп: «Нинди ярәшү?.. — дип сораганында, карчык: «Анысын инде әниеңнән кайтып сораш», – дип, Таһирны яныннан куып җибәрә.

Мәктәптән кайткач, Таһир: «Күңелем куырмач тели, әни, куырмач кыздырып бир әле?» — дип әнисеннән үтенә. Куырмач кызгач: «Әнием, үз кулың белән алып бирсәнә?» — дип ялвара. Әнисе кайнар куырмачны учына алып улына сузганда, Таһир әнисенең кайнар куырмач тоткан учын куллары белән кыса да: «Әтиемнең минем хакта нинди ярәшүе бар? Ник миннән яшерәсез? Әйтмәсәң, кулыңны бушатмыйм!» — дип белдерә. Кайнар куырмачтан учы пешүенә чыдый алмаган ана барысын сөйләп бирергә риза була. Ул Таһирның чын әтисе — вәзир Баһир булганын, туган көннәрендә аларның хан белән Таһир һәм Зөһрәне бер-берсенә ярәшкәннәрен сөйләп бирә. «Тик, зинһар, боларның барысын оныт, ул дәрттән күңелеңне суыт. Зөһрә — хан кызы. Инде без алар белән тиң түгел», — дип ялвара... Шул минуттан Таһир күңелендә дә Зөһрәгә кайнар мәхәббәт дөрләп кабына. Шуннан соң инде Таһир да Зөһрәгә көн саен үзенең гашыйклык хәлләрен искәртә башлады. Моны сизеп, Зөһрә, наз күрсәтеп, аңа ачуланган төс күрсәткән булды. Һәммәгә мәгълүм: яшь кызлар егетләр тарафыннан аз гына мәхәббәт хисен сиземли башласалар, моңа бик үпкәләгән төс күрсәтеп егетләрен үчеклиләр... [...]

Шәһәр тышындагы бер чишмә буенда Зөһрәнең бер бакчасы бар иде. Тел белән әйтеп бетереп булмаслык бер гүзәл бакча иде ул. Бакча эчендә хан, рум һәм һинд осталарын китертеп, Зөһрәгә бер гүзәл сарай салдырган иде, карарга күзләр камашыр иде. Беркөнне, җаны кысылып, Зөһрә шул бакчасына китте. Сараеның балконына чыгып, алдында аккан чишмә суына карап утырды. Зөһрәнең бу бакчага юнәлгәнен тоеп, Таһир да шул бакчага киләсе итте.

Язманы ***Мәсгут Гайнетдин*** *әзерләде*

Дәвамы бар ■

КАЙГЫСЫЗ ПАДИШАҺ
ҺӘМ КАЙГЫЛЫ ВӘЗИР
ТУРЫНДА ХИКӘЯТ

Риваять хуҗалары һәм хикәят ияләре шулай риваять итте:

Борынгы заманда бер падишаһ бар иде. Табигате белән төшенке күңелле, кызу канлы иде, әшәкелек-дуңгызлыкта тиңе юк иде, һаман саен халыкны рәнҗетер иде. Халыктан ишеткән сүзне хәтерендә саклады, алдагы көндә шуны дәлил итәр иде, «фәлән вакыт шулай димәдеңме?» дип хөкем итәр иде. Шуңа күрә аның янында булган кеше артыгын сөйләмәс иде.

Падишаһның бу кызу канлылыгына артык исе китмәүче кыю һәм булдыклы бер вәзире бар иде. Һәркөн падишаһка ризалык күрсәтер, һич файдасыз гамәл кылмас иде. Бу вәзирнең чибәр бер кызы бар иде, ай йөзле, хуш холыклы, гөл сурәтле, тәмле телле иде.

Бу мәлик шул кызны алырга теләп, вәзиргә ничә көн рәттән хәбәр җибәргән иде:

— Кызыңны миңа бир! — дип. Вәзир болай җавап бирде:

— Әгәр кем дә кем үзенең хуҗасы катында үзенең дәрәҗәсен белмичә эш итсә — аркасына әйләнеп төшәр, тора алмас. Әгәр падишаһ үзенең бәндәсенә шәфкать күзе белән караса һәм игътибар итсә, бәндәсенә шул тиеш: үз-үзен белсен, хуҗасына каршылык күрсәтмәсен, кеше үз-үзен белергә тиеш. Мин колмын,

ни хөкем булса шул булыр, кызым хатының һәм серләреңне бүлешүчең булыр, әмма ләкин падишаһ үз тиңен тапса, яхшырак булыр иде, — диде, һәм һәрвакыт сөйләшү-җаваплашу шул рәвешчә кичәр иде. Падишаһның бу җәһәттән вәзиргә карата күңеле хуш түгел иде, әмма аңа каршы чара күрә алмый, чөнки вәзир аңа кадәр үк шул урында хезмәт итә иде, хокуклары нык иде. Мәликнең аны шелтәләргә, урыныннан төшерергә кулыннан килмәс иде. Әмма һаман төрле сылтаулар табып, вәзирне карага буяр иде. Гөнаһларын исбат итмәкче булыр иде. Шул юл белән үч итеп, «кызны алам», дияр иде.

Вәзир катында моңа шаһит булганнар бу мәгънәдән даимән падишаһтан сакланыр һәм качар иде. Падишаһтан курыкканга күрә, һич кеше вәзирнең кызын сорарга килмәс иде.

Шулай беркөн вәзир падишаһ катында утырганда кинәт күкрәгән җиргә орды. Падишаһ моңа каршы:

— Бу ни хәрәкәттер?! — диде. Вәзир:

— Падишаһның яше озын булсын, гәрчә синең кебек тиңсез мәликнең күләгәсендә, игътибарлы карашы астында бәхетлемен һәм ярдәмен тоямын, әмма адәми зат кайгысыз булмас, — диде. Шаһ бу сүзгә риза булмады, күңелендә «яхшы сәбәп таптым!» диде. Аннан вәзиргә:

— Бу нинди урынсыз сүздер? Кешенең башында акылы булса, «галәмдә гамьсез кеше юк» дип ничек кистереп әйтә алсын? — диде. Вәзир:

— Әгәр берәр кеше Көнчыгышны һәм Көнбатышны гизеп чыкса да, гамьсез кеше таба алмас. Бу хакта бәет бар:

Дәрин галәм кәси бигамъ набашәд,
Әгәр башәд бәни адәм нәбашәд.
Ягъни:
Бу галәмдә кеше бигамъ түгелдер,
Әгәр булса — адәм углы түгелдер.

Падишаһ хакыйкатьне белсә кирәк: сүзенә карап кына, тышкы кыяфәтен күреп кенә кешенең асылын белеп булмый. Бер кешенең тыштан караганда уйнап-көлеп йөрүе, шат булуы әле аның эчке халәтенә дәлил булмас. Сөенеч эчендә елаган кеше дә күп булыр. Кайгы да елата, шатлык та елата, шуңа күрә, и шәһрейар, зинһар кешенең тышкы рәвешен күреп кенә аның күңелендәгесен тасвир итмә. Бу дөньяда кайгысыз кешенең һич булуы мөмкин түгелдер.

Падишаһ бу кыю сүзне ишеткәч, ачуы килде, бугазына тыгылды, бер усал хәрәкәт кылырга теләде, кыймады. Каты ант бирде:

— Бу эшне сыныйм, галәм халкы эчендә гамьсез, кайгысыз кешене табам, сиңа тиешле җәзаңны бирәм, һичкем үзенең хуҗасы янында урынсыз сүз башларга кыюлык итмәсен! — диде. Вәзир бу сүзне һәм бу антны ишетте, бу дулкынлану һәм ачуны күрде, мәликнең теләге ни икәнен белде.

— Хөкем мәликнекедер, ни башкарылырга тиеш — шуны боерсын, — диде.

Аннан мәлик тәхет янына олыларны чакырды, аларга алтын-көмеш һәм хилгать[1] бирде:

— Миңа бер кайгысыз кеше табып бирегез. Шуның белән мин вәзиргә җәзасын бирәм, югыйсә мин аның йөге астында калырмын, — диде. «Нишләрсең, калырсың», дияргә кулларыннан килмәде:

[1] Хилгать - тышкы кием өстеннән киелә торган кыйммәтле затлы халат, чапан.

— Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз, йөрибез, эзлибез, аның кебектән күп кеше бардыр, — диделәр.

Берничә көннән соң белдерделәр: аңа буйсынган бу мәмләкәттә ул боерган сыйфатлы кеше юк икән.

Эш бу урынга җиткәч, падишаһның каһәре килде, шундук бер сәүдәгәр сурәтенә керде, үз җирендә бер наиб[2] куйды.

Бер тарафка карап китте. Килеп җиткән шәһәрендә бер көн буе мәчетләрне, йортларны һәм базарларны гизеп йөрде, эзләнде, тикшеренде. Ләкин бөтен тырышлыгының нәтиҗәсе су өстенә язу язган кебек кенә булды. Бераз ял итте, аннары далага чыгып китте, диңгезләргә керде, тәмам Урта диңгез һәм Гомман[3] диңгезе ярларын аягы астына алды. Шат күренгән һәр кешесе асылында кайгылы булды.

***

Падишаһ шул рәвешчә йөргәндә, бер урыннан күчеп киткәндә колагына шундый сүз керде: «Мәгъриб[4] тарафында бер падишаһ бар икән, галәмдә аның гаме юк икән». Шунда ук бер уй башына төште, ул мәликне күрергә, барырга карар итте.

Шулай итеп Мәгъриб тарафына аяк басты, юлга чыкты. Юлда кем очраса да ул мәликнең шат күңелле булуы хакында сорашты, һичберсе аның кайгысы булу хакында һичбер сүз әйтмәс иде. Фикеренә шуны салды: теләгәнемне, эзләгәнемне таптым, әгәр кайгы-хәсрәт сәбәбе булса, бу халыктан берәрсе аны баса булса кирәк.

Шулай итеп йөреп, акрынлап ул падишаһның башкаласына килеп җитте, дөяләрен-атларын сәүдәгәрләр гадәтенчә йөкләтте. Аннан шәһәр үзәгенә кеше җибәрде, килгәнен падишаһка белдертте.

Падишаһ барган кешедән сорады:

— Ул кем, ни юллы кеше?

Җавап бирде:

— Бер олы сәүдәгәрдер, Хуҗа Муса диярләр, бик күп йөкләре, маллары, җиһазлары бар, — диде.

Бу шәһәр мәлигенең гадәте шул икән: берәр кеше бер тарафтан аны сорап килсә, аңа күп мал-дәүләт бирер иде, ят кешене дә, белешне дә бер санар иде. Ул килүгә шәһәрне бизәрләр иде, тәхетләр төзерләр, аннан хөрмәт вә гыйззәт белән тиешле тәртиптә шәһәр үзәгенә китерерләр иде.

Менә кәрван хәбәре ишетелде, халык йөзләрен капкага юнәлдерде, Хуҗа Муса кәрванын каршы алды. Мәлик әйтте:

— Бу хуҗа мөхтәрәм кеше икән, монда кунсын, — дип боерды. Сарайда аның өчен яхшы урын әзерләделәр, шаһларча келәмнәр, түшәкләр түшәделәр. Хуҗа Мусаны шунда кундырдылар, кешегә кирәкле һәммә нәрсәне алдыннан өзмәделәр, барысын да каршына китерделәр.

Мәликнең бик тә сөйкемле, ягымлы ике углы бар иде, һәркөн кунак катына сәлам бирергә килерләр иде, Хуҗа Мусага хезмәт итәрләр иде, Муса аларга бүләкләр биреп җибәрер иде. Падишаһ та моңа каршы кыйммәтле асылташлар, кыйммәтле киемнәр бүләк итәр иде.

Ул мәлик белән Хуҗа Мусаның фикерләре туры килеп, һәр сулышта берберенә дуслыклары арта төште, күп вакытлар әңгәмәдә үткәрделәр. Бер көн вә бер генә сәгать тә Хуҗа Муса бу мәликне күңелсез күрмәде, даимән күтәренке күңел һәм шат күрде.

[2] Наиб – урынбасар.
[3] Гомман — Согуд Гарәбстаны ярлары янындагы диңгез.
[4] Мәгъриб — Африканың төньяк өлеше.

Максатыма ирештем, саулык белән өемә кайтып җитсәм, вәзиргә җавапны бирәм, гафу үтенүен телим, башка урынсыз сүз сөйләргә мөмкинчелеге калмас, — диде.

Шулай итеп, Хуҗа Муса мәликтән китәргә рөхсәт сорады. Мәлик әйтте:

— Бу җиргә килеп, мөбарәк адымыгыз белән бу урынны бизәдегез, ни булыр иде — күңелегезне безгә бирсәгез, монда урнашсагыз, ватан тотсагыз, көчебез җиткәнчә хезмәт итәр идек. Сезнең белән аралашу күңелле, мөлек һәм мәмләкәт сезнекедер, гомер буе шулай кичерик, — диде. Хуҗа Муса җавап биреп әйтте:

— Падишаһның гомере озын булсын, мин колыңа инде вакыт җитте, бер теләгем өчен йорт-җиремнән аерылып, ерак җиргә төшеп торган идем. Сезнең хезмәтегездә инде ул максудым хасил булды, эшем бетте, китәргә рөхсәт итегез, — диде. Мәлик бу сүздән уйга калды: «Гаҗәп, моңа миннән ни файда хасил булган икән?» Аннан әйтте:

— Миннән хасил булган ул максудың ни иде, әйтсәң икән?

Хуҗа Муса әйтте:

— Белеп тор: мин дә синең кебек бер дәүләтнең падишаһы идем. Минем бик акыллы һәм камил вәзирем бар, шуның белән арабызда сүз чыкты, бәхәс булды. Ул: «Бу җиһанда гамьсез кеше булмас!» — диде. Мин: «Булыр!» дидем. Шул сәбәптән ант эчтем: «Бар галәмне гизәм, гамьсез кешене табам, аны вәзиргә дәлил итәм», — дидем. Шушы сәбәп белән сәүдәгәр кыяфәтендә сәфәр иттем, далалар вә диңгезләрне тәмам гиздем, синнән үзгә гамьсез кеше тапмадым, сине һәрдәм шат хәлдә күрдем. Инде белдем, вәзирем ялган сөйләгән икән, илемә кайтып тәхетемә утыргач, иң әүвәл вәзиргә җәзасын бирәм, аннан калган эшләремә керешәм, — диде.

Угылсыз-кызсыз мәлик бу сүзләрне ишеткәч, әйтте:

— Инде син мине гамьсез дип белдеңме?

— Әйе! — диде. Мәлик мосафир падишаһка әйтте:

— Минем белән бар, сиңа хәлемне күрсәтәм, — диде.

Тордылар, сарайга керделәр, бер ишекне ачтылар, бер диһлизгә керделәр, бераз барып мәлик тагын бер ишекне ачты, пәрдәне күтәрде:

— Кара! — диде.

Мосафир падишаһ җәннәт кебек бер сарай күрде, дүрт соффә бер-берсенә каршы куелган, һәр соффәдә берәр тәхет-ятак урнаштырылган, уртада мәрмәр өстәлләрдә һәртөрле җиһазлар тезелеп тора, алар өстендә асылган алтын-көмеш читлекләр эчендә былбыллар, тутыйлар төрле күркәм авазлар белән сайрап тора. Бер ятакта падишаһның күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән куркыныч бер кара гыйфрит ярым ятып тора, мең төрле назлар белән үзен сөйдерүгә мәшгуль, ай кебек бер гүзәл аякларын үбәр, ә ике угланчык аягүрә торып коллык итәрләр.

Бу хәлне тәмам күрсәткәч, урындагы падишаһ мосафир падишаһка:

— Күрдеңме? — диде. Мосафир:

— Әйе, күрдем, — диде.

Мәлик әйтте:

— Әйдә барыйк, утырыйк, гамьсезлегемне сиңа күрсәтим, — диде. Баягы ишекләрдән чыктылар, бер аулак бүлмәгә кереп утырдылар. Мәлик үзенең хәлен сөйли башлады:

— Бел һәм хәбәрдар бул: минем атам бар иде. Бу дәүләт тәмам аныкы иде. Күптәннән бер углан теләр иде, олы яшенә җиткәндә генә мин дөньяга килгәнмен. Тагын минем атам ягыннан бер абзам бар иде, башка мәмләкәттә мәлик иде. Аның бер гүзәл кызы бар икән, атам үзенең туганы белән сөйләшеп, килешү төзеп, киләчәк өчен ул кызны миңа багышладылар. Абзам «мөбәрак

булсын!» диде, мин һәм абзам кызы сөендек, сөештек, бер-беребездән бер дә аерылмас булдык.

Шулай итеп мин унбиш яшемә кердем. Әмма язмыш миңа казалар әзерләп куйган икән...

Атамның бер җариясе[5] бар иде, ул аны абзамнан сатып алган иде. Әмма җариянең күңелендә абзама мәхәббәт бар икән, яшерен генә хат аша сөйләшерләр иде. Мин бу хәлне белә идем, минем белгәнемне сизеп, җария мине сөймәс иде. Тырышлыгын шуңа юнәлтте: абзам кызын миннән аермакчы, мине гомерлек кайгыда калдырмакчы булды.

Бу җариянең фетнәсе, котыртуы белән абзам хат язды: «Ул анда булган кызым кире өенә кайтсын, зур бәһа бирмичә килен белән кияү була алмаслар», — диде.

Абзам кызын кире илттеләр. Мин исә аерылышу утында янып, рәнҗүләр кичерер идем... Шул арада атам хаста булды, тиз арада дөньядан китте. Ул җария тиз генә абзамны чакырып китерде. Абзам килде, атамның мал-мөлкәтенә хуҗа булды, җарияне хатыны итте. Мине шундый гамьнәр, кайгы-хәсрәт биләп алды ки, кая керергә белмәдем, абзамны күрергә дә мөмкинлек бирмәделәр. Бәклек дәрәҗәсе абзам исеменә иреште, тирә-юньнең әмирләре һәм олуг дәрәҗәле байлары барысы да килделәр, мине исә рәнҗетеп, хурлык белән шәһәрдән сөрделәр.

Бер авылда атамның колы бар иде, атам ул авылны аңа багышлаган иде. Аның катына бардым, шунда тора башладым. Юньсез абзам мине атамның малыннан мәхрүм итте. Ул җария абзама мине шулай явыз итеп күрсәтте ки — һичкемнең абзам катында мине якларга чарасы юк иде. Берзаман хәлем шундый кыенлык, бәхетсезлек белән кичте. Ахыр бу бичаралыктан шәһәргә килдем, даям[6] катына бардым. Абзамнан куркудан һичкемгә күренмәдем, шулай ук беркем дә мине килеп күрмәде.

Беркөн даямнең аягына төштем:

— Кызның өенә бар, хәлен миңа җиткер, — дидем. Дайәм җариядән куркудан абзамның өенә бармады, кызның даясе өенә китте.

Шулай итеп, кызның даясе белән минем даям күрештеләр. Минем даям сүз ачмастан борын, кызның даясе сүз ачар:

— Шулай ярыймы инде: шаһзадә абзасының кызын оныткан, хәлен дә белми, — диде. Минем даям шултөрле сүз ишеткәч, әйтте:

— Шаһзадә аның гыйшык утында яна, әмма күрергә чарасы юк, нишләсен? — диде. Кыз даясе әйтте:

— Минем шундый хәбәрем бар, кыз аулакта миңа әйтте:

— Абзам улыннан бер-бер хәбәр ирештер, — диде, зар-зар елады, мин аны «сабыр ит» дип үгетләдем, «барырмын, хәлен белермен», дидем. Мин инде авылга барып, кызның абзасы углын эзләп табарга уйлаган идем, инде ярый үзең килдең, мине интектермәдең, — диде.

Шулай итеп, даям миңа килде, ул сүзләрне миңа җиткерде. Аны ишетеп, гыйшкым яңарды, бере мең булды, берара һушымнан китеп тордым... Исемә килеп икенче тапкыр даямнең кулын үптем, ялвардым:

— Бар, хәлемне белдер, минем сүзләремне җиткер, — дидем һәм абзама җиткерү өчен хат язып тапшырдым.

Даям аулакта кызны барып күрде, хәлемне сөйләде һәм хатымны тапшырды. Ул хатны уңайлы очрак табып атасына тапшырды. Анда язылган иде: «Җариянең фетнәсе аркасында шундый хәлләргә төштем, атамның дәүләтеннән, малыннан

[5] Җария — кол хатын, кәнизәк.
[6] Дая (дайә) — сөт анасы, сабый чактан тәрбияләп үстергән хезмәтче хатын.

аерылдым. Атамның туганы буларак миңа мәрхәмәт итсәгез икән, кызың Хода һәм Рәсүл (*Мөхәммәт пәйгамбәр —* ***Ред.***) боерганынча минем хатынымдыр, ни өчен болай итәсең? Тугрысын әйтәм: мал вә мөлкәттән аерылсам аерылырмын, әмма хәләлемне ташламам. Тәкәбберлек итмә, юмартлык күрсәт, кызыңны миңа тапшыр».

Беркадәр вакытлар үткәч, абзамнан яшерен рәвештә бер илче килде, аның җавабын тапшырды: «Ярар, яхшы булыр, мин кулыннан тотмам. Әмма шул кирәк: кырык янчык алтын бирәсең, аннан кызны аласың», — дигән.

Моны ишетеп бик каты кайгыга калдым, чөнки кырык янчык түгел, бер бөртек малым юк иде. Бу авыр хәлемне абзам кызына белдерергә кулымнан килмәде. Шулай аптырап берничә көн йөрдем. Беркөн күрдем: кызның даясе килде, кыздан сәлам китерде, йөз динар, бер төргәк тукыма алдыма куйды. Кызның сүзләрен җиткерде:

— Ишеттем, чарасызлыктан авылда ята икән. Ләкин кайгырмасын, кырык янчык алтын өчен хәсрәт чикмәсен, хәзинә минем кулымдадыр, акрынлап ул янчыкларны тутырырмын. Ике ай вакыт сорап атама кеше күндерсен, нишләсәм дә эшләрмен, ул вакыт эчендә янчыкларны әзерләрмен. Курыкмасын, бер янчыкта ун мең алтын булыр, барысы бергә дүрт йөз мең динар булыр. Хәзинәдә синең атаңның өлеше дә күп, аз-азлап алсам, беленмәс», — дигән.

Бу сүзләрдән сөендем, бер бәкне абзама җибәрдем, ике ай миһләт[7] сорадым. Кабул итте, вакытында тапшырыга дип антлар бирделәр, абзам да ант эчте:

— Әгәр ике ай эчендә мал килсә, каршылык итмим, башка сылтаулар тапмыйм. Әмма шуны белеп торыгыз: соңга калса — бирмәм, — диде.

Бу сүзләрне һәм килешүне дая белән кызга белдердем. Кыз әйтте:

— Һәр төндә абзам улы минем сараем алдына килсен, һәр төндә бер янчык ташлыйм, алсын, китсен, — диде.

Шулай итеп, һәр төндә сарай тәрәзәсе алдына килер идем, бер янчык ташлар иде, алып, торган җиремә кайтып китәр идем.

Инде янчыклар тәмам тулып җиткәндә, гадәтемчә бер төндә бардым, тәрәзә каршында утырдым. Төн караңгы иде, болыт тарткан иде, яңгыр ява башлады. Кыз нигәдер кичекте. Куркудан хәнҗәремне кулыма алып, чүгәләп утырдым. Кинәт йоклап киткәнмен.

Кыз килде, гадәтенчә тагын янчык ташлады, янчык бөтен авырлыгы белән хәнҗәр өстенә төшеп, хәнҗәр иңеп, ботым арасындагы дәрт вә рәхәтлек чыганагын кисеп төшерде…

Мәҗбүб[8] булдым, акылым китте, мең михнәт белән тордым, янчыкны алдым, көч-хәл белән өемә кайтып егылдым…

Бу хәлне һичкемгә белдермәдем, төрле мәрхәмнәр[9], дарулар белән дәваландым, күп зәхмәтләрдән соң терелдем. Әмма ни файда? Чөнки ирлек китте…

Ул арада шундый вакыйгалар булды: абзам ауга чыгарга теләп, атка атланып чыкканнан соң, аты дулап, егылып төшкән, муенын сындырган. Абзам кызы шунда ук бәкләрне җыеп, килешүләр ясап, хөкемдарлыкны үз кулына алган. Мал-мөлкәт абзам кызы исеменә язылган.

Шул хәлләрдән соң кыз миңа хәбәр бирде, әйтте:

— Хәлләр менә шулай булды, инде мал вә мөлекнең барысын да сиңа тапшырырмын, — диде.

Кыз катына бардым, кыз мине күрде, бик яхшы кабул итте, кулымны вә аягымны үпте. Әйтте:

[7] Миһләт — вакыт, срок.
[8] Мәҗбүб — печелгән, евнух.
[9] Мәрхәм — мазь, шифалы май.

— Ничә заманнар инде йөзеңне күрүдән мәхрүм идем, менә инде Хак Тәгалә рәхим итеп, бөтен киртәләрне алып ташлады, сине — минеке, мине — синеке итте, әгәр инде падишаһлык килешү шартлары һәм гадәт буенча миңа тигән икән, мин аны сиңа тапшырам, падишаһлык сөр, ә мин исә кәнизәгең кебек сиңа коллык итәрмен, — диде. Аннан соң йөз-мең мәртәбә йөз вә күземне үпте, хәзинәләр саклана торган сарайларның ачкычларын миңа бирде.

Ул минем белә усал шаярткан җарияне хурлык һәм мәсхәрә белән катыма китерде, әйтте:

— Сиңа һәм миңа иткән әшәкелекләренең җәзасын бир! — диде.

Мин кодрәтемнән файдаланып, аңа җәза бирмәдем, киресенчә игелек иттем: аны бер олы бәккә кияүгә бирдем. Әмма күңелемдә шул борчу бар иде: «Миңа шулкадәр яхшылыклар иткән кызның миндә өмете бар, ә инде өмете акланмагач, мине читкә тибәрер, бернәрсәсез калырмын», — дип курыктым.

Шулай берничә көннәр үтте. Беркөн кыз ясанды-бизәнде, хушбуйлар сибеп, ачык чырай белән яныма килде. Өмет итәр иде — миннән хәрәкәт килер дип, белмәс иде: андый эштән гаҗиз торырмын. Әйттем:

— Әле бу арада сырхаулап торам, өзлегермен дип куркам, — дидем.

Кыз ышанды, бүлмәсенә китте. Иртәгесен кыз боерды, шәһәрне бизәделәр, олыларны, бәкләрне, барча сарай әһелләрен чакырды. Барысы да диванга[10] кыелдылар. Кыз үзе пәрдә артында утырды, пәрдә аша кычкырып әйтте:

— Әй каум[11]! Минем бәклегемә ризамысыз, минем хакимлегемне таныйсызмы? — диде.

Һәммәсе беравыздан кычкырдылар:

— Разыйбыз! — диделәр. Аннан әйтте:

— Урынымны минем ирем булган абзам углына бирәм, ни диярсез? — диде.

— Яхшы булыр! — диделәр. Аннан мине алдылар, тәхеткә кичерделәр, өстемә чәчү чәчтеләр[12], шатлык-куанычлар күрсәттеләр.

Шулай унбиш көн кичте. Миннән һич таләп һәм теләк беленмәде. Кайгы-хәсрәт үзәгемә үтте. Берсе шул: үзем гашыйкмын, әмма мәгъшукәмнән ләззәт ала алмыйм. Берсе шул: югым юклыгын аңа ничек белдерим? Берсе шул: хатын ирен никадәр нык сөйсә дә, эшен башкармаса, сөймәс булыр. Тагын берсе шул: инде хәлемне белеп, читкә этәрсә, бу урынымнан китсәм дус вә дошман арасында рисвай булырмын. Бу уйлар эчендә төн вә көн хәсрәттә идем, канлы яшьләр түгәр идем, шул дәрәҗәгә җиттем ки — көн дә мең мәртәбә үлемемне тели идем.

Бер ай буе ул пәри йөзлене[13] хасталык сылтавы белән алдап йөрдем. Бу вакыт кичкәндә үбешү-кочышулар да булды. Әмма ни файда? Аның белән генә гыйшык утын дөрләтеп булмый, аның өчен фәкать хәрәкәт кирәктер.

Шулай итеп, шуны белдем ки: бу хәлемне белсә, мине үзеннән читләтер. Хатын-кызның сөюе ләззәт, рәхәтлек алу өчендер һәм тагы бала табып, шуны сөю өчендер.

Бу хәлләр белән кырык көн үтте. Кызның сабыры, карары калмады. Белде ки: арада нindидер вакыйга бар. Беркөн кискен хәрәкәт белән, ачулы һәм борчылган рәвештә катыма килде. Әйтте:

— Әй син, тугрылыксыз ярым, вай син хафалар китерүче чәнечкеле гөлем! Минем өметемне ни өчен кисәсең, бу тулы чибәрлегем белән, бу якты ниятләрем

[10] Диван — дәүләт түрәләренең утырышы.
[11] Каум — халык.
[12] Чәчү чәчтеләр — алтын, көмеш тәңкәләр чәчү йоласы.
[13] Пәри — чибәрлек символы булган мифик кыз.

белән, бу наз вә нәзакәтләрем белән сиңа киләм, ә син шуларга агу кушасың. Шуларны күз алдыма китереп, бар галәмне утларга ягып утырамын. Бу синең миннән ераклык күрсәтүең нидәндер? Мин шуны аңламыйм — элек син минем белән бер түшәктә яту хыялыннан тәмам киселгән идең, инде мин үзем, падишаһлык, мал-мөлкәт, бар нәрсә бушлай кулыңа төште. Бу аерылу уты нидән соң? Шул утка төшкән хәлдә дә син мине сөйдерәсең, сөюем шул чиккә җиткән ки — үләргә җитешкәнмен. Әгәр инде вәгъдәңнән дүндең икән, аптыраштa торасың икән, мин сиңа кирәк түгел икән — мөбарәк булсын, сине сиңа багышладым. Әле андый ук түбән хәлдә түгелмен, синең кебекне табудан гаҗиз булмам, — диде.

Ул ай йөзле озын толымлыдан бу сүзләрне ишеттем, аның мине өнәмәвен, кире кагуын белдем исә, оятымнан утта яндым, белмәдем — үлеме мин, тереме? Телем тотылды, әмма белеп торырмын — дөресен сөйләр. Ул дәм үз-үземә әйттем «Ни булса шул булыр, вакыйганы уртага куям, хәлемне сөйләп бирәм». Шунда ук йөземне җиргә куйдым, аягым астыннан туфрак алып башыма куйдым, әйттем:

— Әй оҗмах хурларының нуры, вай Раббының гүзәле! Синең гыйшкыңда колмын, мәхәббәт җепләре белән бәйләнгәнмен, Әмма минем яшерен серем бар, моңарчы сиңа әйтмәдем, әйтә алмадым, әгәр Тәңрегә ант итсәң, серемне сиңа сөйләсәм, мине читкә кумассыңмы, мәрхәмәтеңнән мәхрүм итмәссеңме? — дидем.

Кыз бу сүзләрдән фикергә калды, аннан ант эчте.

Бәс, хәлемне аңа сөйләп бирдем, җәрәхәтемне ачтым, күрсәттем:

— Бу җәрәхәт синең аркаңда булды, — дидем.

Кыз хәлне тәмам белгәч, торды, хәйранлыктан сүзсез калып, катымнан китеп барды. Ул минутта мең кат үлдем...

Атналар кичте, миңа йөзен күрсәтмәде. Ахыр миңа хәбәр бирде:

— Тор. Падишаһлыкны куй, ризыгың эзләп кит, инде мине бүтән күрмәссең, — диде.

Каты кайгыда булдым, җаваптан гаҗиз калдым, утырып еладым. Күз яшьләре белән даямә әйттем:

— Миннән ул күңелем аулаучыга сәлам әйт. Хатымны тапшыр, — дидем. Хатымда яздым: «Синнән андый сүзләр тиешле түгел. Тәңре өчен, мине яныңа чакырт, йә катыма үзең кил, бер сүзем бар, әйтим. Аннан исә ни әйтсәң шуны тотармын», — дидем.

Никадәр бардылар исә, шулкадәр җавапсыз кайттылар, бәйләнеш урнашмады, йөзен миңа күрсәтмәде...

Ахыр беркөн янына бардым, йөземне аягына куйдым, күзләремнән канлы яшьләр агызып, әйттем:

— Әй гөл сурәтле, ай йөзле! Мин ул түгелме — күпме заман синеке идем, син ул түгелме — дөньяны минем белән күрдең, мин бит бары тик сиңа гына гашыйк идем. Галәм эчендә мине рисвай итмә, үзең белеп торасың — минем бу эштә гөнаһым юк, тәкъдирдә ни язылган — шул эшләнде. Җәрәхәтем өстенә җәрәхәт салма, мине шул үзең куйган урында тот, хәлемне һичкем белмәсен, мәрхәмәтеңнән мәхрүм итмә, — дидем. Бу хакта никадәр сүзләр үтсә дә, файдасы булмады, тик шул ниятен белдерде: бәкләрне, олыларны җыеп, алар шаһитлыгында мине падишаһлыктан төшерә. Торды, китте.

Берничә көн үтте, тагын даягә ялвардым, ул тагын мине кыз катына китерде. Аягына төштем, әйттем:

— Белермен ки — хатын-кызга ир кирәк. Шуңа күрә болай итик: мин шушы сурәттә мәмләкәт белән идарә итим, синең эшеңне, гаскәр, барча буйсынганнар эшен башкарыйм, син исә шушы хезмәткәрләрдән бер күңелеңә яраганын сайлап ал, аның белән вакытыңны үткәр, мин сезгә коллык итәрмен, әмма арабыздагы

серне һичкем тотмасын, — дидем. Бу сүз кызның табигатенә хуш килде. Әнә шул син күргән кара йөзлене голәмнәр арасыннан сайлап алды, үзенә ихтыяр итте, күптөрле гаскәрләренә карамастан шуңа карап, багынып торыр. Шул күзе сукыр, аягы аксак кара йөзлегә барча малын, бөтен күңелен-җанын фида кылды, дөньяны аның белән күрер. Мин кичә вә көндез алар коллыгында бил баглап, шәм кебек бер аяк өстендә торырмын, бары тик алар ятар алдыннан гына катларыннан китәрмен, һичбер адәм заты ул бүлмә янына якын килмәс, ашау-эчүләрен мин китерәм, урын-җирләрен мин түшәп, юыну бүлмәсенә комганнарын мин китерәм. Күз каршымда уйнарлар, мин күз читем белән генә карап күрермен, бәгыремә кан савар. Әле менә яныңа килгән бу ике угланчык (син аларны шаһзадә санап хөрмәт итәсең) ул кара йөзледән туганнар, мин аларны тәрбиялим, халык аларны минеке дип саный.

Ходай гына белер: һәркөн Тәңредән мең мәртәбә үлемемне сорыйм. Сиңа сөйләгән «гамьсезлегем» менә шушыдыр. Әмма һичкемнең бу хәлдән хәбәре юк, тыштан көлеп-уйнап көнемне үткәрәмен, эчемнән исә мең төрле гамьгә чумганмын. Галәмдә гамьсез кебек булганнарны күрерсең, эчләрендә исә күпләргә караганда гаме артыграк булыр, — диде.

Аннан соң әйтте:

— Тор, ватаныңа кайт, зирәк вәзиреңнән гафу үтен. Шуны бел: дөньяда гамьсез булган һичкем юктыр. Хак Тәгалә дөньяны бар итеп, адәм балаларын гамь өстендә куйгандыр, дөнья аларга бүген якты көн булса, иртәгесен кара төндер, бүген тормышы баллы ширбәт булса, аның соңында үлем ачысын татыр. Күркәм гөл чәнечкесез булмас, хәзинә елансыз булмас.

Шушы нәрсәне белү өчен күп зәхмәт чиккәнсең, шулкадәр җирләр үтеп монда килгәнсең, моны белү өчен ул кадәр мәшәкатьләр чигү дә кирәк түгел иде, чөнки бу ап-ачык билгеле, күп мәртәбәләр сыналган күренештер.

Вәзиреңне акылсыз дип сүгәсең, сүзенә ышанмыйсың, һәм дә бу нидер: үзеңне акыллыга санычйсың, ә үзең наданнарча хәрәкәт итәсең, — диде.

Падишаһ бу сүзләрне ишетеп бик нык оялды, «тышкы якны гына күреп, гамьсез йөргәнмен икән», дип уйлады. Шулвакыт вәзирнең сүзе хак икәнен белде.

Аннан соң юлга чыгарга әзерләнде, кирәк-яракларын җыя башлады. Җирле падишаһ аны кунак итте, мосафир падишаһка күп бүләкләр бирде, һәр икесе бер-берсенә килеп-китү ишекләрен ачык тотарга вәгъдәләр бирештеләр. Аннан соң урындагы падишаһ кунак падишаһны бер көн буе озатып барды, аннан кире шәһәренә кайтып китте.

Мосафир падишаһ тагын берничә айдан шәһәренә җитеште. Вәзирләр һәм олы түрәләр каршы алырга чыкты, шәһәрне бизәделәр, мәликне кадер-хөрмәт белән тәхеткә мендерде.

Шулчак мәлик вәзирне кабул итте, башыннан үткәннәр хакында вәзиренә хикәят итте. Аннан вәзирнең кулын тотып тәүбә итте: ул башка авыр сүз әйтми, Хак Тәгаләгә буйсына, гөнаһка керми. Вәзир бу кайгы-хәсрәт белән тулы хикәятне ишетеп, гаҗәпкә калды. Аннан кызны мәликкә кияүгә бирде. Мәликнең ул кыздан күп бала-чагалары дөньяга килде. Ахырда бу дөньяны ташлап, ахирәт сараена күчтеләр.

***

Йөз-мең афәрин бу китапны төзүчегә, күчереп язганга, укыганга, тыңлап торганнарга булсын, амин!

*Язманы **Нәҗип Нәккаш** әзерләде.* ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

АНАК Шамил (Шамил Гомәр улы Мәхмүдев), (1928-2005), *татарча, башкортча, русча иҗат итүче шагыйрь, тәрҗемәче.* Ак һәм иреклe шигырь өлкәсендәге эзләнүләре белән билгеле А.Ш. заман әдәбиятында Т.лар һәм хәтта аларның әлгәреләреннән килгән татар милли традицияләрен үстерүгә дә зур өлеш кертте. Ул, һәм көнчыгыш, һәм көнбатыш әдәбиятларын яхшы белүче буларак, совет чоры татар әдәбиятының уңышларын борынгы әдәбиятныкы белән гармонияле бәйли алды. Т.дан тәрҗемәләр арасында галимнәр тарафыннан аның каләменекенә югары бәя бирелде. Лирон Хәмидуллин «Әдәби тәрҗемә дә бик кирәкле эш» язмасында болай ди: *«Шигъри сүз-җөмләне башка телгә зур төгәллек белән күчерү осталары бик сирәк очрый. Бигрәк тә ике телне камил белүчеләр бик сирәк».* Ш.А.лар буыны үсеп өлгергәнче, Т. әсәрләре башка телләргә ашык-пошык башкарылган юлга-юл тәрҗемәләргә нигезләнеп күчерелә. Ш.А. җитмешенче елларда Т.әсәрләренең аһәңен һәм мәгънәсен җиткерерлек тәрҗемәче эзләү белән шөгыльләнә башлый, кумык-ногай телләрен яхшы белгән А.Тарковскийны бу эшкә җәлеп итеп карый. Ул моңа алына да, һәм үзенә Ш.А.ның консультант буларак ярдәмен сорый, әмма зур теләк белән башланган бу хезмәттәшлек ярты юлда өзелә, зур нәтиҗәләр китерми. Ш.А.ның тәкъдиме белән, Т.ның сайланма шигырь-поэмаларының фәнни нигездә эшләнгән сүзгә-сүз тәрҗемәләрен булдыру килешүе төзелә, аңа республика җитәкчелегеннән хуплау алына. Шуннан соң Ш.А. Т.ның һәр шигырен берничә вариантта эшләгән «юлга-юл күчермәләр»не Татарстан язучылар берлегенә тапшыра. Тәрҗемәләр янында сүзләрнең мәгънәви бәйләнеше, шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере, әсәрнең гомуми мәгънә сөземтәсе һ.б. да бирелә. Мостай Кәрим «Волга» журналының 1982 ел, 5 нче санында Ш.А. башкарган эшкә югары бәя бирә; аларда шагыйрьнең барлык шигъри мирасы беренче тапкыр мөмкин булганча русча төгәл яңгырады, фәнни-филологик тәрҗемәдә аның образлы фикерләве дә максималь төгәл чагылды, дип белдерә. Хезмәт, тиражланып, башка халыкларга тарату өчен эшләнсә дә, үз вакытында типографиягә тапшырылмый. Интернет-сайтлардан чыгып фикер йөрткәндә, Т.ның Ш.А. тәрҗ. дәге «Шүрәле»се бүгенге көндә рус телле укучылар тарафыннан иң уңышлы вариант дип табыла.

Әсәр: Тукай Г. Шурале. / Художник Альменов Б.. Перевод с татарского Анака Ш. К., 1997. 39 с.
Әдәб.: Хәмидуллин Л. Есенин Тукайны каян белгән?// М.Җ. 2006. 21 апр.; Хәмидуллин Лирон. Әдәби тәрҗемә дә бик кирәк эш // Хәмидуллин Л. Кичке шәфәкъ. К.2009. 255 б.; Гарапшина Р.М. Феномен поэзии Анака // Сборник статей научно-практической конференции «Актуальные проблемы отечественной и зарубежной истории, филологии (взгляд молодых ученых и аспирантов)». К. 2013. С.25.

Рифә Харрасова

УТЫЗ ИМӘНИ ОНЫГЫ – «КЕЧЕК БОЛГАРИ»

Әнвәр Шәрипов,
Россия энциклопедияләр академиясенең хокукый әгъзасы

Быел күренекле шагыйрь, энциклопедик белемле галим, фикер иясе Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның тууына 260, вафатына 180 ел тулды. Аның иҗаты галимнәр тарафыннан инде шактый өйрәнелгән, шигъри мирасы һәм фәнни хезмәтләренең күпчелек өлеше инде нәшер ителгән. Мин биредә 1986 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр һәм поэмалар» һәм галим Рамил Әдһәмов тарафыннан гарәп телендәге дини трактатларны урысчага тәрҗемә итеп бастырган «Габдрахим Утыз-Имяни ал-Булгари. Избранное» (2007) дигән китапларны күздә тотам.

Болардан тыш та әдип иҗаты турында татар галимнәренең күп санлы фәнни мәкаләләре дөнья күрде. Әмма матбугатта шагыйрьнең шәхесе, балалары, оныклары хакында һәм гомумән татар шигъриятендә һәм фәнендә ул чәчеп калдырган орлыкларның ничек үсеп китүләре, нинди җимеш бирүләре турында материаллар әлегә чагыштырмача аз яктыртылды.

Габдерәхим Утыз Имәнинең гаилә тормышы һәм балалары турындагы беренче мәгълүматларны Ризаэддин Фәхреддин бирде. Үзенең атаклы «Асар» хезмәтенең алтынчы кисәгендә (Оренбург, 1904) ул шагыйрьнең биш улы һәм биш кызының исемнәрен атый, аларның кайсы авылда, кайсы төбәктә яшәгәнен әйтеп китә. Габдерәхим хәзрәтнең балаларын һәм гаилә тормышын җентекләп 1947-1948 елларда Утыз Имәни иҗаты турында беренче диссертация язган галимә Үлмәс Ибраһим кызы Беляева өйрәнде. 1940-1950 еллар шагыйрь иҗатын бары дини мотивларга гына кайтарып калдырдылар, аны өйрәнү хупланмый башланды. Шулай булуга да карамастан, Үлмәс ханым Беляева Утыз Имәни яшәгән һәм укыткан барлык авылларда йөреп, әсәрләренең кульязмаларын эзләп, шагыйрьнең әле исән булган оныклары белән очрашып, әдип турында бик күп кыйммәтле материаллар туплады. Үзенең диссертациясендә ул шагыйрьнең гаилә тормышын шактый тулы яктырта алды. Шушы хезмәттән бер өзек китереп үтик. *«Утыз Имәни семья тормышын бик яшьтән оештырган. 1773 елда, 19 яшьләр чамасында Утыз Имән авылында туып үскән Рахманкол кызы Фәтхиягә өйләнгән. Фәтхиянең атасы мирза булган, ләкин Габдерәхимгә җирсез килеш кенә килгән. Закон буенча аларга җир тиеш булса да, Габдерәхим исән вакытта кулларына кермәгән. Үзләре үлгәч, Би-*

лал Мамлин дигән нәселдәшләре даулап йөрсә дә ала алмаган, дип раслый истәлекләр. Фәтхиянең өч кыз баласы булган. Фәтхия белән бары биш ел гына торган. Фәтхия үлгәч, шул ук Утыз Имән авылыннан Габдерразак кызы Хәмидәгә өйләнгән. Хәмидәдән 13 баласы булган: бишесе кыз, сигезе ир бала. Хәмидәгә өйләнгәч, Утыз Имәни илендә җиде-сигез еллар чамасы гына торган да хатыны, балалары белән бергә Бохарага киткән». Ә Ризаэддин Фәхреддин исә: *«Габдеррәхим хәзрәт… беркадәр затлар хозурында гыйлем эстәгәч, Хәмидә Габдерразак вә Бәдигыльҗәмал исемле хатыннары*

Габдерәхим Утыз Имәни Әл-Болгариның кызы Бибиҗамал ягыннан бишенче буын оныгы Гамилев Ходәйфә. 1905-1995

вә Габденнасыйр исемле угылы белән Бохара тарафына сәфәр кылган», — дип яза. Үлмәс Беляева бу фикер белән килешми һәм үзенең фикерен кире какмаслык фактлар белән дәлилли. Билгеле булганча, шагыйрьнең хатыны Хәмидә 1798 елда Бохара төбәгендә вафат була. Әдипнең шуннан соңгы гаилә тормышын Үлмәс Беляева болай тасвирлый: *«Габдерәхим берничә еллар сәяхәттә йөргәннән соң, яңадан Утыз Имән авылына кайтып, Фәтхиянең сеңлесе Бәдигыльҗамалга өйләнгән һәм шул хатыны белән ахыргы көннәренә кадәр гомер иткән. Бәдигыльҗамалдан ике ир баласы, ике кыз баласы булган»*. Шуннан соң галимә Утыз Имәнинең гаилә тормышына түбәндәге ачыклыкны кертә: *«Утыз Имәнинең семьясы турындагы моңа кадәр булган мәгълүматлар ачыкланмаган иделәр. Яңа табылган материаллар, даталар бу мәсьәләне анукларга ярдәм иттеләр. Шулай ук Нәкый Исәнбәт иптәш көтепханәсендә Утыз Имәнинең үз кулы белән язылган бер документ бар. Ул анда балаларының кайда, кайчан туулары, үлүләре турында, күбесенең көннәре, айлары, еллары белән билгеләп язып куйган. Мәсәлән, «Кызым Бәдигыльҗамал 1188 сәнә сабан бетәр вакытта тугды», — ди. Димәк, кызы Бәдигыльҗамал 1774 елда туган була. Утыз Имәнигә бу вакытта нәкъ егерме яшь була. Шулай булгач, Риза Фәхреддин әйткәнчә, Утыз Имәнинең беренче хатыны Бәдигыльҗамал була алмый. Чөнки Утыз Имәни, хатыны Бәдигыльҗамал исән була торып, кызына Бәдигыльҗамал исемен куштырмаган булыр иде. Татар халкының гореф-гадәтендә мондый хәл очрамый. Шуның аркасында әдәбиятта шактый каршылыклы фикерләр яшәп килде. Мәсәлән, Утыз Имәни бер үк вакытта ике хатын белән торган, беренче хатыны Хәмидә булып, соңгы хатыны Фәтхия булган, шуның ише башка фикерләр дә йөрде. Кыскасы шул: беренче хатыны Фәтхия, ул үлгәч Хәмидәгә, ул үлгәч Бәдигыльҗамалга өйләнгән булуын, ике хатын белән бер үк вакытта тормаганын югарыда китерелгән фактик материаллар раслыйлар»*.

Шуннан соң Үлмәс Беляева Габдерәхимнең әле 1940 елларда исән булган оныкларын атап китә: *«Утыз Имәнинең өченче, дүртенче буынына тоташкан картлар бар. Алар хәзерге көндә дә авылның искечә иң укымышлы картларыннан саналалар. Мәсәлән, Фазыл карт, Хафиз карт, Мөхәммәт карт һәм башкалар»*. Һәм галимә *Габдерәхимнең кайсы баласы кайда яшәве, оныклары турында шактый тулы мәгълүмат бирә. Мәсәлән, аңа Габдерәхимнең кызы Бибиҗамалның улы Мөхәммәтфазыл белән очрашып сөйләшергә туры килгән. «Фазыл карт Утыз Имәнинең әсәрләрен, аның турындагы материалларны җыйган, саклаган. Күп кенә шигырьләрен яттан да хәтерли. Фазыл Котлыгбаев безгә Утыз Имәни турында материал туплауда бик зур ярдәм итте һәм без алардан югарыда файдаландык та»*, — дип яза ул.

Казан дәүләт университетында аспирантурада укыганда фәнни җитәкчем, күренекле галим Хатип ага Госман миңа фәнни эш темасы итеп Утыз Имәни иҗатын өйрәнүне биргәч, мин дә шагыйрь яшәгән авыл һәм шәһәрләрне йөреп чыктым. Әмма миңа инде Утыз Имәнинең бары дүртенче, бишенче яки алтынчы буын оныклары белән генә танышу бәхете тиде. Үлмәс Беляевадан соң шактый вакыт үткән, ул очраткан, кырыгынчы елларда исән булган аксакал бабайлар инде гүр ияләре иде. Шагыйрьнең кайсы оныкларын ачыкларга һәм кайсылары белән очрашырга туры килде соң миңа?

Утыз Имәнинең оныклары илебезнең күп шәһәр һәм авылларына таралган. Аларның күбесе гыйлем-мәгърифәт, фән-әдәбият өлкәсендә хезмәт куйган. Мәсәлән, мин әдипнең туган авылы Яңа Кадидә (шагыйрьнең ту-

уына 250 тулу уңае белән ул авылга үзенең элеккеге Утыз Имән дигән исеме кайтарылды) Вәзгытдин белән Фәсхетдин бабайларның шагыйрьнең бишенче буын оныклары булуын ачыкладым. Казанда шагыйрьнең кызы Бибиҗамал ягыннан алтынчы буын оныгы Бикмөхәммәтов Альберт яши. Әдипнең бишенче буын оныгы Әхмәтҗанов Әшрәф Мәскәүдә Халыкара мөнәсәбәтләр институтын тәмамлаганнан соң күп еллар буена «Известия» газетасының Иран буенча үз хәбәрчесе булып эшләгән (кызганычка, ул 1981 елда бакыйлыкка күчкән, мин аның белән очраша алмадым). Шулай да, миңа төрле елларда Утыз Имәнинең кайбер оныклары белән күрешергә туры килде. Җитмешенче елларда Башкортстанның Дәүләкән районы Мерәс авылында Утыз Имәни нәселеннән булган Әхмәтҗанов Хәмзә һәм аның улы Әхмәтҗанов Закир, 1976 елда Чистай районы Исләй авылында 94 яшьлек Нурулла бабай Хәлилов белән, 1986 елда әдипнең Уфа каласында яшәүче дүртенче буын оныгы Вафин Әнвәр ага, ә 1988 елда Сәмәрканд шәһәрендә яшәүче бишенче буын оныклары Әхмәтҗанов Халит һәм Әхмәтҗанов Мигъдәт агалар белән очрашып сөйләшергә туры килде.

Утыз Имәнинең бер оныгы белән мин күрешеп кенә калмадым, берничә ел хат та алышып тордым хәтта. Ул — Лениногорск районы Куакбаш авылында яшәүче Гамилев Ходәйфә бабай — Утыз Имәнинең кызы Бибиҗамал ягыннан дүртенче буын оныгы иде: Габдерәхим — Бибиҗамал — Җәләлетдин — Гамилетдин — Ходәйфә. Без аның белән 1995 елга, ягъни аның вафатына кадәр элемтәдә тордык.

Танышуыбыз 1969 елда булды. Ул вакытта мин әле аспирантурада укый идем. Утыз Имәни иҗатын өйрәнү белән кызыксынып китеп, җәйге каникул вакытында Габдерәхим хәзрәт яшәгән авылларда йөреп кайтырга



Габдерәхим Утыз Имәни Әл-Болгари.
Линогравюра. Эрот Зарипов эше. 1990

ниятләдем. Сәяхәтем Лениногорск районының Куакбаш авылыннан башланды. Билгеле ки, Габдерәхим бу авылда берничә ел яшәгән, мәдрәсә салдырып, шәкертләр укыткан. Әлеге салада беренче мәдрәсә булган ул.

Килеп кердем. Авыл уртасындагы кибет янында бер бабай басып тора. Аңардан: «Бу авылда борынгы кульязмалар юкмы икән?» — дип сорадым. «Булса, Ходайфәдә булыр», — диде ул, бер өйгә күрсәтеп. Бусагадан уздым. Мине авыл картларына хас булганча түгәрәк ак сакаллы, ачык йөзле бабай каршы алды. Сөйләшеп киттек. Ул миңа Габдерәхим хәзрәт һәм аның кияве Гыймадетдин турында үзе белгән хатирәләрне сөйләде. Утыз Имәни Куакбаштан соң әтисенең авылы Тимәшкә күченеп китә. Киткән вакытта, мәдрәсәгә хәлфә итеп Гыймадетдин исемле үзенең бик укымышлы бер шәкертен куеп калдыра, аңа Бибиҗамал исемле кызын да кияүгә

бирә. Гыймадетдин гарәп, фарсы телләрен яхшы белә, бик оста каллиграф та була. Утыз Имәни әсәрләренең байтагын кулдан күчереп тарата.

Ходәйфә бабай миңа Утыз Имәни салдырган мәдрәсә урынын да күрсәтте: ул авылны икегә аерып ага торган елга ярының түбәнге ягында булган. Язгы ташу вакытында су басып китмәсен өчен башта субайлар сугып, шулар өстенә салынган. «Субайлар өстенә салынганга күрә, ул ике катлы йортны хәтерләтә иде. Мин бала чагында аның утырткан баганалары исән иде әле», — дип сөйләде Ходәйфә бабай.

Ул миңа Утыз Имәни һәм аның кияве Гыймадетдингә бәйле кайбер хатирәләрен дә бәян кылды. Бу — шуларның берсе: «Габдерәхим хәзрәт бервакыт (кайсы елдадыр — белмим), Түбән Чыршылы авылына килеп төшкән. Түбән Чыршылыда бу вакытта Фәттах исемле кеше хәзрәт булып торган. Ул аш мәҗлесендә утыра икән. Кинәт мәҗлестәгеләргә килеп әйткәннәр: «Җәмәгать! Тизрәк тотыгыз ашыгызны! Габдерәхим хәзрәт килә икән. Аны каршыларга барырга кирәк!» Мәҗлестән ашыгып таралганнар. Шунда Габдерәхим хәзрәт Түбән Чыршылы дин әһелләренә багышлап бер нәзым да язып ташлаган. Аның эчтәлеге мәҗлестә озак утырасыз, дип тәнкыйтьләүдән гыйбарәт булса кирәк. Шул әсәр Түбән Чыршылы имамы Таҗи абзыйда сакланган. Мин укып торырга сораган идем дә — миңа бирмәде. Фәттах хәзрәт үлгәч, ул китап Фәттах хәзрәтнең энесе Хәниф хәзрәткә күчкән, аңардан — Таҗи муллага. Кульязма китап булган ул, басма китап түгел. Таҗи мулла үлгәч, кая киткәндер: Миңлебай авылындагы кызы Мәрьямдә түгелме? Таҗи мулланың тутасының малае Габделәзәлдә (Мәмәт авылы) түгелме? Таҗи мулла үзе исән чагында: *«Китапларымны энемә, ягъни Габделәзәлгә бирәм», — дип әйткән булган». (Бу кульязма артыннан йөреп карасам да, очына чыга алмадым. —* ***Ә.Ш.****)*

Ходәйфә бабай ихлас күңелдән миңа ярдәм итәргә теләде. Үзендә сакланган бер-ике кульязманы бирде, мин аларны соңыннан Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының «Мирасханә»сенә тапшырдым. Бабай белән аерылышканда, без хәбәрләшеп торырга сөйләштек.

Аның беренче хаты түбәндәгечә иде: *«Исәнмесез, балам Әнвәр һәм башка талибәләр! Мәгълүм бабагыздан һәм Гайниҗамал апагыз берлән сагынычлы дустлык, туганлык сәламнәребез соңында, хаталарымыз улса, гафу итеп, дога-хәерләрегезне риҗа вә нияз әйләдек.*

Балам Әнвәр! Үземез бу көндә, әлхәмделиллаһ, саг-сәламәтләрмез. Гомәр агамыз да (Куакбаш авылындагы икенче бер аксакал бабай. — ***Ә.Ш.****) шулай сәламәт кенә гизмәктәдер. Илләремез шулай тыныч кына, әлемез бик дәүләтле, Ходага шөкерана кыйламыз. Балам Әнвәр! Һәр нә язасыгыз, мәгълүмегез. Бер сәфәреңез караңгулыкда улса да, ягъни Башкортстан, икенче сәфәреңез якты улган икән, ягъни Ленинград. Балалар, бер вакытта Ризаэддин хәзрәтнең әсәрендә күреп үткән идем: Габдерәхим Болгариның дөнья йөзендә бер арба тулысы китабы бар, дигән иде. Кайсы әсәрендә икәне хәтеремнән чыккан. Шулай улгач, ихтимал, тагын да бардыр. Азия тарафында күп вакыт гизгән улса кирәк. Сәмәркәнд белән Бохараларда. Шәһәрләрне, әлбәттә, сез беләсез. Шулай улса да, мин 1952 елда Бохарада улдум, ягъни иске Бохарада. Беркадәр җайларда тамаша кыйлдым. Иске Бохарада дәүләт тарафыннан сакланып калган «Мир гарәп» исемендә бер мәдрәсә вар. Шул мәдрәсәдә улдым. Анда дәүләт тарафыннан рөхсәт берлән дамеллалар укый иде. Шундагы мөдәррис хәзрәт берлән мөсахәбәт кыйлышдым. Ул мәнем тарафдан сорашды, мән дәхи андан сорашдым. Шулвакытта әйткән иде: «Болгари дигәнләре йадыма килә», — диеп. Шулай улгач, шунда сакланмый микән? Әлбәттә, сез беләсез, мин сезнең*

хәтергә генә төшерәм. Чөнки Ризаэддин хәзрәт китабында бик күп күрсәтә. Әллә Башкортстан җыеп алды микән? Чөнки Беляевадан (1948 елда Утыз Имәни иҗаты турында беренче диссертация яклаган галимә Үлмәс Ибраһим кызы Беляева. — **Ә.Ш.***) әүвәл кайткан бала шулай дигән иде: Башкортстан үзе җыя; без, ягъни Татарстан үзенә җыя, диеп. Без ярыш ачтык, дигән иде. Ихтимал, шулайдыр.*

Балам Әнвәр! Габделәзәлдә булмаган икән, моңа бәнем йөрәгем бик әрни. Кайда булыр икән? Чыршылыда калган булса, Чыршылы бетеп диярлек янды. Җинан апада да булмаган икән. Ярый, хәерле булсын инде. Өмидебез калды: Беренче Май районы, Кара Чишмәдә. Чөнки мәнем әби анда тормышда улган, шуның оныкларында сакланмыймы икән? Андан Карабаш дигән идем. Әгәр сәфәр чыкса сиңа барырга, Ярмәкдә улмасмы? Чөнки мәнем туганлар анда да бар. Бер абый мәнем Ярмәкдән. Богырыслан ягында Ярмәк. Башкача хәтеремдә юк. Җүбәйрә дигән апагыздан сорармын, ләкин анда булыр диеп күңелем ышанмый.

Ярый, балам, хушыгыз.
Сәлам берлән Гамилев.
1970 ел, 22 декабрь».

Шуннан соң ул 28 юллы шигырь язып куйган. Ул шигырьләр Ходәйфә бабайның үзенеке түгел, Утыз Имәнинең төрле-төрле әсәрләреннән кыска-кыска өзекләр иде. Шулардан соң ул болай дип өстәгән: «Бу шигырьләрне авылда Җинан әбидән телдән укытып алдым. Ул Болгари кызындан укыган әбидән алган; укып, бәңа алып кайткан. «Горбәтнамә»ндә бу сүзләр юкмы? Сүзләр Болгарига охшыйлар. Хушыгыз».

Ходәйфә бабай әле шагыйрь дә икән. Димәк, Утыз Имәнинең таланты аның үз иҗатында гына чагылып калмаган, ә геннар аша аның балалары һәм оныкларына да күчкән. Ходәйфә бабай да әдәби иҗат белән шөгыльләнә икән. Күренекле бабасы хөрмәтенә ул үзенә «Кечек Болгари» дигән тәхәллүс алган (Габдерәхим Утыз Имәнинең «Болгари» булуын беләбез). Татар шагыйрьләре иҗаты, классик әдәбият белән даими рәвештә кызыксынып, укып бара иде, Тукай шигырьләрен яттан да сөйләп бирде. Бабайның бер хатында менә мондый күзәтү бар: *«1912 елда язылган «Ислам мәҗалләсе»ннән күчереп алдым». Тукайдан, дигән:*

Сән булыш сөйсәң мәни,
акчаң, карманың белән,
Күпме тапсаң да икәү,
уртаклашыйк аның белән.
Син исә гыйлем вә гыйрфан
белән булышам, дисәң,
Файдаланмам, туган,
мин андый гыйрфан белән.

Ходәйфә бабай аңа түбәндәге шигырь белән җавап бирә:

«Мәнем сүзгә күнсәң, Тукай,
сәнең теләк улыр шулай;
Ак чабата чолгау урап,
суган игеп булыйк без бай.
Гыйлем-гыйрфан юлы шулай,
акча илән карман тулгай,
Икәү иксәк, бергә бүлсәк,
дус булырбыз менә шулай.

Маллар-дәүләт — арыслан авызында, төрекмән түрендә. Малны шуннан алырга кирәк бит. Ә Тукай сорап кына алмакчы була», — дип аңлатып та куя бабай.

Ходәйфә бабайның тагын бер кыска шигырен китерәм. Ул «Кемнәр кем? Мән үзем кем?» дип атала.

Дигәннәр кәһәфләрни —
җиде-сигез һәммәләри,
Белмәгәннәр: даг эчендә
улган ди фәҗвәләри.
Мосхафта дийәдер: «Даг эчендә
сакчы булган кыйтмирлары».
Шуңа охшаш белмәделәр мән
Гамилне,
Белмәделәр мәндә
улган гәүһәрләрне.
Белер улса, һич димәсләр:
«Сән шагыйрьче», —
Дия иде мөлла Сәгыйть хезмәтчесе.

Минем архивта Ходәйфә бабайның тагын берничә елдан соң килгән икенче бер хаты да саклана. Бу хатны язганда аның беренче хатыны Гайниҗамал апа вафат булган, бабай икенче хатынга өйләнгән. Болай яза: *«Исәнмесез, Әнвәр балам, талибәләр! Мәгълүм бабаң Гамилевтан сезнең исән-сау улып яшәвегезне тәбрикләп, һәр икемездән, ягъни бабай һәм әбидән сәлам соңында, үземез исән-сау яшәп ятамыз. Башкача хәзергә ят хәбәрләр юк. Тормыш иптәшең улса, аңар да бездән сәлам диярсең. Иптәшең булмаса, Болгариның шигырьләре яныңда — шулар берлән моңланып ятарсың. Бусы Кечек Болгаридан диеп укырсың: хәзерге апаңның артыннан йөргән вакытта моңландым:*

Кыйлулә уйкусун талдым,
Бер хәбибе җәмал күрдем.
Дийә нәфсем сиңа һибә,
Җәмал базарундан килдем.
Калкып талган уйкуымдан
Тәгъбирүне тыңла андан.
Җәмал базарларун гизсәң,
Дийә сиңа тәкъдим андан.
Җәмал базарларун гиздем,
Нәчә йирдә җәмал сиздем.
Нәзар дәрйаларун йөздем —
Табалмадым, әй, сән әула.
Кайусының буйы кыска,
Кайусы бик гүзәл төскә,
Кайусы бик озын буйга,
Гаклы юк аның һич тә.

Ошбу «Җәмалнамә»не соңгы рәфикам Фатыйма исменә моңладым, туган. Иле — Димскәй башы дигән карйәдә туып үскән.*

Балам Әнвәр! Ялгызлык үзе бер зиндандыр. Үзем татыганга, шул вакыттагы моңларны сәңа яздым. Парлап яшәү — хода әмередер. Шул ходаның әмерен үтәп яшәү — безнең вазифамыздыр.

Сүзгә байлык бары хатын-кызларныкы, хакларун бирә белергә кирәк. Интернат аталары, урам аналары күбәйделәр. Сак бул!»

Шушы хаттан соң безнең элемтә өзелеп торды. Беркадәр вакыттан язсам да, миңа җавап килмәде. Соңрак аның вафат булганлыгын ишеттем.

Бабайның төрле язмалар һәм шигырьләр дә язылган ике калын дәфтәре бар иде. Алар кем кулында калгандыр? Анысын белә алмадым. Бәлки, әле берәр кеше кулында сакланадыр, дигән өмет бар.

Алда китерелгән берничә генә шигырьдән чыгып караганда да, Ходәйфә бабай Гамилевның башка беркемгә дә охшамаган, үзенчәлекле таланты булганлыгы күренеп тора. Безгә киләчәктә әдәбиятыбыз тарихындагы зур, билгеле талантларны гына түгел, ә менә шундый, беренче карашка бик үк зур булмаган, әмма үз әдәби дөньясы, үз карашы булган үзенчәлекле шәхесләрне һәм аларның иҗатларын да халкыбызга кайтару өстендә эшләргә кирәк. Безнең халкыбыз чын мәгънәсендә талантларга бай халык ул.

Сүзлек: кәһәфләр — легенда буенча, әле Ислам барлыкка килгәнче үк җиде-сигез кеше тау куышында яшәгәндә, медитация вакытында, янәсе, аларга Аллаһ Тәгаләдән хәбәр килгән; **фәҗвә** — таулар арасындагы юллар; **мосхаф** — Коръән; **даг** — тау; **кыйтмир** — юк-бар нәрсә, җен; **кыйлулә** — төрле сүзләр белән; **хәбибе җәмал** — сөекле гүзәллек; **һибә** — бүләк; **калкып талган уйкуымдан** — торып тәмле йокымнан; **тәгъбир** — төш юрау; **нәзар дәрйалары** — күз сирпү елгалары; **сән әула** — синнән яхшыракны; **кәмал** — камил; **әййам** — көннәр буе; **там** — тулы, бөтен; **кальб** — йөрәк; **сәфәр кафына** — сәфәргә чыгып, әйләнеп кайту; **ари** — эзли. ■

---

* Әсәрне тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.

ТОРМЫШ ЮЛЫМ[1]

Гобәйдулла Салихов

стр. № 1

Автобиография

Губайдулла Зарифович, родился в августе

да в семье крестьянина – бедняка в деревне

Бурангуловского с/совета Усерганской 6-й волости

Оренбургской губернии.

революции и после революции, занимались

Отец умер в 1921 году. После смерти

1927 год воспитывался у дяди (у родного брата

в деревне Верхне-Назарово Баскаковско-

ской волости Зилаирского кантона Баш. АССР.

~~...ского р-на Оренбургской области.~~

на иждевении майди в свое родное

и с 1927 года началась моя трудовая

1928 по 1931 год учился в Бурангуловской

году вступил членом колхоза.

командировал меня на курсы ветработ-

при совхозе „Сакмара" Баш. АССР.

кладовщиком к-за „Кзыл-тан"

в ряды ВЛКСМ.

по август 1935 год работал продавцом

. В тоже время учился на разных

с сентября 1935 года и 1936, 1937 годах

годичного Оренбургского педагогического

пединституте.

2-х месячные областные курсы

городе Оренбурге. После окончания курсов

финансистов, областное управление (облфо) направило меня

старшим инспектором госстраха по Зилаирскому району.

На этой работе я работал по май м-ц 1938 года.

А потом, из за ~~.......~~ отсутствия свободного квартира

и по семейному обстоятельству я ушел с этой системы

работы. После чего, перешел на счетную работу и с мая

м-ца 1938 года стал работать счетоводом колхоза „Кзыл-тан".

Гобәйдулла Салихов. Саратов. 1941 ел

«Автобиография»нең беренче бите

[1] Терминологияне автор нөсхәсендәгечә калдырырга тырыштык. — *Редакция.*

2007 елның көзендә иске йортны сүткәндә чормадан күн портфель килеп чыкты. Ачып карасак, аның эчендә әтиебезнең – ике сугышны кичкән кече лейтенант Гобәйдулла Зариф улы Салиховның үз кулы белән язган биографиясе (берничә нөсхәдә), «Муса Җәлил» дип имзаланган берничә шигырь[2] һәм башка кәгазьләр ята иде.

Әти үзенең сугышта күргәннәре турында сөйләргә яратмады, укучылар янына чакырылганда да тел яшерде, башка фронтовиклардан аерып, үзенә сүз бирсәләр, һаман шул берничә җөмләсен әйтеп чикләнде: «Сугыш – начар. Башка беркайчан да сугышлар булмасын, кешеләр газапланмасын иде». Ул сугыш турында сөйли алмады... Аның гомер сукмагы авылдашлары, якташлары өчен сер булып калды. Дөрес, 1973 елның 30 маенда Кувандыкта автоһәлакәткә тарып бакыйлыкка күчкәнче, ул берникадәр хатирәсен балаларына, улларына, кызларына бәян кылып өлгерде.

Бу язмада әтинең автобиография рәвешендә язылган истәлекләре басыла, җәя эчендә кайбер аңлатмалар бирелә.

Гафур Гобәйдулла улы Салихов,
Башкорт дәүләт университеты профессоры

Мин, Салихов Гобәйдулла Зариф улы, 1914 елның августында Оренбург губернасы Орск өязе Бикташ авылында ярлы керәстиян гаиләсендә тудым. Әти-әнием инкыйлабка кадәр дә, инкыйлабтан соң да игенчелек белән шөгыльләнде. Әти 1921 елда вафат булды. Ул үлгәннән соң 1921-1927 елларда Башкортстан АССРның Зилаир кантоны Үсәргән волосте Югары Назар авылында әнинең абыйсында тәрбияләндем.

1932 елда колхоз мине ветеринария хезмәткәрләре курсын үтәргә командировкага җибәрде (Башкортстан АССРның «Сакмар» совхозына). 1933 елда ВЛКСМ сафына алындым.

1934 елның гыйнварыннан алып 1935 елның августына кадәр Чеботарево сельпосында сатучы булып эшләдем. Шул ук вакытта төрле кичке курсларда белем эстәдем. 1935 елның сентябреннән алып 1936, 1937 елларда Дәүләт педагогика институты каршындагы өчеллык Оренбург педагогика рабфагында укыдым.

1937 елның җәендә ике айлык финансчылар курсын тәмамладым һәм Өлкә идарәсе (ОБЛФУ) мине Госстрахның өлкән инспекторы сыйфатында Зиянчура районына юллады. Монда 1938 елның маена кадәр булдым, аннары исәп-хисап эшенә күчтем һәм 1938 елның маеннан «Кызыл таң» колхозында (Бурагул, Акбулат авыллары) хисапчы булып эшләдем. 1938 елда эштән аерылмыйча ике айлык, 1939 елның язында, эштән аерылып, яңадан ике айлык хәрби әзерлек курслары үттем. Шул ук елның җәендә, эштән аерылып, Чкалов *(Оренбург – **Г.Г.С.**)* шәһәрендә бер айлык хәрби әзерлек курслары уздым. 1939 елда кандидат буларак ВКП(б) сафына кабул ителдем. 1940 елның 8 гыйнварында фин сугышына алындым, Самара өлкәсенең Петровск каласында урнашкан 17 нче запас полкта хезмәт иттем, шунда полк мәктәбен тәмамладым. Аннан соң рота старшинасы вазифасында марш батальонына билгеләндем. 1940 елның җәендә Балтыйк буе илләрен (Латвия, Литва, Эстония) азат итүдә катнаштым. Шул ук елның сентябрендә демобилизацияләндем, өйгә кайтып, яңадан колхозда хисапчы булып эшли башладым.

Бөек Ватан сугышы башлануга, 1941 елның 30 июнендә, армиягә чакырылдым һәм офицерлар мәктәбенә

[2] Бу турыда журналыбызның 8 нче санында тәфсилләбрәк язылган.

Серия Е

№ 22670 Салихов

(фамилия)

Губай

(имя)

Зарипович

(отчество) В-705713

(личная подпись владельца билета)

Военный билет выдан

м. п. 26 октября 1948 г.

(наименование военного комиссариата)

(должность, звание, подпись)

Серия Е

I. ВОЕННО-УЧЕТНЫЕ ДАННЫЕ

1. Род войск (служба) Химическая

ВУС № 58

2. Воинское звание мл. лейтенант

Приказ ЮжУрВО № 0814 от 23.12.1941 г.

3. Запас ______ разряда ______ разряда

______ разряда

4. Должность Командир огнеметного взвода

5. Должен состоять на учете по 31 декабря 1964 года

СПРАВКА

Выдана мл. лейтенант Салихов Губай Зарипов в том, что он действительно состоит на действительной военной службе в 1 отдельном запасном огнеметном батальоне в должности ком. взвода.

Начальник Штаба

1 ОЗОБ

Завделопроизводством

Т/интендант 2 р.

Гобәйдулла Салиховның хәрби билеты

Гобәйдулла Салиховның 1 нче аерым запас огнемет батальонында хезмәт итүе турында белешмәсе

җибәрелдем. Саратов өлкәсенең Вольск шәһәрендә урнашкан хәрби химия училищесында укыдым. Аны тәмамлауга миңа «кече лейтенант» хәрби званиесе бирелде. Чыгарылышны частьлар һәм подразделениеләр буенча тараткан вакытта, безне, илле биш кешене аерып алып, училище каршындагы 12 нче тәҗрибәи-химик (опытно-химический) батальонга взвод командирлары итеп билгеләделәр. Мин анда взвод командиры сыйфатында 1942 елның гыйнварыннан алып апреленә кадәр хезмәт иттем, сугышчыларны фронтка җибәрергә әзерләдем. 1942 елның апрелендә инспекторлар тикшерүе уздырылды, шәхси составның бик шәп әзерлеге өчен рәхмәт хаты белән бүләкләндем, бу хакта полк газетасында да язып чыктылар.

Утка керер алдыннан, икенче майда, миңа бик зур һәм җаваплы адымга барырга туры килде, шушы көннән бурычым бермә-бер артты: мин Ва-

Гобәйдулла Салиховның хәбәрсез югалуы турында хәбәрләмә



НКО—СССР
Зианчуринский районный военный комиссариат

Форма № 4

12

ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш родств. ком. взвода мл. лейтенант.
(муж, сын, брат, воинское звание)

23 Апр. 1943 19

№

Салихов Губай Зарипович
(фамилия, имя и отчество)

уроженец Чкалов. обл. Зианчуринск. р-на Чабатарев. с/с.
(область, район, деревня и село)

~~в бою за социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, был~~ Находясь на фронте пропал без вести в июле м-це 1942 г.
(убит, ранен, умер от ран)

похоронен
(место похорон)

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (Приказ НКО СССР № 138.)

КОМАНДИР ЧАСТИ

Городской или районный военный комиссар

М. П.

тан хакына, дошманны җиңү хакына кайда гына булсам да (фронтта, тылда, әсирлектә) үз эшемне җиренә җиткереп башкарырга вәгъдә бирдем һәм тәхәллүсем астына имзамны куйдым — Губанов. Бу фамилия минем өчен пароль иде.

1942 елның маенда безнең часть Воронеж фронтына озатылды. 1942 елның 5 июленнән Воронеж фронтының алгы сызыгында сугыштым. Без, 238 нче истребитель батальонының 60 нчы аерым огнемёт ротасы, Воронежны дошманнан сакладык. Безгә бурыч куелды: дошманны шәһәргә кертмәскә!

Минем белән бергә фронтка Чкалов шәһәреннән дустым, инженер-химик Т.Карпенко да килде. Безнең рота җиде взводтан тора иде. Частебызның командиры взвод командирлары белән берлектә (алар арасында мин дә бар идем) оборонаны карап-күзәтеп чыкты да, Воронеж янындагы 75 ныгытылган районны үз кулы астына кабул итте. Бу яу кырында алманнар берничә мәртәбә һөҗүмгә барды, дивизия арты дивизиясен утка тыкты. Аннары дошман безне аннан кысрыклап чыгарды. Үзгә оборона районына чигенергә мәҗбүр булдык. Әмма төп бурыч һаман шул иде: Воронежны дошманга бирмәскә, чөнки ул, иптәш Сталин фәрманы күрсәткәнчә, «Мәскәү белән Баку ишекләренең ачкычы» иде. Чыннан да, без алманнарга бик нык каршылык күрсәттек. Шул ук вакытта алман командованиесе көньяк группировкасының төп удар көчен Воронеждан көньяккарак юнәлтте һәм Дон аша Сталинградка *(Волгоград — **Г.Г.С.**)* ыргылды. Бу хәл безнең оборона өчен куркыныч тудырды... Алманнар фронт сызыгын Воронеждан көньяктарак кичеп Иделгә томырылды. Чолганышта калдык.

Берничә атакадан һәм берничә маңгайга-маңгай бәрелештән соң безнең частьларның хәрби куәте кимеде, көч бетте, тыл белән элемтә өзелде, коммуникация юлы киселде, гаскәр кичектергесез ярдәмгә — азык-төлек, техника һәм сугыш кирәк-яракларына мохтаҗ

иде. Әмма аларны каян табасың? Шул ук вакытта без, гомумән, баш командованиенең күз уңыннан төшеп калдык, ахры. Бар игътибар Сталинград янындагы бәрелешләргә күчте, күрәсең. Эшләр шулай барганда, 1942 елның июль башлары иде, бердәм җитәкчелектән дә мәхрүм калдык… Боҗраны бәреп чыгу зарур иде. Кечкенә төркемнәргә бүленеп артка чигенә башладык. Төнлә генә барабыз, көндез урманга яшеренәбез… Азык-төлек юк. Бер утарда артык хром итекләрне ярты сынык икмәккә һәм ун данә йомыркага алыштырдык. Совет акчасына азык-төлек юнәтү мөмкин хәл түгел, беркем берни дә бирми, кием-салымыңны, итегеңне сорыйлар, безне, солдатларны, бертуктаусыз артка чигенгән өчен ачуланалар… Шул чорда башым яраланды һәм контузия алдым *(күзәтү пунктын снаряд җимергәннән соң бүрәнәләр астында кала — **Г.Г.С.**)*. Вазгыять көннән-көн начарайды, нәтиҗәдә, 1942 елның 5 июлендә, таң вакытында, әсир төштек. Газаплар, ачлык, ялангачлык башланды…

Безне тиз арада көнбатышка кудылар. Касторная станциясенә барып җиткәч, бер совхоз сараена кертеп яптылар, тышкы яктан пулёметлы, автоматлы сакчылар куелды. Июль кызуында калай түбә астында сулар һава юк иде. Җәлладлар ни ризык, ни су бирмәде. Кешеләр хәлсезләнде, үлем-китем артты. Шул рәвешле алтыҗиде көн тордык. Аннары, вагоннарга төяп, яңадан көнбатышка озаттылар. Вагоннар шыгрым тулы, утырыр җир юк, кызу, тынчу, беркавымнан дөньяны сасы ис басты (күпләр йомышын ботинкаларга, итекләренә генә йомышлый башлады). Кеше чебен урынына кырылды, исән калганнар мәрхүмнәрне урындык итте. Безне шул хәлдә Житомирдагы (Украина) әсирләр лагерена китерделәр. Лагерь зур. Әмма ул да дыңгычлап тутырылган. Безне бер читкә җыеп, бишәр кешелек колонналарга тезелергә, аннары баш киемнәрен салып, чүгәләргә куштылар. Җәлладларның һәр гамәлен җентекләп күзәттек, хәзер пулемёт дулап алыр да һәммәбезне егып салыр кебек иде. Катыйльләр әле бер кешегә, әле икенчегә таяк белән төртеп, яңа әсирләрне барларга тотынды, һаман саен «Йуден?», «Син яһүдиме?» дип сорадылар. Җавап бирүче торып басарга тиеш. Җәлладлар тәмам якынлашты. «Син яһүдме?» — диләр миңа. Аягүрә урысчалап: «Юк, мин яһүд түгел, мин башкорт», — дидем. Алар ышанмады. Араларыннан берсе икеөч адым алга атлады да: «Алдыйсың, син кара чәчле, димәк, син — яһүд!» — диде. Җенес әгъзамны чыгарып күрсәтергә куштылар. Теләмәсәм дә буйсындым. Күпме халык алдында урамда җил куып йөргән малай сыман ыштансыз басып тору уңайсыз иде, әлбәттә, әмма кая барасың? Сөннәткә утыртылган булуымны күргәч, ике дә уйламыйча «яһүд» диделәр. Шулай да, милләтемне тәгаен ачыклау эшен арттарак басып торган икенче берәүгә ышанып тапшырдылар. Ул яныма килеп басты да «мөселманча» сөйләшергә боерды. Тоткан динем, Мөхәммәт турында сорашты. Мин белгәнемне әйттем. Нәтиҗәдә «Мөхәммәт өммәте»ннән булуым расланды. Катыйльләр шул рәвешле ары тикшереп китте. Соңрак кына без алман вермахтында ак эмигрантларның хезмәт итүен, гарәп дөньясы *(Төркия — **Г.Г.С.**)* вәкилләренең тәрҗемәче булып эшләвен белдек. Җәлладлар тылмачлар ярдәмендә яһүдләрне аерып алган икән. *(Бу чара 1942 елдан гамәлгә кертелә, чөнки сугыш башланган 1941 елда яһүдкә саналып бик күп мөселманнар ялгыш үтерелә. Яһүдләр, билгеле, үзен ничек тә мөселман дип күрсәтергә тырыша. — **Г.Г.С.**)*

Лагерьда режим каты иде, иртәнге аштан соң көн дә ике-өч сәгать «каз адым»ы белән йөртәләр. Ачлыктан иза чиккән кешеләргә бу — газапның га-

забы! Җәлладлар әсирләрне резин чыбык белән кыйнарга да күп сорамый. Тагын бер яраткан җәзалау алымнары: «гаепле»ләрне чәнечкеле тимерчыбыктан ясалган «күпер» аша (озынлыгы 15-20 метр, киңлеге — 5 метрга кадәр) узарга, шуышырга мәҗбүр итәләр. Ашарга — черек, юылмаган бәрәңге. Аны карабодай яисә тары кибәге белән бутап бирәләр. Иртәнге һәм кичке аш — шул. Төшке ашка бу «сый» янына пычкы чүбе яисә сөяк оны кушылган ипи (ике йөз грамм) өстиләр, чәй эчертәләр. Лагерь Житомирның көньяк читендә, элекке хәрби шәһәрчектә урнашкан иде. Көн саен акылдан язган ике-өч кешене атып үтерәләр.

Озакламый лагерь эчендә сыңар чирәм дә калмады — әсирләр һәр үләнне төбе-тамырына кадәр ашап бетерде. Комлы туфрак кына калды. Һәм миллионлаган бет калды әле тагын. Аларның җир өстеннән йөгереп узганын күреп була иде. Ачлык, тиф башланды, дизентерия… Көн саен йөзәрләгән кеше үлде. Лагерьның төньягында, тугайдан ерак түгел, зират ясадылар. Әсирләрдән көн саен дүрт метр киңлектәге, өч метр тирәнлектәге һәм утыз метр озынлыктагы чокырлар казыттылар. Чокырлар күп иде. Берсе тулса, икенчесе көтә, анысы да тулса, өченчесе… Көн саен лагерьдан ике-өч арба мәет чыкты. Арбаны әсирләр үзләре өстерәде. Мин монда өч ай тордым.

1942 елның октябрендә безне, эшелонга төяп, Польшага озаттылар, Седлец (Седльце) шәһәрендәге хәрби әсирләр лагерена алып килделәр. Лагерь номерын хәтерләмим. Монда мин якташым, татар шагыйре Муса Җәлил белән таныштым. Аның алты шигырен күчереп алу мөмкинлеге булды. «Дустым хисе», «Дустыма», «Сөйгән дустым», «Озатып калучы», «Туган ил сулары» һәм «Картлык». Мин аларны алып кайттым һәм әле дә үземдә саклыйм. 1943 елның февраль аенда Седлец шәһәрендәге лагерьда башкисәрләр Муса Җәлилне һәм тагын бер кешене кулга алды (фамилиясен хәтерләмим). Беренче көнне лагерь капкасы янында, капка сакчылары күзәтүендә, көн буе гимнастёркада гына тоттылар. Көн салкын иде, төньяк-көнбатыштан бертуктаусыз салкын җил исте. Алар сикергәләп җылынырга тырыштылар, арып, карга егылдылар. Әмма аларны кабат басарга мәҗбүр иттеләр. Икенче көнне шул ук урында, бу юлы шинель кигәннәр иде, кулларына икешәр кирпеч күтәреп тордылар. Өченче көнне инде без аларны күрмәдек…

Бу лагерьда мин өч ай буе җан асрадым. Инженер-химик Т.Карпенко да минем белән бергә иде. Һәр лагерьда алманнар, теләгән кадәр кешене аерып алып, сак астында эшкә алып китәләр иде.

1943 елның апрелендә бу лагерьдан бер эшелон әсирне икенче лагерьга — Радом (Польша) шәһәренә күчерделәр. Якташым Т.Карпенко Седльцеда калды. Безгә аерылу гаять авыр иде — күпме юллар бергә үтелгән бит, күпме күрелгән, кичерелгән: Иделдән алып Польшага кадәр иңгә-иң булдык, фикер алыштык, авырлыкларны бергә җиңәргә тырыштык… Радом шәһәре лагеренда мин журналист, Совет армиясе лейтенанты иптәш Рожкин *(Рощин? — **Г.Г.С.**)* Игнатий белән таныштым. Тумышы белән ул Мари АССРдан иде.

Монда да сак астында бертуктаусыз эшләттеләр: вагоннардан күмер, таш, кокс, торф, печән, цемент, известь, бәрәңге, гәрәнкә, утын, такта бушаттык, сусаклагычлар казыдык, аны цемент белән ныгыттык, урамнарны төзекләндердек, юллар, күперләр салдык. Монда унбиш ай булдым. 1944 елның июленә кадәр. Тәүлегенә ике тапкыр кысыр аш — кәбестә шулпасы ашаттылар. Кеше башына ике йөз грамм ипи тиде.

1944 елның 20 июлендә иртә таңда безне, җиде кешене, шул исәптән Рожкин Игнатийны да, кулга алдылар. Ул


(Муса Джалил)

Saf kөmeştəj hineꞑ həd bujьnda
balьq totьp, ujnap yꞑtem min,
taꞑlarьnda qoşьn sano ƶьbatьm,
Ǝj kөnnəre hində jəttem min.
Atqa atlanьp hineꞑ qьrlarьnda
Tьrnalanьm səsь qьrlarьn,
Taꞑ atqanda hine joꞑьzatьp
Jьrlanьm min jəşlek jьrlarьn
Jeget bulьp yꞑəp berense qat
mexəbbətte hində hiddem min
hineꞑ həblarьndь esəp yꞑrem
qara qaşlь qьƶьь həjdem min.
Hineꞑ gyzəl matur bujlarьnda
Əwəlmep atta saptьm m…
Sitkə kithəm jorəк sьktam…
hine haqьnьp kire qajttьm m…

Польша. Седлец.
Январь 1943 г.

Муса Җәлилгә нисбәт ителгән «Туган ил сулары» шигыренең кулъязмасы

Туп явымыннан соң урамнарны чистарту. Әсирлектә. Берлин. 1944-1945 еллар

көнне җәлладлар ашарга бирмәде. Лагерьда тентү узды. Икенче көнне, ягъни 21 июльдә, җидебезне дә станциягә куып китерделәр һәм товар вагонына тутырдылар. Анда бездән башка да кешеләр бар иде. Станциядә озак тотмадылар, тиз арада каядыр озаттылар. Кая? Нишләтергә җыеналар? Бихәбәр идек. Вагон станция саен диярлек тукталып, һаман кеше белән тула торды. Берничә көннән Берлинга килеп җиттек, концентрацион лагерьга урнаштырдылар. Лагерьның исемен һәм номерын белмим. Безне оккупациягә эләккән барлык территорияләрдән җыеп алганнар булып чыкты (бик күп милләт вәкилләре бар иде). Монда мин Совет армиясе лейтенанты Селиверстов белән таныштым, ул үз вакытында Ленинградта контрразведчиклар мәктәбен тәмамлаган, өч тапкыр дошман тылына кереп чыккан, дүртенчесендә, 1944 елның язында эләктергәннәр.

Соңрак шуны белдек: 1944 елның 20 июлендә Гитлер барлык генералларын һәм адмиралларын хәрби киңәшмәгә җыйган булган икән. Шунда бер генерал портфеленә мина салып кергән һәм портфелен фюрерның өстәле астына куеп (янәсе, Гитлердан башка беркемгә дә ышанмый), үзе көнбатыш фронт чикләрен урап кайтырга чыгып киткән. Киңәшмә вакытында мина шартлаган, өч генерал үлгән, Гитлерны шартлау

дулкыны җимерек дивар аша урамга ыргыткан, нәтиҗәдә, ул яраланган, контузияләнгән, әмма барыбер исән калган. *(Сүз «Валькирия» операциясе турында бара. — **Г.Г.С.**)*

1944 елның июль вакыйгаларыннан соң фашистлар хакимияте, инкыйлабтан һәм яңа түнтәрелештән куркып, бөтен Алмания, фронтлар һәм әсирләр лагерьлары буйлап кулга алу кампаниясен җәелдергән, лагерьда шик тудырган бәгъзеләрне аерып алып, үзгә урыннарга күчергәннәр. Чөнки бу кешеләр (алманнарга карата чын-чынлап нәфрәт саклаганга һәм әсирләр арасында зур абруйга ия булганга) «фетнәчеләр тарафыннан Гитлерга тугры гаскәрләргә каршы кулланылырга мөмкин масса» дип исәпләнгән. Баксаң, алманнар «шикле» әсирләрне һәрвакыт күз уңында тотарга тырышкан икән. Алар арасында мин дә булганмын. Берлинга озатылган әсирләрнең күбесе офицерлар иде.

Бу вакытта инглиз-америка гаскәрләре Берлинны яхшы ук тупка тота иде инде. Көн саен шәһәр өстеннән меңәрләгән самолёт үтә, алар ике-өч тапкыр яңадан әйләнеп килә. Көньяктан яисә төньяк-көнбатыштан керәләр дә төрле калибрлы бомбалар ташлап китәләр. Берлин ут эчендә. Алманнар безне көн дә шәһәргә алып чыга һәм эшкә җигә: янгын сүндерәсе, урамны җимерелгән дивар ташларыннан тазартасы, трамвай юлларын төзекләндерәсе, бомба чокырларын күмеп, юлларны тигезлисе, вагоннар бушатасы. Төшеп тә шартламаган бомбаларны сафтан чыгарасы. Бу эшләрне башкарганда бик күп кеше һәлак булды. Сакчылар өчен шәһәрнең һәр кварталында саклану урыннары, тоннельләр бар иде. Безгә, билгеле, бернәрсә дә юк. Җирле халык белән сөйләшергә дә тыела. Кемдер сүз каттымы, хәзер үк җәза көтә: арт саныңа 25-100 тапкыр таяк белән сугалар, өстәвенә, икмәктән дә мәхрүм итәргә мөмкиннәр.

Берлин лагеренда бер айдан артык тордык. *(Тикшерү бара. Гобәйдулла Салихов һәм аның иптәшләрен җиде тапкыр эшафотка менгезәләр. Башына капчык һәм элмәк киертелгән килеш алар ярты көн буе шунда басып тора. Җәллад артта таптана. Ике офицер «15 августка тәгаенләнгән түнтәрелеш» турында сорау ала, җавап бирмәсәгез, асабыз, дип куркыта. Бер әсир бу газапка түзә алмыйча чаларып чыга. Акылдан яза. Аны алып китәләр. Сорауларның күбесе алманча яхшы белгән һәм лагерьда тәрҗемәче вазифасын башкарган Гобәйдулла Салиховка ява. Бишенче көнне лагерь коменданты аларны җәзадан азат итә һәм камерадан гомуми баракка күчерергә боера. — **Г.Г.С.**)* 1944 елның август азагында бер эшелон әсирләрне Берлин лагереннан Венага (Австрия) күчерәләр. Лагерьның исеме — «Венайзен». Номерын хәтерләмим. Лагерьда бер-ике мең кеше булгандыр. Бу вакытта Вена да, Берлин кебек, тупка тотыла иде. Монда да Берлиндагы хәл кабатланды. Көн саен сак астында эшкә йөрттеләр: урамны тазарту, трамвай юлларын төзекләндерү, юлларны тигезләү, станцияләрне ипкә китерү, ауган вагоннарны торгызу, бомбаларны сафтан чыгару (булдыра алсак...), янгын сүндерү һ.б. Монда да әсирләр өчен бомбадан саклану урыннары каралмаган иде. Венада мин җиде ай тордым. 1945 елның 2 апреленә кадәр.

1945 елның март азакларында совет гаскәрләре Венага якынлашты, әмма шәһәрне алырга ашыкмады... Төн дими, көн дими самолётлар шәһәр күген айкады. Алманнар үз хәлен аңлап котырды, куркышты. Тиз арада имеш-мимеш таралды: болар советларга бернәрсә дә калдырмаска уйлый икән — ни азык-төлек, ни транспорт, ни кеше ресурслары... Әсирләр өчен аерата кыен вакытлар җитте. Нерв күллары киерелеп тартылган халәттә түземсезләнеп үз сугышчыларыбызның Венага керүен көттек. Алманнарның

исәбе анык иде: шәһәрне буш калдырып, безне көнбатышка куарга һәм американнарга тапшырырга, яисә, авырлыклар туса, әсирләрнең барысын да юк итәргә. Совет гаскәрләре кулына гына эләкмәсеннәр! Тормыш кыл өстендә калды…

1945 елның 2 апрельгә каршы төнендә алманнар безне Венадан куып чыгарды һәм Дунай елгасы ярыннан, шоссе буйлап, көнбатышка куып китте. Без, билгеле, теләр-теләмичә, мөмкин кадәр җәелеп, сузылып, озаграк барырга тырыштык. Һич атлый алмас авыруларны һәм хәлсезләрне ике дә уйламыйча атып үтерделәр.

Таң атуга совет самолётлары безнең өстән оча башлады, алар менә-менә баш түбәсенә тиеп китәр төсле иде. Әсирләр баш киемнәрен болгады, ярдәм көтте: «Коткарыгыз! Булышыгыз безгә!» Бу сүзләр алманнарның җен ачуын чыгарды. Алар безне Дунай ярында салынган Линц шәһәренә куып китерделәр дә биререгә хәрби әсирләр лагерена урнаштырдылар. Халык күп иде. Биредә 1945 елның 5 маена кадәр булдык.

5 май иртәсенә сакчылардан берәү дә калмаган иде, качканнар, әмма лагерь һаман бикле иде әле. Көндезге сәгать икедә Америка танклары Линц шәһәренә керде һәм чәнечкеле тимерчыбыкларны җимереп безне, ниһаять, азат итте.

Кара көннәр үтте, куркыныч бетте, миллионлаган кешенең изасына нокта куелды… Без сугышның төкәнгәненә шаһит булдык, күпме көткән якты көннәрне күрдек, алман-фашистлар тәмугыннан котылдык, ачлыкны кичтек, ничә еллык авыр газаплардан арындык (әмма ул еллар безнең йөрәктә мәңге төзәлмәс яралар калдырды)…

Шул рәвешле, һәркем үзен яңадан тугандай хис итте. Куаныч-шатлыклар ташыган килеш шәһәр урамнарына чыктык. Үч алу теләге канны кыздырды… Биш-алты көн дәвамында шәһәрдә канунсызлык, хакимсезлек хөкем сөрде, аннары Америка түрә-карасы артты һәм хакимият тулысынча алар кулына күчте, американнар яхшылап тәртип урнаштырырга тотынды, безгә «холыксызланырга» җай калмады. Әсирләр азат ителгән 5 майдан алып 30 майга кадәр баягы ук лагерьда яшәде. Көндез кем кая тели шунда таралды да кич яңадан баракларга җыелдык. 1945 елның май азагында лагерьга СССР юстиция генерал-полковнигы иптәш Голиков җитәкчелегендә Әсирләрне репатриацияләү буенча Дәүләт комиссиясе килде. Анкета тутыргач, безне йөк машиналарына тутырып, Вена шәһәре янындагы 308 нче номерлы фильтрацион лагерьга китерделәр. Монда да иркле йөрдек. Смерш тикшерүен уздык. Аннан соң рядовой составны төрле эшләргә җибәрделәр, без, офицерлар, җил куып йөрүдә булдык…

1945 елның 12 сентябрендә Австрия территориясендәге офицерларны да репатриацияләү башланды. Маҗарстан (Венгрия), Румыния аша ЮжУрВОга (Көньяк Урал хәрби округы), Алкинга (БАССР, Уфа шәһәре янында), андагы 12 нче запас дивизиянең 28 нче запас-укчы полкы частена кайттык.

Биредә Дәүләт комиссиясе миңа «кече лейтенант» хәрби званиесен кире кайтарды.

1945 елның декабрендә демобилизацияләндем. Әсирлектә чакта КПСС сафларыннан чыгарылганмын. Туганнарым арасында раскулачиваниегә һәм репрессиягә эләгүчеләр юк. Үзем беркайчан да хөкем ителмәдем.

1933 елда тормыш кордым. Биш балам бар. Өйгә кайтуымнан бирле колхозда хисапчы булып эшлим.

26/II-1954.
Запастагы офицер, кече лейтенант
Салихов Гобәй Зариф улы
(Гобәйдулла Зарифҗан улы).

*Урысчадан **Миләүшә Талипова** тәрҗемәсе*

Зариф Мөэминов

Солдат йөрәге*

(Автобиографик бәян)

VI

Беркөнне эштән кайткач, тиз генә әбит бирделәр дә, стройга тезеп, тагын бер порция икмәк өләштеләр. Кайсыбызга көрәк, кайсыбызга балта, кайсыбызга пычкы тоттырдылар. Кайдадыр урман яна башлаган, ди. Сүндерешергә алып киттеләр. Урман янудан дәүләткә зур зыян килүе хакында аңлаттылар. Австрия дәүләтенә килгән зыян безгә нәрсә инде, дип мыгырдаштык без. Чокыр-чакыр, таулар кичеп, арып-алҗып төнлә белән җәһәннәм кебек җир бетереп янган пожар янына барып җиттек. Салкын һавалы төндә ул әле юаш яна икән. Үлән-әрекмән, вак куак мәреп (үреп) бетергән чыршы урманы күз алдында кисәк кабынып, дөрләп китә. Бөтен дөньясын ут алып бетерә. Утка якын килмәле түгел, читкәрәк китеп яттык та шунда ук йокыга да киткәнбез. Кемдер уятты — өстебезгә шартлап-гөртләп ут килә. Тагын читкә китеп яттык. Шулай итеп төн узды, кызу көн башланды. Пожар да торган саен котырды. Бары какланып торган таш тау түбәсенә килеп җиткәч кенә тукталды, чөнки алда янар нәрсә юк иде, янгынга эш бетте. Безне кайтырга җыйный башладылар. Тау арасындагы урман каплаган чокыр буйлап шоссейка (таш юл) узган. Шоссейкадан түбән чокыр төбендәрәк нindидер бер тоннель күренде. Тоннель авызын көчкә генә шәйләргә була. Тоннель һәнүз җир астына сөзәкләнеп керә, эчкәрәк кергән саен киңәя бара. Ун адымнар чамасы баргач, уңга таба борыла. Шылтырап су акканы ишетелә һәм ул су һәнүз эчкә таба агып тора. Анда бернәрсә күренми, караңгы бушлык кына. Бу тоннель хакында урман сүндерергә килүче җирле халык та бернәрсә белми икән.

— Борынгылар әйтүенә караганда, бу — аждаһа, зур елан оясы булырга кирәк, — дип кенә сөйләнделәр.

Ут сүндереп йөргәндә бер Казан татары, бер Сембер мишәре, бер Оренбург башкорты качкан булып чыкты. Тотып

* Ахыры. Башы журналның 7-8 нче саннарында.

кире кайтару булмады. Өч ай узгач болар үзләре кайттылар: шундый тазарганнар иде. Боларга җәза да бирелмәде. Югыйсә, тотылып килүчеләрне биш көн рәттән унар минутка асып куялар иде. Җәза шулай: кулларын артка каерып, ике кулдан асалар. Шунда ук врач карап тора. Берәү бидрә (чиләк) белән су тотып тора, берәү сәгатькә карап тора. Асылган кеше һушыннан язмасын өчен, башына салкын су сибеп торалар. Врач беләк тамырын тотып, йөрәк тибешен күзәтә. Шуны әйтергә кирәк, 1916 елның көзендә Австриянең карт императоры Франц Иосиф үлгәннән соң андый җәзалар бетерелде. Ул гына да түгел, Русиядә Февраль революциясе булып, Николай патша тәхеттән баш тарткан. Бу хакта безгә беркем бер сүз сөйләмәде. Русиядәге революция без пленныйларга күп төрле җиңеллекләр бирде. Әсирләрдә нииндидер күңел күтәренкелеге сизелә иде.

Әлеге качудан кайткан өч иптәш урман янганын сүндерергә баргач тоннель эченә качып, өч ай буе шунда яшәгәнлекләрен сөйләделәр. Үзләренә продукция әзерләп, көндез шул тоннель эчендә ашап һәм йоклап ятканнар. Төннәрен мондагы

халыкның сарыкларын урлап суйганнар, тегермән басып, он алып килгәннәр, йортлар баскалаганнар. Болар йортка керүгә барлык гаилә куркып, юрганнарына төренеп ята икән. Болар йортны тентеп, үзләренә кирәкне алып чыгып китәләр икән. Алай кеше үтергәннәрен сөйләмәделәр. Өч ай эчендә тугыз сарыкның башына җиткәннәр.

Шушы ук чорда ике Елховой мишәре, бер Златоуст башкорты качкан иде. Башкорт көз көне кире кайтты. Аның сөйләве буенча, боларның тору урыннарын жандармнарга белдергәннәр. Төнлә ут кырында ашап-эчеп утыралар икән, ниндидер тавыш ишетеп, башкорт сагайган, читкәрәк киткән. Жандарм отряды боларны чорнап алып, мылтыктан ут ачкан. Башкорт качып котылган, ялгызы гына калгач кайтырга мәҗбүр булган. Мишәр егетләре үлделәр булса кирәк, диде. Соңыннан белдек: мишәр егетнең берсе үлгән, берсе кулы яралы хәлдә, Травник больницасына җибәрелгән. Яраланган мишәр Кыям исемле иде.

Сәетгали исемле бер кырым татары бар иде. Бу татар, кырымтатарларга гына хас булганча кап-кара чәчле һәм кап-кара мыеклы, иренеп кенә, акрын сөйләшә, тавышын борынынннан чыгара иде. Шушы Сәетгали качарга гадәтләнде. Качып бер атна йөрми, тотып китерәләр. Асалар, җәзалыйлар. Ләкин ул һаман кача. Аптырагач, моны төрмәгә ябалар. Сәетгали төрмәдән дә кача һәм бер яһүд кибетен баса. Тагын тоталар. Тотып китергәч, аның исем һәм фамилиясен сорап язалар.

— Исемең ничек?

— Сәетгали, — ди бу.

— Фамилияң ничек?

— Паюмов.

Югыйсә, Мәмәтгалиев иде фамилиясе. Якташлары да «Сәетгали» яки «Мәмәтгали» дип йөртәләр иде.

Сәетгалине комендант чакыртып китертә. Комендант болай дип сорый:

— Менә син иртәгә завод эченнән кача алырсыңмы?

— Качармын, Ваше превосходительство! — ди егет.

Комендант:

— Әгәр дә кача алмасаң, таш камерага яптырам. Ә инде кача алсаң, кулыңа язу биреп, ирекка чыгарам. Теләгәнчә кәсеп итәрсең. Бүләк итеп, югары сортлы мең штук папирос та бирәм, — ди. Килешү төзеп, Сәетгалидән имза ала.

Иртән комендант заводны постлар белән чолгата һәм Сәетгалинең берүзенә биш сакчы ияртеп заводка кертеп җибәрә.

— Качырсагыз, башыгыз белән җавап бирерсез, — ди комендант постовойларга.

Сәетгали заводта иптәшләре белән вагонга такта төйи. Әбиткә хәтле бер эшелон такта төялә. Сәетгали әле шунда. Ара-тирә кесә сәгатенә караштыра. Вакытны һәрвакыт күзәтеп кенә тора. Бервакыт, әбит җитүне белдереп, завод гүләргә керешә, ыгы-зыгы башлана. Барча халыклар әбиткә йөгерешәләр. Сәетгали такта төялгән вагонда алдан әзерләп калдырган оясына кереп утыра. Такта төялгән вагоннарны паровоз пар пышлатып, кычкырата-кычкырта шаулап, сөйрәп чыгып китә. Сәетгали дә такталар белән бергә китә. Ыгы-зыгы вакытта биш пост Сәетгалине күздән яздыралар. Постовойлар да, пленныйлар да сборга кайталар. Аларны комендант үзе каршы ала, барча пленныйларны стройга тезеп, Сәетгалине эзли башлый. Сәетгали Паюмов юк. Ул качкан. Комендант шунда ук биш постовойны арестовать итә. Такталар төялгән эшелон Травник шәһәренә килеп җиткәч, Сәетгали Паюмов жандармнарга үзен белдерә һәм торба заводындагы комендантка илтергә куша. Комендант сүзендә тора: мең папирос һәм мөһерле ирек язуы бирә. Сәетгали тауар сату эшенә керешә.

VIII

Гәстилдә бик ару гына эшләп йөрим. 1917 елның кыш айлары килеп җитте. Озаклап ятмаса да, кисәк кенә кар явып алгалый. Беркөнне калын кар төште. Аударылган ак чыршыларны күрәп, кардан әрчибез. Тау түбәсендә борынгыдан калган сүнгән вулкан моржалары еш очрый. Урман эче чокырлар белән тулы. Кайберләренең төбендә челтерәп җир асты чишмәләре агып ята. Чокырның бер ягыннан агып чыга, икенче ягына кереп китә. Шундый чокырлар аркылы ауган агачларны кардан көрибез, үлчәп, пычкылар белән турыйбыз. Пычкы кысылмасынга таскак ясыйбыз. Астан кисәбез, үз-үзебезне бүрәнә астында басылып калудан сакларга тырышабыз.

Шулай эшләгән вакытта бүрәнә өстеннән таеп чокыр төбенә егылдым, тирән кар көртенә чумдым. Иптәшләр казып чыгардылар. Сулы кар, өстем манма. Һәрчак янып торган зур учагыбыз бар иде. Учак каршына чүмәштем. Бик каты кызыша башладым. Тырнак очларыма хәтле сызлый, бөтен тәнем ут яна. Авыру хәлдә Травникка җибәрделәр. Теге җәһәннәм госпитальгә аяк тартмаса да, китәргә туры килде. Үткән елда авырмыйча килеп тә аздан гына үлми калдым әлеге госпитальдә. Бу юлы инде, шиксез, үләрмен дип куркам.

Килеп җиттек больницага. Күрәм: этаж араларындагы җиде кат ишекләр алып ташланган. Иң соңгы ишек төбендә генә бил каешына штык таккан яшь бер бүснәк малае тора. Хәзер иркенлек икән монда. Авырулар, һичкемнән сорамыйча, шәһәргә чыгып йөреп кайталар. Ризык порцияләре аз булса да арткан, сыйфатлы. Икмәк — яхшы бодай икмәге. Кеше башына 400 грамм бирәләр. Шурпа да икмәкле, ярмалы, боткасы да куе. Фирт-фәлән дип аралатулар гел бетерелгән.

Җиңел һәм файдалы эшләргә теләп баручыларны гына йөртәләр. Көчләү һәм кыйнауларның эзе дә калмаган. Элекке вакыттагы җәһәннәм мәлиге кебек усал дежур хезмәтен үтәүче Хәмзә исемле бүснәк капралы ышанмаслык дәрәҗәдә юашланган. Нимес, маҗар-венгрлар күренмиләр. Сөйләүләргә караганда, аларны куып-себереп бетергәннәр. Авырып килүемне белгәч тә, таныш иптәшләрем сырып

алды. Кайсы алма китерә, кайсы груша, кайсы слива, кайсы әфлисун, кайсылары колбаса, кайсылары сыр — яткан җирне күмеп ташладылар. Алар ризык бирә торган (колбаса пешергән, җимешләр сортировать һ.б.) иткән урыннарга барып эшли икән. Бер атна ятканнан соң температурам нормальләште, әкренләп йөри башладым. Махсус мине караучы бер кыз бар иде. Хорват кызы. Күзләре кылый булса да, чибәр иде ул. Температурам күтәрелә башласа җитен киндерне суга манып күкрәгемә чорный башлый. Ул хәйлә белән мине шулай коча, мин исә аны чынлап кочарга керешәм. Аннан көлешергә керешәбез. Больница түгел, җәннәт бу. Башка кайгы төште, кире кайтарып җибәрмәгәйләре, дип бик куркам. Иртәнге чәйдән соң, кухняга төшеп, әбиткә хәтле сөяк кимерәм. Юан, кимекле сөякләрнең җелекләре бармак юанлыгы, итләре дә мул гына калдырылган. Бервакыт өелгән сөяк астыннан зур бер йомарлам туң май табып алдым. Мөгаен, поварлар эше булгандыр. Мин майны алып кереп баш астына төреп куйдым. Берничә көн майга болгатып күмәч ашаганнан соң, туң майны жандармнар атып яралаган Кыям исемле мишәр дустыма унике кисәк колбасага алмаштым. Кыям дустым бу майны шәһәргә илтеп бер хатынга саткан. Хатынны шул май белән жандармнар тоткан. Халыкка тоткыннардан бернинди продукт та алырга ярамый икән. Сорау ала башлагач, теге хатын майны больницада ятучы яралы урыс пленныеннан сатып алганлыгын әйткән. Жандармнар әлеге хатынны ияртеп Кыямны тотарга дип больницага килделәр. Пленныйларны зур һәм озын коридорга тезә башладылар. Әлеге хатын май сатучының Русия татары икәнлеген дә ирештергән. Шунлыктан коридорга фәкать татарларны гына тезделәр. Кыям, май сатучы, әллә нинди киемнәр киеп, зур козырёклы бик ямьсез фуражканы күз өстенә үк төшереп, стройга чыгып басты. Хатын һичберәүне: «Май сатучы татар егете менә шушы», — дип әйтә алмады.

Кыям хатынның каршысына ук килеп, ике кулы белән бөеренә таянып:

— Әнкәем, исеңә ныграк төшер әле, сиңа кирәк кеше мин түгелме? — дип кат-кат эндәште.

— Юк, син түгел, — диде хатын аптыраулы тавыш белән.

Кыям, безгә борылып, татарча, әкрен тавыш белән:

— Мин булсам да, танымассың шул, әнкәй, — диде.

Хатын Кыямны таныса, егетем мине дә әйтмичә калмый иде. Мишәр егетләре күп уйлап тормый алар, үзләренә кыенлык килсә, сер капчыгын бушатып, төбеннән селкеп үк куялар. Ул да, мин дә җаваптан котылдык. Дежур Хәмзәгә дә эләгәчәк иде. Поварларга да җавап тотарга туры киләчәк иде. Хәмзә дә бу хакта алдан ук аңлатып, майны чәлдереп, шәһәргә чыгарып сатучы арада булса, стройга өстен алмашып басарга кушкан иде. Жандармнар киткәч, бармак янап, Кыямга:

— Син икәнсең, шайтан! — диде. Тавышына артык ачу чыгармыйча, яңадан сак булырга кушты.

Больницага эләгүем Раштуа бәйрәме алдыннан иде. Бәйрәм уңаеннан яхшы әбит белән ужин бирелде, иртәнге чәйгә ром да салганнар иде. Гыйнвар ае узды, февраль аеның азаклары килеп җитте. Савыккан кешеләргә комиссия ясап, эш урыннарына озаталар. Без комиссиягә кермәскә тырышабыз, качабыз. Китәсе килми бит. Беркөнне иртәнге чәйдән соң шәһәргә чыгып киттем. Башта бер сәгатьчегә кереп, утын ярып, ике крона акча эшләп чыктым. Яңадан эзләнсәм дә, эш бирүче табылмады. Шәһәр базарына киттем. Кибетләр буйлап йөргәндә тауар сатучы бер кыз каршысына килеп туктадым. Төсенә караганда бу кыз яһүд кызы булса кирәк. Бүснәк мөселман кызлары болай киенми. Кыз саткан кибет алдында, стойка янында, бер бүснәк-мөселман хатыны да басып тора иде. Аның уң ягына килеп бастым. Үзләре теле белән әйткәндә, бу хатын түрчәнкә, ягъни төрек,

мөселман дине тотучы — минем диндәшем була инде. Өстемдә пленныйлар киеме булса да, башыма мөселман бүснәкләрчә кып-кызыл фәс кигән идем. Бу төрек хатынына илтифат итмәдем. Төрек хатын-кызлары йөзләренә челтәрдән пәрәнҗә эләләр, күлмәкләре киң итеп тегелгән. Аларның яшьме, картмы икәнлеген аеру да бик читен. Яшь дип уйларсың, чуттан чыккан карт булыр. Төс-кыяфәтен дә чамалап булмый. Шунлыктан көләч, яһүд дип уйлаган сатучы кызга эндәштем, нинди булса да эш юкмы икәнлеген белешә башладым. Бар белгән хорватчаны кулланам инде.

Сатучы кыз шаяртырга тотынды. Башта «эш юк», дип маташты. Өстәп:

— Син нинди эшләр эшли беләсең? — дип көлә.

— Хуҗалык эшләрен кем белмәсен? Барын да эшли беләм: утын кисәм, сабан да сөрәм, чәчәм, урам, печән чабам. Илдә чакта барысын да эшли идек, — дидем.

Кыз бөгелә-бөгелә көлә һәм миннән кабат-кабат:

— Русиядә иң мөһим эшне эшләмиләрме әллә? Шул эшне белүеңне әйтмисең, — ди.

Кызның шаяртуын төшенә яздым бугай. Оялып, башымны түбән иеп, тик тора башладым. Минем оялуымнан кыз да уңайсызланды бугай. Көлүен тиз бетереп, сүзне икенчегә борырга тели, ләкин сүзне ничек яңартып башларга белми. Шул чакта төрек хатыны көрсенеп куйды:

— Мескенкәйләрем, заруленниклар (кул арасына керергә тырышып йөрүчеләр). Утын ярып, су ташып йөриләр шунда... — диде. Миңа табан борылып:

— Әллә син мөселманмы? — дип сорады.

Аңа таба карамыйча гына:

— Әйе, мин мөселман кеше, — дидем.

Хатынның тавышы бер яшь кенә кызның мөлаем тавышын хәтерләтте. Ләкин мин аңа таба һаман карамый идем әле. Хатын, ашыгып, тагын сорау бирде:

— Мөселман булсаң, берәр дога укып күрсәт әле?

Мин шунда ук әгузе-бисмилла әйтеп, «Әлхәм» сүрәсен укый башладым. Хатын мине бүлеп:

— Бу сүрәне монда эләккән һәр урыс пленные белә. Һәркем өйрәнә, башларына төшкәч. Бүтәнне укып күрсәт әле син, — диде.

Шулчакта хатынга текәлеп, сынап карап алдым. Юка пәрәнҗә эченнән матур, кызарып пешкән алмадай чибәр йөз шәйләнде. Һушсыз булу дәрәҗәсенә җиттем. Соравына җавап итеп, ничек шулай туры килгәндер, «Йосыф» сүрәсендәге Йосыф-Зөләйханың камәл мәхәббәт белән сөешүләрен бәян кылган аятьләрне укырга керештем.

Хатын, дулкынланып:

— Ярар, укымышлы чын мөселман егет икәнсең. Ышандым инде, — диде. Куеныннан зур ике алма чыгарып, миңа сузды. Алмаларны алдым, шундый борлыктым, үз-үземне оныта яздым. Әллә нәрсәләр искә төште — илдә калган сөйгән дус кызларым, иректә, рәхәттә йөргән чакларым, әти-әнидән күргән иркәлекләрем... Бу илдә забун булып, кешегә дә хисапланмыйча, эттән ач, дуңгызлардан кадерсез йөрүләрем исемә төшеп, яшьле күзләремне яшереп, ашыгып китеп барган чагымда, арттан кычкырган баягы моңлы тавышны ишеттем:

— Тукта әле, тукта әле! — ди иде бу тавыш.

Ирексездән, борылып карадым. Әлеге түрчәнкә артымнан җәһәтләп килә иде. Туктадым. Ул басынкы һәм назлы тавыш белән:

— Бездә эш бар иде. Барырсың микән? — диде.

— Нәрсә эшләргә кирәк соң?

Ул чын ихласлык белән:

— Утын ярасы бар иде, — диде.

— Барам, миңа эш кенә булсын, — дидем мин.

Ул ярым каушаган хәлдә:

— Алай булгач, безгә баруның тәртибе шулай булыр: мин алдан барам. Син мине югалтма да, якынаеп та бетмә. Үзең беләсең, бездәге тәртип каты, — диде.

— Беләм... — дидем.

Аларда хатын-кызлар һәрвакыт өй эчендә генә утыралар. Шәригать шулай куша. Йөзләренә пәрәнҗә япкан хатыннарның чит ирләр белән кара-каршы сөйләшеп торганнарын күргәнем булды. Якыннарымы-түгелме — анысы миңа билгеле түгел. Тагын шундый хәлләргә очраган чаклар була иде: юлда бер төркем хатыннар ят ирләрне очратсалар, юл читенә кереп, ирләр узганчы чүгәләшеп утырып калалар. Әйтерсең, эттән посып калучы песиләр! Берәр йортка якынлаша башласаң, төрек ирләре әллә каян ук сиңа бакыра башлый: «Не смей, мусульманский кучу», — дип йөгереп килә. Әгәр дә берәр хатынга якынрак килсәң: «Не смей мусульманская женщина!» — дип бакыралар. Аларның көмеш чылбырга таккан пычаклары билләрендә генә йөри. Мөгаен, тыңламасаң кадарлар да иде.

Менә шуның өчен дә әлеге хатын:

— Югалтма да, кырыма да килеп җитмә! — дип, мондагы тәртипне аңлатып куйды.

Ярар, киттек. Хатын алдан бара. Мин аңа карап барам. Мондый ныклы тәртипне ригая кылуга (үтәүгә) ачу да килә. Мөселман шәригатен, Коръәннең мөселман хатын-кызларга биргән хокукларын мин белмимме! Болай ук кылану — Коръәнне бозу ул! Шундый фикерләремә мавыгып, алдымнан барган хатынның үкчәсенә баса язам икән. Аның: «Бик миңа елышып барма!» — дигән сүзләре исемә төшеп, артта кала башлыйм. Көтмәгәндә берәр ир заты каршыга чыгып, бәйләнеп китүе ихтимал булганлыктан, үземне дә сакларга тырышам, бу хатынны да кызганам. Аны рисвай итә күрмәсеннәр, дим. Хатынның йөзен күрмәсәм дә, кигән күлмәкләре капчыктай салынып торса да, чамалыйм — ул әле яшь, гәүдәсе, аяк атлаулары килешле. Хатын станлы (зифа гәүдәле), килешле һәм бик үк тулы тәнле булмаска охшый. Чибәрлек ягына да төшеп калган түгелдер кебек. Инде хыялымда бу хатынның сурәтен ясап куйдым, булса да булыр икән шундый чибәр, гүзәл зат, дип гаҗәпләнеп барам. Җил өргән арада күлмәге тәненә сыланып ала, хатынның тәне җиңелчә калтыранып барганын чамалыйм. Базарны да чыктык, бик күп борылма урам-тыкрыкларны уздык. Ниһаять, шәһәр читенә чыгып, бер генә яклы урамнан бара башладык. Мин хатыннан һаман саен ерак кала барам. Хатын борылып-борылып карап: «Бу солдат арттан килә микән?» — дип күзәтүе миңа бик ямьле иде. Хатын бер капканы ачып, башын изәгәдәй: «Күрә микән кая кергәнемне?» — диптер инде, борылып бераз тукталып алды. Тиз атлап шунда барып кердем. Баскычтан ук биек чардакка менеп китешле. Әлеге хатын бер әби белән таныштырды. Бу карчык йөз дә өченче яше белән бара икән! Бик ачык каршыладылар. Карчык мине күрү белән еларга кереште:

— Минем бәбкәем дә шулай интегеп йөри торгандыр инде...

— Улың кайда соң? — дип сорадым әбидән.

— Русиядә пленда, — диде әби, кытыршы бармаклары белән күз яшен сөртеп.

— Хәбәре бармы улыңның?

— Бар... Казан дигән шәһәрдән хаты килгәли. Болай бик зарланмый үзе. Казан мөселманнары бик яхшылар, дип мактый. Син, улым, Русиянең кайсы җиреннән? Бик зур, диләр бит ул илне. Чамасыз олы, диләр.

— Мин шушы Казан дигән каладан, — дидем.

Мондагы надан халыклар түгел, шактый укымышлы нимесләр дә Уфа шәһәре

турында хәбәрдар түгелләр. Казан дисәң, әле бераз күзаллыйлар. Безнең якка Уфа каласы якынрак. Анда барып җитү мөмкинлеге дә күпкә уңайлы. Шуңа күрә безнең як кешеләре дөньяга Уфа аша чыгып таралалар. Без үзебезне Казаннан дип түгел, Уфа якларыннан дип сөйләшәбез. Шуңа күрә, карчыкка гомерендә ишетмәгән Уфа ягыннан икәнен белдереп тормадым, Казаннан, дидем. Бусы да алдашу түгел.

Әби телгә оста, зиһене үткен, үз хәлләрен сөйли башлады. Улы шушы киленгә өйләнеп, унбиш көн генә торган, сугышка алып киткәннәр. Унбишенче ел башында ук пленга да эләккән. Бу кыз нибары унбиш көнлек кенә хатын булып калган. Бу халыкларда тәртип шундый: кызлар кияүгә бармас борын битләренә пәрәнҗә япмыйлар. Кияү куенында бер кич кунгач, пәрәнҗә куялар икән. Килен мин эшләргә тиешле эшне күрсәтте. Нәзакәтле сөйләшүеннән киленнең иркәрәк бичә икәнлеген чамалап алдым. Эш ягына да көчәнә торган түгел икән. Әрдәнә утыны яру күп көч сорамый, ә бичә нәзек бүкәндә кечкенә бер ботак булса да аны читкә алып ташлый барган. Андый бүкәннәр шактый җыелган, чүмәлә булып өелгәннәр. Шуларны ярырга кушты. Эшкә керештем. Больницага килеп тәрбия күргәч, тазарган идем, беләктә гайрәт уйнап тора. Колбасный цехта эшләүче иптәшләрем ай буена яңа суйган иттән шулпа эчерделәр, хайванның эч маеннан өзмәделәр. Минем ише хәлсезләнгән кешегә ифрат файдалы икән ул эч мае. Башта мин аны эчүдән баш тартырга теләдем. Нинди хайван мае икәнен кем белгән? Бәлки чучка маедыр?.. Дусларым ай-вайга карамыйча кыстыйлар. Беренчедән, без сугыш кырында әсир төшкән Аллаһ бәндәләре, тоткыннарга хуҗалар ни тамызсалар, шуны ризык итәбез; икенчедән, шәригать буенча авыруга дару өчен һәр файдалы нәрсәне эчәргә яраганын искә төшерделәр. Иптәшләрем арасында даны ерак киткән мәдрәсәләрдә укыган чын белемле зыялы шәкертләр дә бар иде. Аларның киңәшләренә колак салып, һәркөнне берәр австрийский бокал эч мае эчә башладым. Әйткәнемчә, нинди хайванныкы булгандыр, авыруларым күзгә

күренеп чигенделәр, хәлләнә башладым. Тәнемә сеңеп кенә барды бу май. Көч кергәч, ниндидер батырлык эшлисе килә бит ул...

Беркөнне, гадәтләнгәнчә, кухняга сөяк кимерергә төштем. Күрәм: складның ишеге бер карыш чамасы ябылып җитми калган. Ишекне ачып карадым. Кул сузымында гына түшкәләр өеме. Бар бик зурлары, бар кечкенәләре. Мин бер түшкәне чәлдерергә уйладым. Кердем складка. Иң кече дигән бер түшкәне күтәреп маташам. Зурлары янында гына кечкенә булып күренә икән. Түшкәне шинель чабуы астына яшерергә тырышам, булмый бит. Калдырып чыгарга туры килде түшкәне. Һәнүз аласы килә. Тагын кердем. Тагын куркып алмыйча чыктым. Ниһаять, өченче керүемдә чәлдердем түшкәне. Бер этажга мендем. Бу этажда Австрия солдатлары ята иде. Яшеренеп аулак кечкенә бүлмәдә торам. Бүлмәгә солдатлар тәмәке тартырга керәләр иде. Быдыр-быдыр сөйләшеп ике авыру солдат килеп керде. Мин аларга шинель астарындагы түшкәне күрсәтеп:

— Трбияш, пан, продам, — дидем. «Кирәкме, сатам», — дигән сүзләр була инде.

— Кулькы кушты? Кулькы кушты? — Ягъни: «Ничак тора, ничак тора?» — дип, яныма килеп бастылар.

Эләксәң, эш харап. Үзаралай шыпырт кына тәртип куйдылар. Берьюлы алмаска, солдатлар берәм-берәм генә кереп, өлешләп алырга булдылар. Солдатлар алмашлап керәләр, пәкем белән түшкәне бер кроналык, ике кроналык, биш кроналык, ун кроналык итеп кискәләп сата торам. Ит базарыннан ким түгел. Йөз утыз кроналык ит саткач, эшне туктаттым, калганы үземә бер атнага җитте. Тозланган, ләкин киптерелмәгән түшкә иде ул. Шулай, дуслар, солдат тазарып, сихәтләнеп тик ята башласа, әлләниләр майтарып ташлый икән ул. Чибәрлегем дә бар, көчем, дәртем ташып тора, җан әзләнә башлый. Табигать шулай куша. Җан-фәрман утын ярам, яшь килен миңа булышкандай итеп янымда йөри. Җай булса, тартып алып, кочакка сеңдерер идем дә бит... Киленнең дә күңеле уйнаклый, һуштан язу чигенә җиткәнлеге күренеп тора. Сизәм, карчык булмаса, ике уйламый бер-беребезгә ташланыр идек. Әби һәнүз балконнан безне күзәтеп, карап тора. Ул, бичара, үзенең карчыклык вазифасын тулысынча үтәргә тырыша. Беләктә көч кайный, йөрәк шаулап тибә, әллә нинди шашкын дәртле, мәхәббәтле гайрәтем белән әрдәнәгә шундый каты китерем чабам. Йомычкалар зырлап һавага очып китәләр. Көчем котыра, дәртне кая куярга белмим. Солдатның уенда өч нәрсә генә булырга тиеш: ашау, йоклау һәм илгә хезмәт итү. Башына икенче төрле исәп керә башлауга, ул солдат булудан туктый. Әсиргә исә ачтан үлмәү һәм ничек тә исән-имин илгә кайтып егылу турында гына фикер йөртү лазем. Башка нәрсә уйга да килми, теге яки бу нәрсә уйга килә икән, аннан тоткынга бер файда да юк та — үзеңә хафа, җаныңа көчлек килә. Вәссәлам. Ярый, мондагы хәлгә кайтыйк. Шулай, җенләнеп утын яра торам, аяк астымнан ниндидер кату алып, йөземә калтырану тарала, хатынның да йөрәге күкрәгеп ватардай итеп тибә булса кирәк. Кинәт читкә борылып, күкрәк тирәсен тотып алгалый. Моны ачык сизәм. Хатын торган саен миңа елыша, бетмәс-төкәнмәс көч белән әрдәнә бураны очыруыма хәйран калып, исен-акылын тәмам җуя бара кебек тоела. Эшлибез шулай, балконнан безне күзәтеп торган карчык тәмам туңып, бөрешеп, чарасыздан тамак кыра башлады. Салкын җилдә бөтенләй күшегеп беткән, дер-дер калтыранганы миңа күренеп тора.

— Әби катып үлә бит, — дим әкрен генә.

Бичәкәй дә моны күреп торган, карчыкны кызганып, аның янына менеп, җитәкләп өйгә алып кереп китте. Бик озак тормады килен, тагын минем янга төште һәм шунда ук әби дә балконга килеп чыкты. Тагын безне карап тора баш-

лады. Карчыкка да ачуым килә башлады. Карчык йөздә өч яшь яшәгән. Бернәрсә дә аңламый микәнни? Ник ул яшьләрне саклап маташа? Әгәр дә шушы күз бәбәге кебек берләнбер килене булмаса, бу карчык бер көн дә тора алмас иде. Безнең якта мондый ыспай гәүдәле, назлы сылукайларны «күз бәбәге кебек» дип йөртәләр. Күз керфеге чак кына тәэсирләнүдән дә тибрәнеп китә. Кыз баланың тәмам өлгереп, һәрнәрсәгә гаҗәпләнеп, өметле каравы, һәрнәрсәдән сөенеч, ямь эзләгәнне белдертә торган сүз бу. Кызганам киленне. Бу киленне генә түгел, гомумән, төрек хатын-кызларын кызгана башлыйм. Тагын гайрәтем арта. Монысы ачулы гайрәт бугай. Тирәмдә бөтерелгән бу чибәр хатынны, ичмасам, бер кочып суырып үбеп тә булмый бит. Ачуым котырып, балта белән ордым бөке (бук) әрдәнәсенә. Балтаның сабы тимере яныннан сынып чыкты. Бу вакытта нибары җиде палан (пүлән) ярасы калган иде. Хатын хәсрәткә калды. Ә әби сөенә шикелле. Аның салынган иреннәре таралып киткән һәм эчкә баткан күзләре сукыр лампа кебек елтырый иде.

— Сапсыз балта калдырып китә алмыйм. Икенче сап ясарга кирәк. Тагын бер балта кисәге булса, бу балтаны элеккесеннән дә яхшырак итеп саплар идем.

Килен дәшми генә каударланып чиннек эченә кереп китте. Кулына бер балта тотып кире чыкты.

— Бу балта белән сап юнып булмый шул, — дидем. — Югыйсә, сап юнырдай, нәкъ кирәкле агачлар бар икән, — дип, сөйләнгәләп әрдәнә арасындагы бер пүләнне алып күрсәттем.

Килен янә карчыкны җитәкләп өйгә кертте дә, әйбәтрәк балта эзләргә урамга чыгып китте. Мин ул арада чыралап яргалаган утыннарны чиннеккә кертеп өеп куйдым. Алар утынны ваклап, чыра кебек итеп диярлек ярырга күнеккәннәр. Килен озак йөреп балта алып кайтты. Озак йөрүнең сәбәбе — балта сабы ясау осталык эше булып саналганлыктан, ул осталар балтасы эзләп йөргән икән. Ярый, үз осталыгымнан чыгып, чыннан да, матур, килешле итеп балтаны саплап җибәрдем.

Хатын балтаны кулына алып, яңа сары сапны әйләндерә-әйләндерә карап торгач:

— Менә шушы балта саплау гына да бездә унике крона тора, — диде.

Калган утыннарын яргалап бетердем. Бүгенлек эш бетте. Хатын утынлыкка манный өйрәсе һәм арпа күмәче чыгарды. Чыгарганнарын ашап бетердем. Теге затсыз әби дә балконнан карап торды. Ашагач, шартын китереп, озаклап дога кылдым, хуҗабикәләргә рәхмәт укыдым. Килен биш крона акча бирде һәм, әбинең читкә карап торуыннан файдаланып, кинәт кенә гәүдәсе белән миңа сарыла төшеп, кызу итеп, иртәгә тагын килүемне үтенде. Вәгъдә бирдем һәм саубуллашып кайтып киттем. Мием кайный, хыяллар мине әллә кайларга алып китте. Хатынның кайнарлыгын әле һаман тоям сыман. Больницага кайтып керүгә, әбиткә звонок та бирделәр.

Икенче көнне ишек төбенә ныклы постлар куйганнар иде. Берәүне дә чыгармадылар. Куып комиссия камерасына керттеләр. Врач, аркамнан сөеп, тазаруымны әйтте. Икенче көнне үк торба заводына озаттылар. Шулай итеп теге чибәр килен белән кабат очрашу хыял гына булып калды.

IX

Бер якшәмбе көнне үзебез сыман ук тоткын поляк солдаты мине үз янына чакырды. Бардым аның кырына. Ул өстенә кызыл диагональдән тегелгән җылы бишмәт кигән иде.

— Кенәз, — диде ул миңа. — Син бер җиргә дә чыгып йөрмисең. Әйдә, мин сине диндәшләрең — төрекләр янына алып барам…

Кызыксыну көчле иде, барырга булдым.

— Кая барырга җыенасың? — дип сорашучылар булды, әйтмәдем.

Киттек поляк белән урман эчендәге тар сукмак буйлап. Юлыбыз торган җиребездән көнчыгыш ягына сузыла. Тар гына сукмак. Урман ташлыкка үсеп чыккан. Анда зур — сыер һәм ат гәүдәләре кадәр, кечерәкләр — бозау, сарык гәүдәләре кадәр ташлар. Валуннар, диләр. Шул ташлар арасыннан сукмак шуыша. Бу сумактан кешеләр сирәк йөриләр, ахры. Моңа хәтле бу тарафта бөтенләй дөнья юктыр, дип уйлап йөри идем. Яшькелт чыршылар каплап алган, Травник шәһәренә хәтле сузылган биек, яссы таулар гына шәйләнә иде. Бара торгач, поляк дус белән тауның артына чыктык. Тауың аргы ягында зур тигезлек җәелеп ята икән. Ерак җирләр ялтырап күренә. Инде тау итәгеннән барабыз. Шактый баргач, сукмак гел бетте. Таудан тәмам төшеп, үзәнлеккә табан теркелдибез. Әйтерсең, куерып аккан болыт түбәсеннән җиргә төштек. Сукмак беткән җир сөзәгрәк урыннар иде. Шулай читенлек белән тауны төшеп җиттек. Авыл-салалар юк, әле анда, әле монда бүснәк өйләре күренә иде. Бергәләп оешып утыру юк. Берсенең йорты — тау түбәсендә, икенчесе тигез урында йорт корган. Йорт яныннан ук басу-кырлар башлана. Кайсының җире аз гына, кайсыныкы шактый иркен күренә.

Бер йорт каршына килеп тукталдык. Поляк миннән мөселманча кычкырып сәлам бирүемне үтенде. Кая барганымны яхшы белгәч, аптырап калмадым, гарәпчәләп, көр тавыш белән: «Әссәламәгаләйкем!» — дип кычкырдым. Шунда ук өйдән бер төрек килеп чыкты һәм: «Вәгаләйкемәссәлам!» — дип җавап кайтарды, сүзгә керешеп тормыйча, безне өенә алып керде. Гадәттә, аларның өйләре өч бүлмәле була. Берсе — иң алдагысы, кухня. Ул җир идәнле була. Бүлмә уртасына, туп-туры идәнгә ут ягып бәрәңге һәм аш, кукуруз боламыгы пешерәләр. Ут тирәсенә кечкенә тәбәнәк эскәмияләргә түгәрәкләнешеп утыралар. Тәмәке тарталар, ашыкмыйча әңгәмә сатaлар. Бу өйгә кергәч тә без шундый күренеш



күрдек. Ут тирәсенә биш-алты төрек утырганнар, шулай күрше-күкертләр бергә җыйналганнар. Безгә урын бирделәр һәм тәмәке тәкъдим иттеләр. Мин, тәмәке тартмагач, тәкъдимне кире кактым. Шунда берсе миннән:

— Әллә сез русский төрекме? — дип сорады.

— Русиядә төрек халкы барлыгын белмим. Мин чыннан да Русиядән, мөселман татары, — дидем.

Берничә төрек бердәм рәвештә шаулап алдылар:

— Татар, татар! Мөселман!

Мин полякча, немесчәләбрәк:

— Я, я, җист татар (әйе, әйе, татар булам), — дигән булдым.

Русиядән пленнан кайткан ике төрек сүзгә керештеләр. Аларның берсе — Омскида, Себердә, икенчесе Казанда әсирлек хафасында булганнар. Безнең илдәге мөселманнарның яшәү рәвешен ошатканнар, яратканнар. Тик шунысы бар: Русия мөселманнары урысларга караганда ярлырак яшиләр, авырлык белән гомер кичерәләр, диләр. Моңа аптырауларын белдерделәр. Бездәге мөселман татар хатын-кызларының пәрәнҗәсез йөрүе дә исләрен җибәргән. Начар итеп сөйләмиләр, төрек хатыннарына да пәрәнҗәне ташларга вакыт, дип куялар. Бу мәсьәләдә сүз көрәштереп тә алдылар. Миңа Русиядәге хәлләр кызыклы, сораша башладым. Бу инде 1918 елның язы бит. Ләкин алар Николай патшаның тәхетне ташлавын, хөкүмәт белән Керенскийның идарә иткәнен генә әйтә алдылар. Боларны хөкүмәткә Керенский утыргач кайтарганнар икән. Минем өчен шаккаткыч, кем әйтмешли, табадан яңа гына пешеп төшкән хәбәрләр иде бу. Пленныйлар өчен яшәү шартларының нигә шактый йомшавын аңлый башладым. Элекке кебек каты тәртип кулланырга теләгән капралларга көн бетте. Сугарга дип кул күтәрсәләр, тоткыннар үзләре сугып җибәрергә дә күп сорамыйлар. Аның өчен хөкемгә тартучы юк. Тоткыннар көч куллануны артыкка җибәрсәләр, капрал постовойларны ярдәмгә чакыра, тегеләрнең берсе дә арага кереп кысыласы килми, ишетмәгәнгә салышып, берсе дә ярдәмгә килми:

— Теләмибез, господин капрал! Үзегез төрткән утны үзегез сүндерегез! — диләр.

Эшкә барганда постовойлар форма өчен генә иярә. Элеккеге кебек стройга тезеп мәтәшмиләр. Эш урыннарына баргач та ятып йоклыйлар. Кайберәүләргә ачуы килсә, мастер да постларга ярдәм сорап кычкыра. Ләкин постовойлар аның сүзен тыңламыйлар да, ишетмиләр дә, кырына да бармыйлар. Мастер чәчләрен йолкырдай була. Шулай вакыт үза. Капрал белән постовойлар еш ызгышалар. Капрал аларны җәзага тартмакчы булып, комендантка әләкләп карый, һич теләгәнчә нәтиҗәгә ирешми.

Йокламыйча да төш күреп була икән һәм андый төшнең юрамасы көне-сәгате белән тормышка аша икән. Беркөнне эшне әбиткә хәтле ике сәгать алдан бетердем. Кешегә күренмичә, урман аша туры гына баракка кайтып киттем. Тау башлап барганда, бер ялансулыкка килеп чыктым. Киртләч-киртләч, диваннар тезелгән кебек, таш тезмәләре бар. Арылган иде, утырдым шул таш диваннарның берсенә. Каршымда матур күренеш-манзара ачылды: ямь-яшел үсмер чыршылар белән капланган кечерәк таулар тезелеп киткән. Башка кисәк уй килде. Тукта, мин әйтәм, бу матурлыкны туйганчы бер күреп калыйм әле. Кем белгән, бәлки, иртәгә үк бу җирдән кая булса да алып китәрләр. Шулай хыялга бирелеп шактый утырдым. Ямансу уйларда баракка кайтып яттым да йокладым. Соңлап иптәшләр әбиткә кайттылар. Бергәләп ашарга утырдык. Яссик дигән җирдә эшли идем мин бу чакта. Гәстилдән эшелон килеп төште. Машинист янәшәсенә утырып, управляющий да килгән. Безне стройга тезделәр. Унике иптәш белән минем исем-фамилиямне дә язып алдылар.

— Иртәгә сигез сәгатьтә канцеляриягә төшәсез. Сезне моннан башка җиргә озатабыз, — диде комендант.

Икенче көнне расчёт ясап, безне Сараево шәһәренә җибәрделәр. Сараево, Бүснә-Һәрсәкнең (Босния-Герцеговина) баш шәһәре.

Сараевога өч яктан тимер юл керә. Берсе — Травник ягыннан, берсе — Албания ягыннан, берсе — Белград, ягъни Сербия ягыннан. Сараевода һәм аның тирәләрендә торучылар күбесенчә мөселманнар, хосусан, Сараево халыклары — төрекләр булса кирәк.

Солтан Сәлим хөкем сөргән чорда күп кенә халыклар Төркиядән бире килгәннәр. Кызыгы шул: кешеләр озын гомерле монда. Йөз яшь һәм йөз унбиш яшьтәге картлар бүснәкчә, хорватча да, төрекчә дә сөйләшә беләләр. Яшьләре саф хорватча сөйләшәләр. Монда халыклар күбесенчә йөз яшь яшиләр икән. Сараево тирәсендә завод һәм фабрикалар күп һәм аның тирәсендә төрек алпавытлары да күп. Сирәгрәк православный һәм католик, яһүд, хәтта нимесләр дә бар. Сараево шәһәре төзек. Стеналары тоташ пыяла дүрт-биш катлы йортлардан гына торган урамнар да бар. Электр стансасы да бик зур икән. Сараеводан электр көче унбиш чакрымга хәтле ераклыкларга тарала. Безне Сараеводан дүрт чакрымда читтә урнашкан, Албаниягә китә торган тимер юл өстендәге Ступа дигән стансага китерделәр. Монда да эшкә җиктеләр. Игенчеләр булып киттек. Паровой машина көче белән катлаулы молотилкада ашлык суктырып йөрдек. Ашлык сугу беткәннән соң бәрәңге алуга керештек. Анда бәрәңге дә бик уңа икән. Бер төптән, санап караган булды, йодрык кадәрле туксан-туксан биш данә бәрәңге ала идем. Әле исәпкә алмаган егерме-егерме биш данә ваграклары да була иде. 1918 елның көзе иде бу. Пленный тормышыбыз әле һич үзгәрми. Тик аяусыз каты җәзалар кулланмыйлар, капраллар берхәтле йомшаган төсле күренәләр. Икмәк порциясе артмый, тик шунсы бар — күгәргән ипи бирү бетте, әйбәт, таза икмәк бирәләр. Элек Австрия солдатларына бирелә торган өлеш — бер зур бодай икмәген дүрт пленныйга бирәләр. Аш дигәне — бәрәңгеле, кәбестәле, кабаклы шурпа. Аңа ит яки май катнашмый, ә инде хезмәт мәсьәләсенә килгәндә, көндез дә, кич тә эшкә йөртәләр. Көндезге эш казнага булса, төнге эш капрал һәм башка әфисәрләр кесәсенә эшләнә. Тоткыннарны җирле халыкка сатып акча эшлиләр.

Шулай бервакыт бәрәңге ташып йөри идек. Кичке юлга бардык. Капрал бер юан кеше белән сөйләшеп тора. Җиде олауга бәрәңге төядек. Һәр олауга пар үгез җигелгән. Арбалар алагаем зур, тирән. Һәр арбага йөз пот бәрәңге сыя. Көн болытлы иде. Кояш баеп барганда яңгыр ява башлады. Дүрт чакрым ераклыктагы Сараево шәһәренә җибәрделәр. Кемгәдер җиде олау белән җиде йөз пот бәрәңге илтәбез. Яңгыр көчәя бара, түгә генә инде. Төнге сәгать тугызларда Сараевога барып кердек. Күп урам-тыкрыклардан борыла-борыла бер җиргә килеп туктадык. Җиде йөз пот бәрәңгене, без, чыланып беткән җиде кеше, бушатырга да тиеш бит әле. Юан кеше бушатыр урынны күрсәтте дә, үзе каядыр китеп югалды. Җитмәсә, бәрәңге бушата торган урын шундый урын — ике каралты арасына туры килде. Яңгыр суы ике яклап улактан ташып ага, өскә коелып тора. Коендыра гына! Безнең өстә алама гимнастёрка, алама чалбар, яланаякбыз. Борынгы заманнарда крепостной крәстиян яки кол шундый булгандыр. Төнлә сәгать өчләрдә җиде йөз пот бәрәңгене бер таш өйгә ташып бетердек. Кызу эшлибез инде. Имеш, тизрәк эш бетсен. Кайтыр юлга чыктык. Урамнарда электр яна. Шәһәр көндезге кебек якты. Рельс буйлап чаңлап трамвай килә. Мин алда идем. Трамвайга юл салу нияте белән читкә тартам үгезләрне. Читкә чыгу турында уйламыйлар да. Бирә звонокны трамвай. Колакны ярып чаң-чаң, чаң-чаң килә. Булмагач булмый инде, үгезләрне юлдан чыгара алмадым, дилбегәне ташладым да, читтән карап тора

башладым. Кем җиңәр: үгезләрме, әллә трамваймы? Шалтыратып килде-килде дә трамвай туктады. Үгезләрем электр яктысында күзләрен яшелләндереп, трамвайга акаеп карап тик торалар. Болай карап торулары: «Кемнәр сез, нишләп йөрисез монда?» — дигән сыманрак иде.

Трамвайда халык күп иде. Бар анда ирләр, хатын-кызлар, хәтта пәрәнҗәләрен югары баш өсләренә ташлап, йөзләрен ачкан яшь төрек хатыннары да күренә иде. Үгез кайгысы китте. Төрек кызларына карап: «Сөбханалла, чибәрләр икән!» — дип уйладым мин. Трамвайдагылар төшеп, безне сырып алдылар. Аларның безгә түгел, кемнәргәдер яман ачулары чыккан. Йөзләре ярсудан ярылырга тора. «Әллә бу господалар безгә ачуланалармы? Тирес битләр...» — дип куйды бер иптәшем.

Пәрәнҗәләрен күтәргән матур йөзле кызлар ныклап шаулыйлар:

— Әй мескеннәр, көндез эшләүләре җитмәгән, җиде төн уртасында да йокысыз-нисез, ач килеш кара яңгырларда эшләргә мәҗбүр итәләр!..

— Аһ, Аллам, ялан аяклары, аһ, Аллам, өс-башлары... — дип хатын-кызлар аһ-ваһ киләләр.

Арадан бер зыялы ир кеше сүзгә кереште:

— Тыңлагыз, урысскийлар! — дип кычкырды ул. — Тиешенчә, яхшы итеп солдатларча киендермәсәләр, иртәгә эшкә чыкмагыз! Тиешенчә, кешеләрчә ашатмасалар, бервакытта да эшкә чыкмагыз! Бүгеннән соң беркайчан да төнлә эшкә чыкмагыз. Сезнең Русия ягында пленда калган безнең братлар барысы да кайтып беттеләр хәзер... Ник сезне кайтармыйлар? Сорагыз, таләп итегез, сезне дә кайтарырга тиешләр! — дип сүзен бетерде.

Кондуктор формасындагы кеше ялынган тавыш белән:

— Кадерле урысскийлар, үгезләрегезне юлдан алыйк инде, — диде.

Җыйнаулашып арбаларны берәм-берәм юлдан чыгардык. Трамвайдагылар кулларын изәп китеп бардылар. Кар катыш яңгыр ява башлады. Салкын, түзеп тормалы түгел, күшектек. Үгезләрне ташлап, күз күргән якка йөгерәсе килә. Үгезләр бер дә ашыкмыйлар. Салкын җил торган саен көчлерәк өрә. Арбада ышык түгел. Таң атканда кайтып кердек. Йоклап алгандай иттек, эчкә җылы кереп җитмәгән иде әле. Иртән капрал, уятып, тагын үгезләребезне җигәргә кушты. Мин отказаться иттем. Капрал җикеренергә кереште. Мин аңа каршы:

— Төнлә җиде йөз пот дәүләт бәрәңгесен каядыр аткардыгыз, шуны эшләп көчебез бетте. Өстебезгә кием бир. Кичә безгә Сараевода бер әфисәр киемсез эшкә чыкмаска кушты. Төнлә эшләүнең дә канунсызлык икәнен аңлатты.

Сүземне әйтеп өлгермәдем, капрал яңагыма сугып җибәрде. Җен ачуым чыкты. Теге капралга шундый итеп сугып җибәрдем, капралым һавада дуга ясап әйләнде дә, мәтәлләп, өч метр ераклыкка барып төште. Капрал үзе генә безгә каршы тора алмый, авыр эштән безнең беләкләр корыч кебек каткан. Бер бирсәк, уртача юанлыктагы имәнне сындыра алабыз. Капрал торып башын чайкап алды, аннан постовойларны чакыра башлады. Сакчылар чыгып безнең якка карап тордылар да:

— Господин капрал, синең өчен тоткыннар белән сугышып йөрү безнең вазифага керми, тоткыннарга көч куллануга без каршы! — дип, кире баракка, җылы бүлмәләренә кереп киттеләр. Капрал сүгенә-сүгенә алар артыннан йөгерде.

Әбит вакытында безгә кием-салым китерделәр. Йоклаганда ябынырга берәр одеал да бирделәр. Биргән киемнәре яңа түгел, искене ямап корыштырган киемнәр иде. Күрәсең, тоткыннарга дип күптән кайтарылган шушы иске киемнәрне дә бирмичә йөрткәннәр.

Арабызда яһүд егетләре дә бар иде. Дус күреп йөрүче Майорзон һәм Абрамов фамилияле ике яһүд бар иде. Майорзон белән Абрамов минем кебек гади эшчеләр иде. Икесе дә минем белән бергә торба заводына гәстилдән килгәннәр

иде. Акча тотуда артык сак булулары өчен һәрвакыт тәнкыйть итә идем. Алар миңа һәрвакыт:

— Иртәгәне уйламыйча бар булганны тиз тотып бетерү ахмаклык бит, юләрлек. Син, Латыйпыч, болай карауга, бер дә юләр төсле түгел. Әмма алган акчаңны көнендә эчеп бетерүең бер дә килешми. Алтмыш крона акчаны бер утыруда эчеп бетерәсең. Өч көн кәефсезләнеп, башыңны күтәрә алмыйча, аһ-ух килеп, салкын су эчеп йөрисең. Синең исәнлегең үзеңнән башка беркемгә дә кирәкми, врачлар эчү авыруыннан көчсез, саклый алмаслар, — дип кисәтәләр иде. Өстәп тә куялар — эчмә! Башыңны саклау турында уйла! Булган хәтле яхшы аш кына аша. Илеңә сау-сәламәт булып кайтырга тырыш. Русиядә синнән башка да инвалидлар җитәрлек, күргәнсеңдер, меңәрләп-меңәрләп кайтып киттеләр...

Бу акыллы үгет-нәсыйхәтләрен аңласам да, аларны һәнүз үртәргә яратам:

— Минем әти-әни җәбрәй түгел шул, без — татарлар! Белгәнегезчә, иң беренче татар туган көнне җәбрәйләр, кайгыга сабышып, өч көн елап ятканнар. Үз акылыгызны үзегезгә саклагыз, татарлар җәбрәйләрдән акыл өйрәнергә мохтаҗ түгел, — дигән булам.

— Акыллы дурак син, Латыйпыч, — ди Абрамов, елмаеп.

Майорзон кызу канлы:

— Нинди акыл булсын анда? Шыр тиле! Тел әрәм итеп киңәш биреп маташкан булабыз, җитмәсә! Ипи шүрлегеңә менеп төшсәм, белерсең кемнең кайчан, ничек елаганын, — дип, тизрәк минем яннан китеп бара.

Дустымның болай ачуланганын сирәк күргәнгә, инде мин кычкырып көләм. Чыннан да миңа яхшылык теләүче әйбәт егетләр иде алар.

Абрамов бу отделениедәге урыс пленныйларына старшой-өлкән булып тора. Агроном кеше ул, игенчелек остасы. Шуңа күрә булса кирәк, бу яһүд хәтта Австрия кенәзләре белән дә озаклап сөйләшеп тора. Яһүд, эшкә кагылышлы булса, үз фикерен ачык итеп әйтә, фикерен яклый ала. Бик закунный сөйлиләр. Шул ук вакытта хәйләкәрлек тә җитәрлек. Пленныйларга акчаны үзе барып ала, үзе өләшә, кемгә күпме акча тиеш икәнен бераү дә белми. Беркайчан да акчасыз йөрмиләр, һәрчак чиста, пөхтә киенгән булалар. Шуңа күрә башка пленныйларның өлешенә дә кергәндер ул старшой, дип уйлап куям.

Яһүдләргә немесләр бик каныгалар иде. Дрезден лагеренда булган бер вакыйганы язып үтим әле. Бу лагерь авыр яралыларны, каты авыруларны Русиягә озата торган лагерь санала иде. Русиягә кайтару өчен иң соңгы комиссия шушында була. Комиссиядә бер пленный яһүд табибы да эшләгән. Озак вакытлар, күбесенчә, ул биргән белешмә буенча авырулар һәм яралылар Русиягә җибәрелгәннәр. Яһүд табибы, гомерен куркыныч астына куеп, меңләгән сау-сәламәт пленныйларны да Русиягә җибәрергә өлгергән. Немесләр моны сизеп алганнар.

Австриянең хәрби суды бу яһүд врачын балта белән турап үтерергә хөкем итте. Лагерьда, барча хәрби пленныйларны җыйнап, суд карарын укыдылар. Җыйналган халык алдында палач балта тотып, баганага бәйләнгән шәп-шәрә яһүд врачы каршысына килде. Бер кулын чабып өзде, аннан икенчесен, аннан соң бер ботын, аннан икенчесен, иң соңыннан муенын чабып өзде. Бу еркычлыкны карап торырга ничек көчем җиткәндер, хәзер дә аңлый алмыйм. Немесләрнең ерткычлыгыннан һушсыз калып тору гына булгандыр инде ул. Менә сезгә немесләрнең кануны, тәрбиясе. «Кеше» дип санарга да кыен. Бу вакыйга 1916 елның декабрь аенда булган иде. Шушы вакыйганың шаһиты булган авылдашым яралы пленныйларны Русиягә озатучы командада санитар булып хезмәт итә иде. Яһүд табибының сәяси партия члены булуын әйтте. «Нинди сәяси партия булгандыр, мин аңламадым», — диде.

Чын батырлар көрәште ил өчен, ирек өчен,
Тормышларын корбан итте кадерле идеал өчен.
Утка-суга ташландылар, чикмәделәр көрәштән,
Татымаган җәзалар калмады дошман-палачтан.
Алар җиңмәгән фронтлар булмады һәм тумады,
Хаклык өстә, ялган аста, ялган хакны бумады!

X

Ступа стансасының бер ягында зур усадьбалы төрек баяры бар иде. Аның игенен паровой машина көче белән сиксән кеше бер ай суктык. Катлаулы сугу машинасы сугылган икмәкне өч сортка аерып чыгара. Мин капчыкларны алмаштырып гергә утыртып, үлчәвен тигезләп, капчык авызын тимерчыбык белән борып тордым. Эшемне баяр үзе урындыкта утырып карап торды. Баяр болай нык кына җегәрле карт иде. Русия мөселманы икәнлегемне белгәч, мине хыянәтсез дип ышанды. Ул беркөнне миңа:

— Егет, син нәрсә уйлыйсың? Менә мин хәзер йөз дә бер яшемдә. Беркемем дә юк. Тик бердәнбер кыз балам бар. Кызымны яхшылап күзәтче. Әгәр дә мәслихәт күрсәң, кызыма кияү, үземә уллыкка керә алмассыңмы? — Ул, урыныннан торып, үз усадьбасына таба карап колачын җәйде. — Әнә шулхәтле имениеләрем барсы да сиңа кала. Ике йөз хезмәтчеләрем бар. Шуларны өйрәтеп, эшләттерә белсәң, шул җитә. Үзең эшләүнең кирәге юк.

— Мөмкин түгел, бабай. Җәяүләп үз илемә кайтачакмын. Энем, абыем сугышта һәлак булдылар. Мине карт әти-әнием өзелеп көтеп торалар. Чын ышанып, шундый тәкъдимне әйтүегезгә рәхмәт, — дидем.

Карт, өметсезлек белән тирән уйга чумып, сүзсез калды. Картның унике яшьләр чамасында бердәнбер кызы, сабый гына булса да, чая, үткен, зирәк иде. Монда кызлар иртә өлгерәләр. Унике яшьтә инде кияү турында уйлый башлыйлар.

Ступаның икенче ягында кырык яшьләр чамасында тагы бер төрек бар. Бу төрекнең дә таштан салынган икешәр катлы дүрт шәп өе бар. Өй тирәсендә җимеш бакчасы һәм иген игә торган җирләре. Төрекнең өч туганы булган. Сугыштамы, ничектер, моның туганнары үлеп беткәннәр. Энеләре үлгәч, өч киленне үзенә хатынлыкка алган. Хәзер дүрт хатыны бар, һәркайсы аерым йортта яшиләр. Дүрт хатыннан дүрт кызы җитеп килә, кызлар гәүдәгә килешле, алма кебек пешеп җиткәннәр, бүгеннән тотып кияүгә бирергә була. Шушы төрек бервакыт мине очратып:

— Хаҗи, — диде («хаҗи» аларча белемле, укымышлы дигән сүз), — дүрт кызым берчә җиттеләр. Син нәрсә уйлыйсың? Кызларымның кайсын теләсәң, шунысын үзеңә хатынлыкка бирәм. Дүрт өемнең берсе сиңа булыр. Җимеш бакчасы, иген басулары да сиңа булыр, — диде. Миңа ышанганы күренеп тора. Моңарчы да мине гел күзәтеп йөрде, үзендә эшләп йөрүче иптәшләремнән дә күп сорашкан. Иптәшләрем: «Укытучы егет ул», — дип, минем хакта күптөрле мактау сүзләре яудырганнар икән.

— Тәкъдимеңә зур рәхмәт. Ләкин булдыра алмыйм. Мин үз илемә кайтам, —дидем.

Ул миңа каты гына итеп:

— Әле егерме елсыз кайта алмассың. Русиядә тагын сугышлар кузгалып торганлыгын хәбәр итәләр, — дип, күземә карап алды.

— Ялган хәбәр ул… — Илдәге хәлләрне бөтендәй белмәсәм дә, бирешәсем килмәде.

Бик якын дустым — башкорт егете бар иде. Ырынбур башкорты, Кадербәкев Ибраһим исемле иде ул. Урыслар аны «Абрам», мине «Захар» дип йөртә башламакчылар иде. Чын исемем Зариф бит. Үзләренчә исем тагып кына куялар башка кавем кешесенә. Без каршы төштек, мулла кушкан исемнәребезне үзгәрттермәдек.

Беркөнне, эшкә стройга тезелүдән алда, барактан чыгып качтык. Шәһәргә барасыбыз килә иде. Башта посып тордык. Тавыш-тын беткәнне озак көтәргә туры килде. Старшой яһүднең күзенә күренүдән куркабыз. Ул безнең эштән калганны күрсә, атна буе бәйләнеп, теңкәне корытачак иде. Капралга сатып ук куярга да күп сорамас.

Шәһәргә бардык. Инде сәгать тугызга җиткән иде. Азрак күңел күтәрерлек төшем алу өчен, эш эзли башадык. Вакыт соң булганга күрә, бер дә эш таба алмадык. Сүз каткан һәркем:

— Соң инде. Эшче кирәк хуҗалар таралышып беттеләр, — диләр. Килдек шәһәрнең базарына. Уналты яшьләр чамасындагы сөт сатучы малай:

— Нәрсә, урысскийлар, эш эзлисезме? — дип сорады. Каршысында ике бидон сөте утыра.

— Эш эзләгән идек, эш бирүче булмады. Вакыт соң инде, диләр...

— Берегезне хәзер үзем алып китәм. Сез икәү бит, берегез генә кирәк.

Кадербәкев белән карашып торабыз.

— Кайсыбыз тәвәккәлле соң? — дидем Кадербәкевка карап.

— Икебезне дә алмаса, беребез дә бармыйбыз! — диде.

— Ятып калганчы, атып кал, әйдә, син китә тор, — дидем. — Бәлки, бераздан миңа да бәхет елмаер...

Менә бәла, сөт сатучы малай Кадербәкевне аласы килми, аңа мин ныграк ошадым булса кирәк.

Кадербәкев, үзсүзле башкорт, үземне генә җибәрүгә каршы төште, минем дә дустым Кадербәкевне базар уртасында калдырып китәсем килми. Шулай итеп, килешә алмадык. Базардан чыктык. Күңелсез төстә, баракка кайтып киләбез.

Шул арада әлеге малай пар атын чаптырып, безнең арттан куып җитте. Тагын сатулашабыз. Малай икебезне дә алмый. Мине генә ала. Мине Кадербәкев җибәрми. Ахырда, Кадербәкевкә үпкәләргә урын калдырмыйча:

— Барып, күреп кайтыйм әле. Кайда, ничек, ниндирәк эш микән? Эше бүгенлек кенә микән? Ике-өч көнлек булса, иртәгә сине дә алып барырмын, — дидем. Бу Кадербәкевны юату гына иде инде.

Тарантаска сикереп менеп утырдым. Малай атларын кире борды. Кире шәһәргә кердек, шәһәрдән икенче тарафка киткән шоссейка белән чыгып киттек. Малайны нимес малаена охшаттым. Ул хорватча сөйләшә иде. Гаилә хәлләре, кәсепләре хакында сорашам. Фәкать авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүләре хакында сөйли яшүсмер.

— Әтием олыгаеп бара. Ике айдан бирле, бер дә кайтмыйча, паровой машина белән кешеләрнең игеннәрен суктырып йөри. Килешү буенча. Договорны бозу ярамый, хөкемгә тарталар, — ди малай белдеклеләнеп. — Шушы көннәрдә үзебезнең игеннәрне суктырырга кайтачак. Өйдә әнием һәм бер сеңлем бар...

Хыял яшендәй уйнап алды. Малай бик чибәр нәрсә, сеңлесе дә төшеп калганнардан түгелдер. Травникта су сөлегедәй төрек килене үзәкне өзгән иде инде. Моның сеңлесе аннан да чибәрдер...

— Еракмы әле, кайчан барып җитәбез? — дип сорыйм. Малай, кесә сәгатен алып, кояшка күтәрә төшеп, угына карап алды.

— Нәкъ сәгать өчтә өйдә булабыз...

Әле сәгать уннар чамасы гына. Теркелдисе бар икән.

— Ерак яшисез икән шәһәрдән.

— Два десять и пять километр, — диде малай хорватчалап.

— Һо… Мин бит аерым тәртип белән яшәүче кеше. Русия әсире. Миңа бүген эшне бетереп, бүген үк кайтырга да кирәк. Ату капрал «кых» итәчәк, — дидем сабырсызланып. Бу арадан ничек кайтып җитәргә? Артка борылып, Сараево шәһәренә карап алдым. Шәһәрдән шактый ераклашканбыз инде. Әллә соң арбадан сикереп төшеп калыргамы? Сабыр итәргә булдым.

Малай, уйларымны укыгандай:

— Хафаланма, бездә сиңа яхшы булыр. Сыерлар сөтне күп бирәләр, күпме телисең, шулкадәрле сало ашарсың, — диде көлеп. Күңелне күтәрергә тырыша.

Егерме биш чакрымны шоссейка юлы белән генә бардык. Шоссейкадан уңга борылып, басу юллары белән тагын өч чакрым кергәч, ниһаять, нәкъ сәгать өчтә килеп төртелдек малайның ихатасына. Абыйсын каршы алырга унбиш яшьләр тирәсендәге чибәр кызый йөгереп чыкты. Акчарлак очуына гына тиңләп була аның йөзеп-йөгереп килүен. Артыннан әнисе чыгып килә. Кыз шунда ук минем исем һәм фамилиямне сорады. Теленнән өзмичә исемемне кабатлап йөргән була. Үзенчә кызыктыр инде. Атларны тугардык, өйгә кердек. Өйгә керүгә, болар «һау» да «һау» килеп, немесчә сөйләшергә керештеләр.

Карчык, кинәт минем барлыкны итсенә төшергәндәй, миңа борылды:

— Сез немесчә сөйләшә белмисезме?..

Хорватчаны эшкә җигеп:

— Юк, — дип баш чайкадым.

— Алай… Хорватча пупалыйсыз икән… Исемегез төрекләрнекенә тартым, әллә сез Русия мөселманымы? — дип кызыксынды хатын. Ул инде шактый олыгаеп килә, күрәсең, кияүгә соңгарак калып чыккандыр. Кешегә хөрмәт белән карарга өйрәнгән, әсир кешегә дә «сез» дип дәшә.

— Әйе, — дидем мин, артык җәелеп китмичә. Чынлыкта, мин немесчә дә шактый шомарган идем.

Карчык, нигәдер, уңайсызланган кыяфәт белән:

— Димәк, сез дуңгыз ите ашамыйсыз? Бездә моңа хәтле Абдул дигән татар хезмәтчесе торган иде. Дуңгыз итен авызына да алмады. Яхшы гына эшли иде, качты, — диде.

— Тоткынлыкта шәригать кануннары җан сакларга өнди, ни-нәрсә ашауга бәйләнми. Шулай да, дуңгыз ите ашауга мин каршы, — дигәч, карчык нигәдер елмаеп куйды.

Алар немесчә сөйләнәләр. Нәрсә хакында сөйләнүләрен аңлап торам. Малай шәһәрдән алып кайткан тауарларын — йозак, таба, кадакише әйберләрен әнисенә биреп, һәркайсын ни бәһадән алганлыгын әйтә. Ике бидон сөтне ни бәһадән сатканлыгын, күпме акча алганлыгына хисап бирә. Немесләр төгәл халык, тиенне дә әрәм итмиләр. Русиядә андый төгәллек юк, һәркем, кул астына ни эләксә, шуны чәлдерү турында гына уйлый. Русия кешесе эшлим дип кайда бышын тыкса да иң элек ни-нәрсә урларга мөмкин икәнлеген тикшереп чыга.

Малай мине мактап сөйләргә кереште:

— Бу әсирләр икәү иде. Икесе дә килергә теләделәр. Мин гәүдәгә зуррагын, көчлерәген алып кайттым.

Әнисе «яхшы булган» дигәнне белдереп, ияк кагып алды да, этиләре кайтуга хәзерләнеп торырга боерып, малайга эшләр йөкли башлады.

Мине эшсез озак тотмадылар. Сөт өсте-каймакта пешкән кабак боламыгы ашаттылар һәм, кулга балта тоттырып, әрәмәлектәге балан куаклыгын кыркып, печәнлек җире хәзерләргә боердылар. Малай, мине эш урынына алып барып, ничек эшләргә икәнлеген өйрәтеп бирде дә үзе кайтып китте.

Нишләптер боларның өйләре бер дә нимес өенә охшамаган. Тузып беткән хорват өе иде бу. Димәк, бу йорт-җирнең хуҗасын — хорват кешесен куганнар да ихатасына шушы нимесне китереп керткәннәр. Гайрәтем чикте. Чибәр нимес кызы Анна да һич күңелемә ошамады. Нимес кайда да нимес, кяфернең дә кяфере икән. Бар кайгысы: кеше җирен басып алып, талап, төп хуҗаны куып, тар-мар китерү.

Озакламый этиләре кайтты. Аны малай минем янга алып килде. Бар көчемә эшләгәнемә сокланып карап торды карт нимес. Эшемнән туктатып, миңа бәйләнергә тотынды.

— Син, солдат, бездә генә кал, — ди. — Русиядә хәзер зур сугыш кабынды, революция бара, — ди. — Русиягә кайттың исә, икенче көнне үк сугышка алып китәләр. Анда ата — улны, ана — кызны белми, шиксез, үләчәксең. Кал бездә, рәхәтләнеп эшлә, тормышыңны рәтләрбез, — ди. Кыставына чуерташ эрер иде. Үз илем барлыгын, анда карт эти-әниемнең мине тилмереп көтеп торулары хакында аңларга да теләми. Аларны сөйли башласам, кулын гына селти. Тыңласа — ишетми, ишетсә — тыңламый икән ул нимес кавеме.

Өч көн шулай үтте. Анна янымнан китми, калырга үгетли, шаяртудан туймый. Шушы өч көн эчендә бу кыстаулардан, Аннаның туктаусыз янымда әйләнүеннән тәмам ялыктым. Башта кызык иде, хәзер инде чибәрлеге күземә күренми. Ахырда, түзмәдем, эшләгәнгә бер тиен дә акча сорап тормыйча, тоттым да качтым. Качуымны сизгән Анна артымнан куып җитте. Караңгы төшеп килә иде инде.

— Китмә, син миңа ошадың! — дип иңсәгә сарыла. Әллә нинди яхшылыклар вәгъдә кыла.

Эреп китә башлавымны тоеп, үземне кулга алдым. Өч көннән соң килергә ялган вәгъдәмне биреп, шоссейкага чыгып, шәһәр ягына табан йөгердем. Анна артымнан карап калды.

Кайтышлый бер хәрчәүнәгә кереп тамак чылаттым. Башка шактый китте. Кадербәкевкә шушы баштан кичкән маҗараларны сөйләп бирдем. Арттырып инде, әлбәттә. Минем сөйләвем буенча, өч төн рәттән Анна белән сәндерәдә аунаганбыз, тагын шунда китәргә җыенам, имеш. Авызга шайтан суы керсә, телгә әллә нәрсәләр килә ул. Кайсы чын, кайсы ялган икәнен үзең дә аермый башлыйсың.

Бу сүзләргә Кадербәкев рәнҗеде.

— Килешкән эш түгел инде бу, — диде кызып. — Илгә кайтканчы, һәрчак бергә булырбыз, дип кул бирештек. Сүзеңдә тормасаң, беркайчан да уңмассың. Гәстилдән киткәндә, управляющийга ялынганыңны оныттыңмы? Кадербәкевне җибәрмәсәгез, мин дә бармыйм, дип тартыштың. Монда килүгә, мине бар дип тә белмисең, яңа дуслар таптың…

P.S. Шушы урында әсәр өзелә. Автобиографик бәянның юкка чыккан өлеше әллә ни күп түгелдер. Чөнки Зариф Мөэминов 1919 елда исән-имин туган авылы — Мөслим районы Теләнчегә (хәзерге Октябрь) кайтып керә һәм укытучылык эшенә керешә. Бу хакта «Чын мирас» журналында (№1, 2014) шактый әтрафлы итеп язылган иде инде. Кызыксынучылар булса, әлбәттә, аны табып укый ала.

Әдәби эшкәртүче, искәрмә-аңлатмалар бирүче —
Фаргил Сафин

«Безнең мирас» – затлы бүләк!

«Безнең мирас» журналының 6 нчы саны тышлыгында 1973 елгы Сабан туе батырының рәсемен күргәч, чын Сабан туйлары, чын үзебезнең авыл батырлары чорына кайткандай булдым: бактың исә, безнең үсмер-яшьлек еллары да «мирас» дип аталырлык көн җиткән. Казан дәүләт университетының студентлар торагында (җитмешенче еллар) бик яратып сөйләнгән һәм көлдергән: «Оча еллар», — дип зарланган ташбака (ни кызыгын табып көлдек икән?) халәтендә калдык: чыннан да, гомер тиз уза икән.

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә филне дә сатып җибәрерлек журналист **Нәсим Акмал** эшли. Матбугатның яңа саннарына күзәтүләре белән ул мине 2015 елның гыйнварыннан **«Безнең мирас»** журналына язылырга «мәҗбүр итте».

Сөбханалла, аерыла алмыйча укырлык журнал чыгып ята икән бит! Почта тартмасыннан алып лифтта ук **«100 ел элек...»** («Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре») сәхифәсен укый-укый менәм. Хикмә-әт, 1915 ел яңалыкларындагы кайбер исем-фамилия һәм оешма атамаларын алыштырсаң, бүгенгебез килә дә чыга!

Студент елларында без күрергә дә хыяллана алмаган документларны, истәлекләрне, әсәрләрне гаҗәпләнеп укыйсың. Күңелгә уелып калганнарыннан **Марсель Әхмәтҗановның** тел галиме **Җәвад Алмазның** тормыш юлы, фәнни мирасы турында **«Миңа тигән зәһәр җилләр...»** язмасы, **Рәис Зариповның «Кара генерал»**, **Вафа Бәхтияровның «Тукай турындагы истәлекләр»**е, **Риза Фәхреддин** хезмәтләре, **Рифә Рахманның «Пәри — башка, җен — башка»** мәкаләсе, **«Түгәрәк өстәл»**ләр, **Рүзәл Мөхәммәтшаның Зөлфәт** һәм **Мөдәррис Әгъләмнең** ике шигырен өйрәнүгә багышланган **«Бер сүздән тора дөнья...»**сы, **Ләбиб Леронның** Татарстан Язучылар союзының элекке еллардагы беркетмәләрен файдаланып, фотолар белән бирелгән язмалары, Нәсим Акмалның **Госман** абый **Әхмәтҗанов** турында **«Яңгырап торган мирас калдырды»** истәлекләрен санарга була. «Безнең мирас»ны укыганда **Җәүдәт Дәрзаман** «Татарстан» радиосында алып барган цикл сүзләре хәтергә килә: «Сагындырып искә төшәләр дә...»

Әүвәл миндә: «Укылган журналларны ярты ел саен берәр мәктәп китапханәсенә бирә барырмын», — дигән уй булган иде. Яңарак кына 2015 елның 1 нче санын актара башлаган идем, грипп чорында күз уңыннан читтә калган **«Кыйссаи Йосыфны»** нәшер итү кыйссасын (Татарстан Язучылар союзының 1969 ел, 28 гыйнвардагы идарә утырышы беркетмәсе) рәхәтләнеп укып чыктым. **Сибгат Хәким**, **Риза Ишморат**, **Гомәр Бәширов** сүзләрен күргәч, нинди төпле фикерле, гадел өлкәннәребез бар иде, дип горурландым һәм сокландым. Биредә сүз, күпләрнең исендәдер әле, **Кол Галинең** 1983 елда 10 мең тираж белән басылып чыгачак «Кыйссаи Йосыф» китабы турында бара. Мин ул затлы итеп эшләнгән китапның (сатуга чыгарылды микән?) югары даирә кешеләре арасында таралып бетүен, безнең ишеләргә эләкмәвен дә хәтерлим.

Журналның бүген килеп ирешкән 8

Риф Якуповның «Сабантуй» альбомыннан

нче саны тышлыгында якташым **Бакый Урманче** ясаган **«Абай»** портреты һәм шулай ук якташым **Туфан Миңнуллинның** тирән мәгънәле шигыре белән ачыла. «Түгәрәк өстәл»нең эчтәлеге, анда катнашучыларның туксанынчы еллар турында хатирәләре — оныкларыбызга васыять итеп җыеп куярлык.

Советлар заманында хыялланырга да мөмкин булмаган (ә киләчәкне бер Аллаһ белә) мондый журналны — милләтебезнең яшерелеп яткан шәхесләрен, тирән фикерләрен, Җәвад Ногман улы Алмаз кебек догадан өзелергә мөмкин булган фидакяр галимнәрен үзебезгә һәм киләчәк буыннарга ирештерүче басманы яшәтергә иде бит! Югарыдагылар өчен әйтә алмыйм, әмма үзебез булдыра алганны тәкъдим итәм. Сентябрь аенда матбугатка язылу башлангач, журналны алдырып укучы һәркем туган мәктәбенә, дустына, күршесенә, эти-әнисенә, бигрәк тә, әбибабасынамы бер данә генә булса да шушы журналны яздырып (Татарстанның теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин), декабрь азакларында, яңа елга бүләк итеп, квитанциясен җибәрсә... бәясе бер кап кәнфит хакы гына булса да, «Безнең мирас» якыннарыгызга ай саен сездән якты, бай сәлам булып килеп керәчәк. Тәгаен шулай буласын беләм — күп мәртәбә сыналган алым.

Хатымның башында «Татарстан» радиосында филне дә сатып җибәрә алырдай тапшырулар әзерләнүен язган идем. Ул мәзәкне мин күптән түгел генә ишеттем. Берәү дустына филен тәкъдим иткән.

— Хортумыннан су сиптереп, душтан да әйбәтрәк юындыра, хатының, балаларың утырып йөрер, ул булганда сиңа берни дә, беркем дә куркыныч түгел. Сатып ал минем филне, — дигән. Дусты алган. Бер айдан очрашканнар.

— Син миңа нәрсә саттың, үзеннән ис килә, өйдәге барлык җиһазны ватып бетерде. Хезмәт хакым аны ашатырга җитми, — дип зарлана филнең яңа хуҗасы.

— Юк, дустым, мондый кәеф белән син филеңне берәүгә дә сата алмыйсың, — дигән беренче хуҗа.

Нәсим Акмал тапшыруына ышанып алган «фил»ем — затлы мал булып чыкты, шөкер.

Наилә Вилданова,
Чаллы шәһәре

Редакциядән:

Беренче чиратта, безнең тыйнак хезмәтебезне күреп, бәһаләп, хат аша җылы сүзләрен юллаган Наилә ханымга һәм аны журналыбызга язылырга «котырта алган» Нәсим әфәндегә зур рәхмәт, әлбәттә! Үз эшеңнең комга түгелгән су булмавын күрү, белү рәхәтлек китерә, икеләтә тырышып, яратып эшләргә дәрт өсти. Икенчедән, укучыбыз телгә алган 6 нчы сан тышлыгына тукталасы килә. Без ул фотосурәткә бәйле бер кечкенә «кызык»ны бәян итеп бетермәгән идек. Шул хәл ничә ай инде күңел төбебезне кытыклап тора. Бәй, менә дигән форсат туды түгелме соң?

Әлеге тышлык — Рифкать Якупов төшергән һәм ике мөстәкыйль рәсемнән торган фотовакыйганың бер өлеше ул. Бозтау-айсбергның өске катламы. Ә астында менә мондый хәлләр ята...

Шәледә була бу хәл. Әлеге дә баягы 1973 елда. Баш батыр исеме өчен көрәшкә соңгы пар кала: туксан килограммга якын авырлыклы Алып батыр белән кечкенә буйлы, авырлыгы алтмыш килограммнан артмаган егет. Сөлгеләр салына... Шулвакыт мәйдан уртасына әлеге «җилкенчәк»нең әнисе килеп чыкмасынмы! «Кая карыйсыз, — дип кычкыра ул хөкемдарларга. — Бу әзмәвер минем улымны үтерә бит!» Апаны көч-хәл белән генә тынычландыралар. Ә улы нык, чыныккан, әзерләнгән булган, күрәсең: ярты сәгать тирләппешеп көрәшкәннән соң, бар кешене шаккатырып, көндәшен күтәреп сала.

Шул егет «Безнең мирас» журналының алтынчы сан тышлыгында елмаеп тора да инде. ■





ФАРФОР ЭШЛӘНМӘЛӘР

(ТР Милли музее фондларыннан)

Фарфор үзенең ныклыгы, чисталыгы белән башка керамик материаллардан аерылып тора. Аың формасы һәм төшерелгән сурәтләр вакыт үтү белән үзгәрми, кайнар һәм салкын су, кискен температура үзгәрешләре дә аның сыйфатына зыян салмый.

ТР Милли музеенда Кытай, Япония, Россиянең император һәм Европаның танылган Мейсен заводында чыгарылган фарфор эшләнмәләре саклана.

***Гүзәлия Җәләлева** әзерләде.*

ИЛҺАМ – КҮҢЕЛ КАНАТЫ

Дания Гайнетдинова

Мин тауларга гашыйк, алар мине
Иңнәренә кадәр күтәрде.
Тауларыма булган мәхәббәтем,
Сагынуым белмим, бетәрме?

Ерак Себердә дә үз иттеләр,
Шөгердә дә таулар янәшә.
Горур таулар миңа илһам өсти,
Кыя таулар мине яшәртә.

Әйе, әлеге шигырь юллары рәссам Мансур Закировның күңел халәтен, яшәешен һәм иҗат дөньясын берникадәр күзалларга мөмкинлек бирә сыман.

Шөгердә туып, бүгенге көндә дә шунда яшәп иҗат итүче рәссам Мансур Салих улы Закиров Лениногорск каласындагы музыка-сәнгать педагогика училищесын тәмамлап, бүгенге көндә дә үз туган ягына тугры калып иҗат итүче рәссамнар арасында, ихтимал, бердәнбердер. Дөрес, заманында ул ерак Себердә,Чукотка, Магадан, Хабаровскида да яшәп ала. Акча кытлыгы гына түгел, Рокуэлл Кент картиналарында һәм Джек Лондон хикәяләрендә тасвирланган ерак Төньяк тынлыгы, ап-ак, чиксез киңлекләр, зәһәр өермәләр, куе томаннар дәшә рәссамны. Шул кырыс табигатьне күрәсе килү уе әйдәкли аны Себер якларына. Диңгез ярында дулкыннар шаулавын, акчарлаклар тавышын тыңларга ярата ул. Табигатьнең күз ачып-йомган арада әллә ничә төскә кереп үзгәрүен тизрәк ап-ак киндергә иңдереп калыйм, дип кулыннан кылкаләмен төшерми Мансур абый. Төньякның, башлыча Чукотканың табигатен, гади күз белән күреп булмаган әкияти гүзәллеген, шул мохит экзотикасын оста, сәнгатьле, ачык итеп сурәтли ул. Шунда иҗат иткән әсәрләрен беренче тапкыр 1982 елда Анадырь шәһәрендә шәхси күргәзмәсендә Себер халкына тәкъдим итә. Ә 1985 елда исә, Владивосток шәһәрендә «Ерак Көнчыгыш» дигән төбәкара күргәзмәдә катнаша. Мәгърур тауларның көч-куәте,

«Туган як». Киндер, майлы буяу

«Чукотка гүзәле». Киндер, майлы буяу

рәссамның кылкаләме аша гәүдәләнеп, тамашачының күңеленә үтеп кирәрлек итеп иҗат ителгән. «Анадырь култыгы өстендә иртә», «Колыма көзе», «Диңгез киңлекләре» кебек картиналар — нәкь менә шундыйлардан.

1989 елда Мансур Закиров туган ягы Шөгергә әйләнеп кайта һәм үз әсәрләрендә туган як табигатенең матурлыгын тасвирлый башлый. Ел фасылларының гүзәл бизәкләре, мәһабәт таулар, урман, болыннар, су буенда балыкчы картны көткән көймәләр, төнге ай, офыктан күтәрелеп килүче кояш һәм башка бик күп образлар һәммәсе дә җанлы, тере... Әйтерсең лә, алар тамашачыга нидер пышылдый, сер сөйли. Һәр иҗат эше үзенә тартып тора. Авторның үз иҗатына, Табигать-анага һәм тормышка гашыйк икәнлеген тоемлыйсың.

Рәссамның туган як табигатенә мәхәббәт белән өретелгән сәнгать әсәрләре берничә тапкыр «Зур Идел» күргәзмәләрендә дә катнаша. Күп кенә әсәрләрен Чукоткадагы Анадырь төбәк музее, Владимир-Суздаль музей тыюлыгы, «Казан» милли-мәдәни үзәге сатып ала. Байтак картиналары Канада, Аляска, Югославия, Германия, Италия кебек илләрдә шәхси коллекцияләрдә саклана.

«Кышкы томан», «Тын иртә», «Язгы кар илендә», «Туган як күренешләре», «Шөгердә аяз көн» кебек картинала-

«Кар илендә». Киндер. майлы буяу

«Ялда». Киндер, майлы буяу

ры исә үз туган табигатенә дан җырлавын дәлилли сыман.

Әйе, кылкаләм остасы Мансур Закиров гомере буе тауларга гашыйк.Ул хәтта альпинистлар төркеме белән берничә тапкыр Памир тавына да күтәрелә. Тауларны тасвирлау аның иҗатының зур өлешен тәшкил итә. Шуларда ул таң атуын, кояш баюын, күк гөмбәзенең чиксезлеген киңдергә иңдереп калырга җай да таба. Рәссамның кичке шәфәкъне, томанлы көнне тасвирлаган картиналары күңелне аеруча иркәли. «Мин үзем иң нәзек кылкаләм белән эшләргә яратам» — ди Мансур абый. Шуңадыр да аның эшләрендә элеккеге осталарның иҗат чалымнарын тоемларга була. Мансур Закиров иҗатында төп урынны пейзаж алып тора. Табигатьне сурәткә төшерү гаҗәеп осталык һәм сабырлык сорый. Ул картиналарын үзенчәлекле, таулар, елгаларны чынбарлык итеп иҗат итә. Боларның һәрберсендә кабатланмас осталык, фикер һәм рәссамның күңел җылысын тоясың. Майлы буяу белән иҗат ителгән әсәрләр тамашачыларны гына түгел, сәнгать белгечләрен дә сокландыра. Аларда авторның рух ныклыгын,туган як табигатенә булган сак карашын тоясың. Очсыз-кырыйсыз дөньяны биниһая көчле сәнгате белән колачлый алган рәссам ул Мансур Закиров. Табигать-анага җан өрә алу — үзе зур осталык! ■

«Биектә калу». Киндер, майлы буяу.

КАЯН КИЛӘ ТАТАРГА МОҢ?!

Марс Макаров

Нинди сәбәпләр сагышланып җырларга мәҗбүр итә икән безнең милләттәшләрне? Октябрь инкыйлабыннан соң гына күтәренке рухлы җырлар туа башлады, дисәң дә ялгыш булмас. Җыр тарихы шуны раслый. Әмма моң тәэсир итү куәте ягыннан хәзерге заманда да беренчелекне тота.

Инкыйлабка кадәр ватаннарын калдырып **Финляндиягә** күчәргә мәҗбүр булган **Нижгар** татарлары, туган җирләрен сагынып, моңлы, сагышлы җыр чыгарганнар. **«Илкәем»** дип атала ул. 1968 елның май башында безгә, бер төркем сәнгать әһелләренә, шул искиткеч, күздән яшь чыгара торган тылсымлы көйне фин татарлары башкаруында ишетергә насыйп булды. Сүзләре дә нинди тетрәндергеч бит! Төркемдәге **Рөстәм Яхин**, **Илһам Шакиров**, скрипкачы **Марат Әхмәтов** белән без кичекмәстән әлеге җәүһәрне күчереп, көен нотага салып, Татарстанга алып кайттык, үзебездә башкарырга ният кылдык.

Рөстәм Яхин симфоник оркестрга аккомпанемент язды, Илһам Шакиров башкаруында җыр радиога язылды һәм тиз арада популярлык казанды. Дистәләгән атлы җырчылар «Илкәем»не үз репертуарларына кертте, хәзер бу җыр моңлылыгы, тирәнлеге белән күп кенә яшь җырчыларны да җәлеп итә башлады. Ул җыр туган илне, туган җирне сагынып яшәү символына әверелде.

Илһам Шакиров, Рөстәм Яхин, Айрат Арсланов, Хельсинки университетының төрки телләр галиме Гомәр Таһир, Марс Макаров, Венера Шәрипова һәм Марат Әхмәтов – Финляндия Президенты Урхо Кекконен белән очрашу алдыннан. Президент Сарае. Хельсинки. 1968 елның май ае



Дөньяның төрле илләреннән килгән милләттәшләребез татар җырын тыңлый. Хельсинкиның Зур концерт залы. 1968 елның май ае.



11.01.2004

Söyekle häm kaderle
Mars,
Helsinkidän cılı sälamnä-
rebezne yulliybız. Küp yıllar
oçraşmadık; läkin sin härvakıt
haterebezdäseñ.
Сине яңа ел белән котлыйбыз.
Киләчәктә очрашырга насыйп
булсын. Сеңелең Роза апа
җибәргән һәдияләрең һәм
сәламнәрең өчен зур рәхмәтләр.
Сиңа исәнлек-саулык, тынычлык,
уңышлыклар телибез.
Исән-сау бул!

Okan — Окан
Rahile — Рәхилә
Tiinet — Тинет

ИЛКӘЕМ

Финляндия татарлары җыры

Китми күңелемнән минем һич
Шул сөекле илкәем.
Анда минем сөйгән халкым,
Анда газиз әнкәем.

Анда таңнар җәйге диңгез
Балкуыннан нурлырак.
Анда җырлар сандугачның
Сайравыннан моңлырак.

Анда җырлый җирдә һәр таш,
Кул изи һәрбер агач.
Анда кайтсам, мин дә башка,
Анда мин дә сандугач. ■



МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин



КАЗАН ГУБЕРНАСЫ *тар.* — Русияне губерналарга бүлү турындагы указга Пётр I 1709 елның 3 февраленнән соң кул куйган, дип уйлыйлар[1]. Барысы 8 губерна оештырыла, болар: 1)*Мәскәү* губернасы — барлыгы 39 шәһәр; 2) *Ингерманланд* губернасы (1710 елда Санкт-Петербург губернасы итеп үзгәрә) — җәмгысы 29 шәһәр; 3) *Киев* губернасы — җәмгысы 56 шәһәр; 4) *Смоленск* губернасы — җәмгысы 17 шәһәр; 5) *Архангелогород* губернасы (Архангельск) — җәмгысы 20 шәһәр; 6) *Казан* губернасы — җәмгысы 71 шәһәр; 7) *Азов* губернасы — җәмгысы 25 шәһәр; 8) *Себер* губернасы — җәмгысы 339 шәһәр.

Димәк, баштагы чорда Казан губернасы, Себер губернасыннан кала, иң зурлардан исәпләнгән. Чыннан да, Казан шәһәренә Җаек, Терек, Әстерхан, Царицын (Сарысу), Дмитров, Саратов (Сарытау), Уфа, Самара, Сембер, Царев Санчурск, Кокшайск, Свияжск (Зөя), Царев Кокшайск, Алатырь, Цивилск, Чабаксар, Кашпир, Ядрин, Козьмодемьянск, Яренск, Василь, Кормыш, Темников, Нижний Новгород (Нижгар), Арзамас, Кадом, Елатьма, Касыйм, Гороховец, Муром, Мукшы, Уржум, Балахна, Вязники, Юрьевец Повольский шәһәрләре буйсынган. Болардан тыш, Казан губернасына Азов губернасыннан Пенза шәһәрен дә кушалар.

Административ бүленеш буенча Казан шәһәренең түбәндәге бистәләре (пригородки) була: Лаеш, Алатырь, Ар Малмыжы, Тәтеш, Оса, Минзәлә, Зәй, Старый Темшинск, Новый Темшинск, Тиакс, Биләр, Малинск.

Уфа каласының бистәләре: *Бөре, Каракүл, Соловарный*.

Шушы вакытлардан алып Русиянең административ бүленешендә «Казан патшалыгы» дигән төшенчә бетерелә.

1714 елда Казан губернасы яңача оештырылып, аңа Казан, Зөя (Свияжск), Вятка, Көнгер (Кунгур), Сембер (Симбирск) һәм Пенза шәһәрләре кергән.

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

[1] Адлер Тимергалинның нигә нәкъ менә бу датаны атавы аңлашылмый. Рәсми чыганаклар Пётр патшаның бу указга 1708 елның 18 (29) декабрендә кул куюын күрсәтә. — *Редакция*.

1780 елларда Казан губернасы түбәндәге провинцияләргә бүленгән:

1) Вятка җире яки Вятка шәһәре. 1780 елның 22 декабре;

2) Каманың югары агымы яки Пермь шәһәре;

3) Идел белән Кама арасындагы җирләр яки Казан шәһәре. 1781 елның 23 декабре;

4) Идел белән Сура арасындагы җирләр яки Сембер шәһәре. 1780 елның 27 декабре;

5) Мукшы белән Сура арасындагы җирләр яки Пенза шәһәре. 1780 елның 31 декабре;

6) Сура белән Идел арасындагы җирләрнең көньяк өлеше яки Сарытау шәһәре;

7) Уфа җирләре инде 1734 елдан ук Казан төбәгеннән аерыла һәм 1744 елда Оренбург өлкәсе дип атала башлый, 1782 елда губерна шәһәре Уфа дип билгеләнә. (Карл Фукс буенча.)

Крәстияннәр кузгалышыннан коты очкан әби патша (Екатерина II) 1781 елда Казан губернасын наместниклык («урынчылык») итеп үзгәртә. Наместниклар императрица тарафыннан билгеләнә һәм турыдан-туры аңа буйсына. 1796 елда император Павел I Казан наместниклыгын бетереп, кабат губернага әйләндерә (1920 елга кадәр).

1913 елда Казан губернасының хәзерге Татарстанга кергән өязләрендә 156 ярминкә эшләгән.

«КАЗАН ТУФАНЫ» — Казан шәһәрендә 1926 елның язында гадәттән тыш көчле су басуны шулай дип атаганнар. Бу вакытта 2600дән артык йорт зыян күргән, барлык сәнәгый биналар су эчендә калган, дамбалар җимерелгән, тимер юл һәм трамвай хәрәкәте тукталган. Су кайбер урыннарда көзгә хәтле торган әле. Казанлылар 1927 елның кышына гына гадәти тормышка кайта алганнар.

КАМАЙ МИРЗА — Казан ханлыгында Хөсәен бәкнең улы. Кайбер чыганакларда Камай морза Хөсәенов дип тә телгә алына. Ватанына һәм ханына хыянәт итеп, 7 казак белән Иван Грозный ягына качкан һәм шәһәрдәге вазгыятьне түкми-чәчми дошманга җиткергән сатлык җан. Урыс чыганакларында аның түбәндәге сүзләре китерелә: «Казанның үз эчендә гарнизон һәм шәһәр кешеләреннән торган утыз меңгә якын сугышчы бар. Шәһәр тышында исә атлы гаскәр һәм тышкы казаклардан торган гаскәр Япанча бәк, Чапкын белән кардәше Шунак һәм Арча бәге Яуш җитәкчелегендә сугышырга җыеналар. Аларга уңайлы вакытны күрсәтеп, биек манарадан милли әләм белән болгап, хәбәр биреп торырга тиешләр».

1552 елның 1 октябрендә Казан каласын тупка тотканнан соң кенәз Иван Камай мирзаны берничә Тау ягы кешесе белән казанлыларга илче итеп җибәрә, бирелергә тәкъдим итеп карый. Ләкин Камай мирза казанлылардан: «Баш бирмибез!» — дигән катгый сүзне генә ишетеп кайта. Камалышта калган казанлыларның җир астындагы юлдан чыгып, суны *«Таһир мунчасы»*ннан ерак түгел, Казан елгасы кырыендагы бер чишмәдән алулары турында да Иванга сөйләүче — шушы зат. Шуннан соң урыслар ун көн буена мунча яныннан чишмәгә таба юл казып, 4 сентябрь көнне казанлыларның яшерен юлы астына 11 кисмәк дары куеп шартлаталар.

Яшерен чишмә (*Тайницкий чишмәсе* — Җәшерек чишмә) моннан соң да озак вакытлар буена файдаланылып килгән әле. 1953-1955 елларда дамба төзегән вакытта чишмә күмдерелә, өсте асфальтлана. Ә бит аны *татарның иң Изге чишмәсе* дип игълан итәргә кирәк иде. Ихтимал, бу урынның исемен мәңгеләштерү турында уйларга хәзер дә соң түгелдер әле.

Казан алынганнан соң, Камай мирзаның урыс хакимиятләренә каршы баш күтәргән халыкны бастыруда катнашканлыгы билгеле. Газиз Гобәйдуллин Камай мирзаның «замогы» (сарае) хәзерге Әйшә авылы янындагы Иске Казан дигән җирдә булуы турында яза. ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның сентябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Казан земствосы вә мөселманнар

Вилаять земствосы тарафыннан 8 урында ошбу ел ачылачак һөнәр йортларының бары да рус авылларында булачак. Үткән эш үткән, кайгыруның мәгънәсе юк, һич булмаса, вакытны форсат белеп, шул рус авылларында ачылачак һөнәр мәктәпләренә балаларыбызны бирергә кирәк.

1) Казан өязе Чебакса авылында фигуралы тимер рәшәткә, тимер койма, капка, ишек, һәртөрле тимер баскычлар ясарга өйрәтелә. Болардан башка рәсем вә әшкял [сызым] һәм башкалар өйрәтеләчәктер. Уку срогы өч елга кадәр булып, фәкыйрь булган шәкертләргә беркадәр ярдәм биреләчәктер. Моннан укып вә эшләп чыккан кешеләргә шәһадәтнамә бирелеп, үзләре дә һөнәрханәләр ачар дәрәҗә хокуклы булачаклардыр.

2) Лаеш өязе Рыбная Слобода авылында төрле таш, пыялалар кыру, алтын-көмеш, бакырдан төрле зиннәтләр ясау, чиркәү җиһазлары, кәшишләр [монахлар] кием, тәрәзә вә ишекләргә куела торган төрле зиннәтләр вә кыйммәтле тоткалар эшләтеләчәктер*.

3) Казан өязе Пестрецы авылында балчыктан эшләнә торган төрле чәчәкле посудалар вә таш савытлар, фигуралы мич кирпечләре, йортларга ябыштырыла торган төрле балчык фигуралар ясарга вә болардан башка рәсем, әшкял өйрәтеләчәктер*.

4) Монастырь (Тәтеш өязендә). 5) Шимизан (хәзерге Чемерчеево?) (Чуел өязендә). 6) Казыль (Казиле) авылында (Лаеш өязендә). 7) Аксубай (Чистай өязендә). Бу дүрт авылда һәртөрле авыл мәгыйшәтендә файдаланыла торган машиналар: сабан, тырма, ашлык суга торган, орлык чистарта торган һәм урак машиналары ясарга өйрәтәчәкләр.*

8) Чистай өязе Богород авылында күн, тире эшләре, аларны буяу ысуллары өйрәтеләчәк. Болардан башка гыйльме хисап, кимия, хикмәте табигыя өйрәтеләчәк.

Әлеге һөнәр йортлары мөселман авылларына күрше рус авылларындадыр. Мөселманнар гафил булмаска тиешләр. Бу һөнәр мәктәпләренә балаларын бирсәләр, мөселманнар бәхетле булачаклар.

Имам Хәсән Манаш.

Кояш. — 1915. — №794. — 8 сентябрь.

Кайчан бетәр икән?

Яз җитәме, көз җитәме, яңгыр вакытлары буламы, һәрвакыт Печән базары, Күмер базары, күл буе тирәләре саналган киң урам бер баткаклык тасвир итә. Бу урамнан кучу өчен махсус калушлар киеп төшелергә тиеш.

Даталар иске стиль белән бирелә.

* Бу урыннарда 1 нче пункттагы мәгълүмат кабатлана.

Мөселман җәмәгасенең шәһәр уртасына иң күп йөри торган урамы булган бу урам соңгы көннәрдә бигрәк тә шакшыланып тора. Урам шакшы, сасы батсаклыкка әйләнгәнлектән, йөрүчеләрнең әллә ничә җирдә тыгылышып торганлыклары, тар бер сукмак буйлап үтәргә нәүбәт көткәнлекләрен күрергә мөмкин. Балаларны бу тирәләрдән күтәреп күчерергә мохтаҗ булына. Яшьрәкләр, мәктәпкә йөрүчеләр өчен бу урамнан үтү Ходаның бер бәласе. Алла сакласын, йогышлы чирләр барлыкка килә калса, бу урам чирне таратырга зур хезмәт күрсәтәчәктер. Шәһәр Думасы мәҗлесе дә бу урамны тазарту кирәклегенә кабат-кабат дикъкатьне җәлеп итә. Дума әгъзалары аерым-аерым гаризалар биреп тә карыйлар. Бу урам халкы җыелышып та управага гариза биреп карыйлар. Урам шакшылыгы бетерелүгә әһәмият бирелми дә бирелми. Бу урамның былчыраклыгын киметүгә, андагы күлләрне корытырга әһәмият бирмәүләр кайчан бетәр икән? Мөселман җәмәгасе шушы бер шакшы урам аркылы күчү өчен генә махсус калушлар өстерәп йөрүдән кайчан котылыр икән?

Кояш. — 1915. — №800. — 15 сентябрь.

Русча-татарча мәктәпләрне зурайту

Шәһәрнең мәктәпләр комиссиясенең 16 нчы сентябрьдә булган мәҗлесендә русча-татарча укытыла торган мәктәләрне зурайту мәсьәләсе каралган. Русча-татарча мәктәпләргә кереп укырга теләүчеләр күп булса да, урын юклыкка күрә, күбесе кабул ителә алмый калалар икән. Шушы хәлне бетерү өчен комиссия мәҗлесе, ике мәктәпне зурайтып, мөтәвази [параллель] сыйныфлар ачарга карар кылган. Мөгаллимнәр мәсьәләсенә күчкәч, мондый мәктәпләрнең күбесендә учитель булып торган кешеләрнең сугышка алынганлыклары сәбәпле, учительсез калганлыклары, алар урынына татарча белә торган кандидатлар юклыгы белдерелгән. Мондый кешеләр табылмаганга күрә, комиссия бу мәктәпләрдә укытырга гимназия бетергән татар кызларын җәлеп итәргә карар кылган. Шулай ук кызларны бу урынга урнаштыруны вакытлы итеп танырга вә элекке учительләре сугыштан кайтып җитүләренә кадәр генә шушы урында калдырырга, дигән карар да кабул кылынган.

Кояш. — 1915. — №807. — 23 сентябрь.

Качакларга ярдәм итегез

Хәзерге көндә бер мөселман комитеты карамагында гына 280ләп качак бар. Янә һәр көн диярлек килеп торалар. Боларның 100гә якыны уку яшендәге балалар. Балаларның 60лабы мөселман мәктәпләренә, 7-8е рус мәктәпләренә урнаштырылдылар. 50ләп качак мөселман төрле урыннарга хезмәткә керде. Янә берникадәре хезмәткә кереп эш эшли алачаклардыр. Ләкин качакларның күбесе эшкә яраксыз карчык вә бала-чага булдыклырыннан, мөселман комитетына боларны тәэмин итү өчен яхшы ук зур суммалар кирәк булачактыр. Мөселман комитеты, шуны алда тотып, кружка илә акча җыю эшенә җитди катнашырга карар бирде. Бу көн комитетның һәммә әгъзалары кружка илә иганә җыярга чыгачаклардыр.

Кояш. — 1915. — №812. — 30 сентябрь. ■

Көлке куа килә...

Каюм НАСЫЙРИ

АКЧА СИКЕРТӘ

Бер патша су яныннан барганда күрде: бер карт бу суны җиңел генә сикереп чыкты. Карт белән бер яшь егет тә бар иде, анысы су аркылы чыга алмыйча, гаҗиз булып ярда калды. Патша бу хәлгә гаҗәпләнеп, карт белән егетне сөйләштереп карады. Алар аңа үз хәлләрен бәян кылдылар: карт кешенең янында мең алтыны бар икән, ә егет фәкыйрь икән.

«Акча кешене сикертә» дигән сүз шушы хикәянең нәтиҗәсе булмак кирәктер.

(«Фәвакиһелҗеләса», 1884)

Фатих ӘМИРХАН

КЫСКА БЕР СӘФӘР

Көннәрнең берсендә минем янга йорт хуҗасы — мәңге исерек, мәңге кызыл йөз вә кызыл борынлы, ак сакаллы карт керә.

— Барин, синең исемең ничек?

Мин исемемне һәм атамның исемен әйтәм. Карт бер дә тәүкыйфсыз (тын да алмыйча) гына:

— Юк, мин андый исемеңне әйтмим; русча исемең ничек?

— Минем нишләп русча исемем булсын? Мин рус түгел бит.

Карт, болай дигәч, бераз аптырап кала, ләкин шулай да бирешми:

— Как же русча исемең булмасын, барин? Безнең бит сезнең борадәрләрдән белешләремез күп; һәммәсенең русча исемнәре бар. Менә такта яра торган заводның урман каравылчысы бар, мөселманча исеме — Кусаин (Хөсәен), ә безнеңчә исеме — Кузьма. Менә мондагы баринда (авылда тора торган помещикны идарә итә) имение управлающие булып сезнең борадәрләрдән берәү торган иде, аның безнеңчә исеме Филипп Яковлевич иде. Хатынының исеме Марфа иде, ә кызларының берсе Александра, берсе Матрёна, берсе Евдокия иде. Как же, барин, синең генә русча исемең булмасын!

— Ә синең татарча исемең ничек соң?

— Минем — Иван Зинович! Минем сезнеңчә дә, үзебезчә дә исемем шулай — Иван Зинович!

Исерек карт Иван Зинович дигән сүзне бертөрле рус милли горурлыгы белән, тавышын нык вә каты тотып әйтә.

— Шулаймы? Менә шулай ук минем дә русча исемем дә, татарча исемем дә шул бертөсле, сезнең борадәрләреңез (туган, иптәш) дә мине Фатих Зарифович дип йөриләр!

Зарар юк, минем исемемне әйтеп, ул да бераз телен ватсын.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

БЕР РӘХӘТНЕҢ... БИШ МИХНӘТЕ

Минем күзәтүләрем:

1. Хатын-кыз никадәр ямьсез булса, шулкадәр киенә белми.

2. Тукай поэзиясен иң примитив аңлаучы кеше, һичшиксез, тукайчы була.

3. Уңган хатын ирсез кала. Күп очракта.

4. Татар әдәбиятын иң примитив аңлаучы кеше, һичшиксез, тәнкыйтьче була.

5. Татар теленең нечкәлеген аңламаган, тоймаган кеше химиягә, физикага, математикага китми: ул — тел галиме була.

6. Кешенең тормыш коруы — космоска чыгу. Старт дөрес алынса — программа үтәлә; старт начар алынса — бернинди центр корректировка ясый алмый.

7. Бер рәхәтнең бер михнәте була, диләр. Дөрес түгел: михнәте биш тапкырга артык була.

8. Әгәр кеше надан булса, аннан котыла алмый: надан профессор, надан академикка хәтле күтәрелеп була, әмма наданлык кала.

9. Бер борчу килердәй булса — көт, ул килә.

Ризван ХӘМИД

ӨЧ ГАЛИМ ҺӘМ ЮЛБАРЫС

Өч галим борынгы мәгарәдә яшәгән

Ризван Хәмид. Л.Лерон шаржы

кылыч тешле юлбарыс сөякләренә юлыга.

Берсе әйтә: мин моның скелетын кабат җыеп бирә алам, ди.

Икенчесе әйтә: ә мин скелетына кабат тән үстерә алам, ди.

Өченче галим шуңа җан өрә алуын әйтә. Һәм шулай итәләр дә. Юлбарыс терелә дә өчесен дә тотып ашый. Без нәкъ шул галимнәргә охшаганбыз: берәүне күкләргә чөеп мактый-мактый юлбашчы итеп күтәрәбез дә... ул безнең башларыбызны ашарга тотына.

Мәмдис ХӘСӘНИ

АҢЛАШТЫЛАР

— Кызым, син бүген шкулдан нишләп поздно кайттың?

— Мамочка, без уроклардан соң татарча тел изучать итә башладык. Мама — әни, папа — әти, дигән сүз икән. И мин в дальнейшем сезгә әни, әти дип скажу...

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан.)

Казан янә үзен күрсәтте

Атлас Гафиятов

Быелгы җәйдә ике атнадан артык Казан янә бөтен дөнья халкының игътибар үзәгендә булып алды: бездә 24 июльдән 9 августка кадәр Су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты узды.

Иң әүвәле шуны искә төшерик: мондый чемпионатлар рәсми рәвештә 1973 елдан бирле үткәрелә. Баштарак алар Олимпиадалар кебек 4 елга бер генә тапкыр үтсә, XXI гасыр башыннан бирле ике елга бер тапкыр уздырыла. Моңа кадәр Австралия белән Испаниядә — өчәр, Италиядә — ике, алардан тыш Япония, Кытай, Канада, Эквадор, Югославия, Германия, Колумбия кебек илләрдә үтсә дә, «су



мундиале»нең Русиядә (хәтта элеккеге СССР да) узганы юк иде әле. Шулай итеп, Казан бу очракта да — беренче!

Кемнәргәдер бу очракта: «Ә нигә кирәк соң безгә мондый ярышлар?» — дип тә әйтергә мөмкин. Әмма андый пессимистларга Казаныбызның соңгы ун елда яхшы якка ничек үзгәрүен дә күрсәтү җитә. Чыннан да, башкалабызны бигрәк тә өч зур вакыйга Европа шәһәрләре дәрәҗәсенә җиткерде, безне бөтен дөньяга танытты. Болар — 2005 елда Казанның меңьеллыгын билгеләп үтү, 2013 елдагы Универсиада һәм быелгы Су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты. Чемпионатны телевизор экраны аша 4,5 млрд. халык каравы үзе генә күп нәрсә хакында сөйли.

Инде чемпионатның спорт нәтиҗәләренә килсәк, алар болайрак: белгечләр алдан ук фаразлаганча иң күп медальләрне Кытай, АКШ һәм Россия спортчылары яулады. Кытайлылар исәбендә 15 алтын, унар көмеш һәм бронза. АКШ командасы 13 алтын, 14 көмеш һәм 6 бронза медаль яулады. Россиялеләрнең күрсәткечләре 9 алтын, 4әр көмеш һәм бронза белән чикләнә. Бөтендөнья белеп тора: безнең кызлар синхрон йөзүдә, ә Кытай спортчылары трамплиннан суга сикерүдә беренчелекне бирәүгә дә бирмәскә тырыша. Шулай



да соңгы вакытта бу төрләрдән башкалар да аларга якынлаша, хәтта узып та китә. Бер көрәшү — үзе бер гомер, дигәндәй, чемпионатлар ярышлардан, медальләрдән генә тормый. Бу спортчылар, тренерлар, тамашачылар өчен үзара танышу, күрешү, дуслашу урыны да. Ярыш вакытында бер-берсенә көндәш булган спортчылар, ул тәмамлануга бер-берсен тәбрикләргә, чын күңелдән аралашырга тотына. Әйтик, Русия спорты тарихында хай-дайвинг, ягъни 27 метрлы манарадан суга сикерү буенча бронза медаль откан Артём Сильченко ярышлар тәмамлануга төп көндәшләрен үзенең туган ягына — Воронежга кунакка алып китте.

Чемпионатта 12 дөнья рекорды куелды, әмма рекордлар моның белән генә чикләнми. Әйтик, анда дөньяның 190 иленнән 2700дән артык спортчы катнашуы үзе бер рекорд булса, 75 комплект медаль уйнатылу — шулай ук тәүге мәртәбә. Чемпионатның ачылу тантанасын янә сигез мәртәбә кабатлап күрсәтү, синхрон йөзү һәм трамплиннан сикерүдә катнаш дуэтларның катнашуы – болар барысы да тәүге тапкыр үткәрелде. Чемпионат барган көннәрдә безгә якынча 100 мең турист килүе көтелсә, чынлыкта аларның 130 меңнән артып китүе шулай ук рекордлы күрсәткеч.

Иң мөһиме: без дөньякүләм зур форумнар үткәрергә, ягъни кунаклар чакырырга, аларга үзебезнең рухи һәм матди байлыкларыбызны күрсәтергә тәмам өйрәнеп җиттек. Моны ярышларны ачу тантасында Россия президенты Владимир Путин да билгеләп үтте.

Заманча спорт корылмалары, кунакханәләр, аэропорт, метро, вокзаллар, юллар — болар барысы да Казаныбызның абруе көннән-көн күтәрелә баруы хакында сөйли. Биналар гына түгел, үзебез дә яхшы якка үзгәрә барабыз. Ресторан-кафеларда, транспортта, кибеттә эшләүчеләр, полиция хезмәткәрләре килгән кунакларга гына түгел, ә гомумән халыкка карата да кешелеклерәк, мәрхәмәтлерәк була башлады. Бәлки нәкъ менә шушылар иң мөһим нәтиҗәдер? ■

Мирасворд

... Шәфигуллин

Хайваннар дөньясы

Эссе, кайнар / Элекке удмурт

1906-1910 елларда Оренбургта чыккан журнал

Галиев, Кари

Казанның элекке бистәсе

Кирәкле, тиешле (иск.)

Ат жигү дирбиясе

Юан бүрәнәгә чокып ясалган гади умарта

Нәсел, кан кардәшлеге булган берничә буын

Иген, төрле әйберләр саклау өчен мичсез бина

Алтын, көмеш җепләрдән бизәнү әйберләре ясау ысулы

«... Чудра» хикәясе (М.Горький)

Мылтык чакмасы

Хәрби старшина (иск.)

... - клуб (Бөтен-дөнья язучылар оешмасы)

«... төннәр» повесте (Г.Әпсәләмов)

Печән өеме / Ике дистә

Борынгы ату коралы

Борынгы Идел

Кәрим Тинчурин драмасы

Перу каласы

Телеканал

Иллэтнең сул кушылдыгы

Нажар, Кави

... шулпасы

Иң вак кисәкчә, бөртек, тузан (иск.)

Борынгы грек архитекторы

Һадия Дәүләтшина романы

Хәнҗәр савыты

Борынгы грек

Артсыз диван

«Дин вә ...» шигыре (Г.Тукай)

Хәсән Туфан поэмасы

... сабагын укыту / Туфан Миңнуллин пьесасы

Түбән сыйфатлы соры күмер / Мавритания акчасы



«... егет» дастаны

Укылган тестны үз сүзләрең белән кабат язу

Ярмәки, Мансур

Башкортстандагы район

Рәис Габдулла *төзеде.*

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: иkенде, Баруди, ерак, кояр, балет, киерге, лар, Ак, вирд, акын, АИ, «Мәктәп», Кысна, лаек, алу, Курсави, ислах, фән, ОМО, туз, убыр, Ирек, кош, кин.

Өстән аска: Кәримуллин, ук, ярлык, лобо, имбир, Туктамыш, ханә, хор, берле, кыпчак, урак, Лу, Дали, акбур, Еникеев, тик, триас, Гафури, Грин, вәзен, де, Алкин.

Тел, әдәбият һәм тарих институты урнашкан бина.

«Безнең мирас»
елъязмасы /сентябрь

● 160 ел элек (1855)

Шагыйрь Әхмәт Кормаши (1855-1883) дөньяга килә.

● 120 ел элек (1895)

10 сентябрьдә Казан сынлы сәнгать училищесы ачыла.

15 сентябрьдә күренекле драматург Таҗи Гыйззәт (1895-1955) дөньяга килә.

● 110 ел элек (1905)

2 сентябрьдә Санкт-Петербургта татар телендә беренче газета — «Нур»ның (1905-1917) тәүге саны дөнья күрә.

● 80 ел элек (1935)

«Совет әдәбияты» журналында Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте басыла башлый.

● 75 ел элек (1940)

7 сентябрьдә Татар дәүләт академия театры Әхмәт Фәйзи пьесасы буенча куелган «Тукай» спектакле белән үзенең яңа сезонын ачып җибәрә.

● 70 ел элек (1945)

Сентябрь башында СССР Фәннәр Академиясе Президиумы Казанда оештырыла торган филиалының составын раслый. Филиал 5 институттан һәм бер сектордан торачак. Тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры итеп Мөхәммәт Гайнуллин билгеләнә.

● 60 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге» повесте дөнья күрә.

● 55 ел элек (1960)

«Совет әдәбияты» журналында Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романы басыла башлый.

● 25 ел элек (1990)

5-10 сентябрьдә Әнкарада Төрек тарихи корымы (җәмгыяте) тарафыннан оештырылган XI халыкара тарих конгрессы була. Анда язучы һәм галим Миркасыйм Госманов «XV-XVIII йөзләрдә Рус дәүләтенең көнчыгыш илләре белән дипломатик бәйләнешләрендә татар теленең урыны» дигән темага төрек телендә доклад белән чыга. Төркиядә булган вакытта М.Госманов биредә яшәүче күренекле милләттәшләребез белән очраша, татар халкы тарихына кагылышлы мөһим документлар туплый. ■

Равил Сәйяр улы Айдаров 1950 елда Арча эшчеләр бистәсендә дөньяга килә. 1972 елда Казан инженер-төзүчеләр институтының архитектура факультетын тәмамлый.

Равил Айдаров — Татарстан Республикасының атказанган архитекторы, Халыкара мәдәният һәм сәнгать академиясе академигы, Россия Архитекторлар берлеге әгъзасы.

2012 елның язында «Хәзинә» галереясында Равил Айдаровның «Казанның 100 агач йорты» дип аталган акварель рәсемнәр күргәзмәсе булды һәм гаҗәеп зур кызыксыну уятты.

Равил Айдаров



«Каюм Насыйри урамындагы йорт»
Кәгазь, акварель.



«Габдулла Тукай урамындагы йорт».
Кәгазь, акварель.

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

2016 елның беренче ярты еллыгына почтада язылу бәясе – 498 сум

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

Редакциядә язылу бәясе – 380 сум

Электрон версиягә язылу – 350 сум

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» АҖ бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172